Әхмәт Кадыйр инде мәңгелеккә күчте, ләкин дә Грозныйда аның музее эшли. Шул музейда бүген дә Җәмил Вәлиуллинның өендә узган табыннан дистәләгән сурәтләр саклана һәм ул фотоларны бүләк итеп бирүемә мин дә шатланам.

Безнең татар: "Дөнья куляса, бер әйләнә дә, бер баса", - ди. Заманында Җәмил әфәнденең атасы ачлык елларын Грозныйда уздырган. Йөз елга якын вакыт узгач, Чечня мәмләкәтенең Илбашы Әхмәдулла абзыйның 24 нче баласы - Җәмилдә кунак кына булмады. Ул татарның 99 вәкиле белән әңгәмә тотып, мөселманлык рухын көчәйтеп, күңел түрендә бүләккә татарның сабырлыгын да алып кайтып китте. Табында хәзрәтебез Вагыйз Яруллин сөйләгән нотык (речь) күңелдән китми.

"Без 500 елдан артык түзәбез һәм матур яшибез", - дигәне.

# ЧЫН ТАТАР ИР-АТЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ УЛ

***Татар ир-атлары арасында тырыш, уңган, тормышта зур уңышларга ирешкән, мәрхәмәтле, олы җанлы кешеләр булуы халкыбыз өчен горурлык хисләре уята. Исмәгыйль Лотфулла улы Латыйпов нәкъ шундыйлардан. Акыллы, югары интеллигентлы, йомшак телле бу кеше белән сөйләшеп утыруы гына да куңелгә ятты. Әти-әнисе, балачагы турында исенә төшергәндә Исмәгыйль абыйның хәтта күзләре яна башлады, әйтерсең лә ул узган гомер юлларыннан тагын бер кат атлап үтте...***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**



Кошки районының Тупли авылында 1964 елның 3 гыйнварында җиде балалы гаиләдә алтынчы булып дөньяга килгән Исмәгыйль әфәнде бүген дә биредә яши. Яраткан туган авылын, аның искиткеч матур табигатен: иртә таңнарда талга кунып сайраган сандугач тавышларын, моңлы итеп чылтырап аккан чишмәләрен, бакалы күлләрен, шаулап торган урманнарын ташлап, читкә китә алмаган ул.

Әтисе таләпчән булганга, ул балаларын кечкенәдән эшкә өйрәтеп тәрбияли. Шуңа күрә җиде баланың да өйдә, йортта үз вазифалары була.

*- Мин өченче сыйныфтан алып өй, мунча ягу эшләрен башкардым. Колхозда әти-әнигә чөгендер утарга, мәк чәчәген җыярга булыша идек. Мәктәптән дә ел саен көзен колхоз кырына эшкә җибәрәләр иде,* - дип елмаеп исенә төшерә балачагын Исмәгыйль абый.

Аның әтисе - сугыш ветераны. 87 яшьлек Лотфулла абый, шөкер, бүгенге көндә исән-сау, Тупли авылында яши. Ул Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында туган. 1928 елда аның әтисе Халик 20 дән артык гаилә белән Туплидан 5 чакрым ераклыктагы җирдә яңа авыл булдырган. Алмалы дип аталган 45 - 50 йортлы бу авыл 60 ел яшәгән. Бүгенге көндә ул җир йөзендә юк инде.

Лотфулла абыйның бала һәм яшүсмер чагы шунда үтә. Ә 1943 елда ул армия сафларына алына. Алты айлык курслардан соң аны фронтка җибәрәләр, биредә ул мотоукчылар гаскәрләренә эләгә. 1нче Белорус фронты составында Лотфулла Латыйпов Берлинга кадәр барып җитә, Зееловск биеклекләрен алуда катнаша. Әле сугыш тәмамлангач та, ул 1950 елга кадәр Дрезден шәһәрендә хезмәт итә.

Авылга әйләнеп кайткач, Лотфулла әфәнде Минкамал исемле кызга өйләнә, һәм алар Туплига күчеп урнашалар.

- *Советлар Союзы вакытында авылда таш өй салып кергән иң беренче кеше минем әти була,* - дип горурланып сөйли Исмәгыйль әфәнде.

Аның әтисе белән әнисе күп еллар авыл кибетендә сатучы булып эшлиләр. Әтисе моңа кадәр колхозда токарь да, терлек караучы да булып эшли.

Әнисе, кызганычка, ике ел элек якты дөньяны ташлап киткән. Бертуганнарының барысы да, шөкер, исән-саулар.

Исмәгыйль абый укыган елларда авыл мәктәбендә 612 бала белем ала торган булган. 1970 елда ул яшьтәшләре белән бергә 1 сыйныфка яңа төзелгән мәктәп бусагасын атлап кергән.

Тырышып укыган, тәртипле малай октябренок та, пионер да була, аннары аны комсомолга да алалар. Актив, үзен яхшы яктан гына күрсәткән, җитди, җаваплы егетне 8 - 10 сыйныфларда укыганда комсомол комитетында спорт секторы өчен җаваплы итеп билгелиләр.

Исмәгыйль әфәнде балачагында да иске акчалар җыю белән мавыга. Бер алты яшьләрендә футбол уйнап кайтканда урамда иске акча тапканнан соң барлыкка килә бу кызыксыну. Тора-бара күңеле археологиягә тартылган малай бу фән буенча бик күп китаплар үзләштерә башлый, тарих дәресләрен яратып укый.

Моңардан тыш, ул иптәшләре белән футбол, баскетбол, волейбол да уйный, чаңгыда да шуа.

- *Безнең тарих укытучысы Таһир*



*Борһанович Әбүзәров авылда спортны шулкадәр күтәрде ки, без, укучылар, район, өлкә күләмендә уздырылган төрле спорт ярышларында һәрвакыт призлы урыннар ала торган идек. Штанга күтәрү буенча да өлкә чемпионнары исемен*



*яулаучылар булды. Алар арасында Хәсибулла Исмәгыйлев, Вәлиәхмәт Шакмаевны атарга була,* - дип исенә төшерә Исмәгыйль абый.

Археология белән мавыккан егет алдында, мәктәпне тәмамлагач, нинди һөнәр сайлап алыйм дигән сорау туды. Үзенең тарих укытучылары Таһир Борһанович Әбүзәров һәм Анна Александровна Әбүзәрова ярдәме белән аңа комсомол комитетыннан юллама бирәләр, һәм ул Куйбышевның педагогия институтына тарих-инглиз факультетына укырга керә. Ул чакта бу факультет, экспериментал буларак, әле яңа ачылган була һәм бары тик 5 ел гына эшләп кала. Латыйпов нәкъ шушы чорга эләгә дә инде.

Институтның бишенче курсын тәмамлаганда Исмәгыйль әфәнде үзенең сөйгән яры, авылда бергә уйнап үскән Руфиягә кияүгә чыгарга тәкъдим ясый. Матур итеп туй уздыралар, һәм яшьләр Тупли авылына кайтып төпләнәләр.

Исмәгыйль әфәнде биредә тарих укытучысы булып эшли башлый. Шулай ук аны мәктәптән тыш эшне оештыручы итеп билгелиләр. Яшь укытучының тирән белемен, тырышлыгын, булдыклылыгын күреп, бер ел дә үтми, квалификацияне күтәрү курсларына җибәрәләр. Аларны тәмамлап кайткач та, Исмәгыйль әфәндене мәктәп директоры итеп куялар. Күп көч таләп итә торган, җаваплы бу вазифадан башка, ул бер үк вакытта тарих һәм физкультура дәресләрен дә укыта.

- *Балаларны яратам, шуңа күрә укытучы эшен дә бик яратып башкардым. Каникуллар вакытында укучыларымны сагынганга, аларның укырга чыкканнарын зарыгып көтә идем. Балаларны яратмасаң, мәктәптә эшләп булмый ул,* - дип сөйли Исмәгыйль Латыйпов.

Укучылар да укытучыларын бик ярата торган булалар. Чөнки мәктәптән тыш эшне оештыручы буларак, ул балалар өчен төрле кызыклы бәйрәмнәр, походлар, төрле шәһәрләргә экскурсияләр оештыра. Гомумән, актив кеше буларак, ул укучыларын да шундый яшәү рәвеше алып барырга күнектерә. Укытучылар белән бергә тирә-як авылларга концертлар, пьесалар куярга да йөриләр алар.

1997 елда Исмәгыйль Латыйповны Елховка районының мәгариф бүлеге мөдире итеп билгелиләр. 2002 елга кадәр ул бу вазифаны башкара, ә аннан соң юллар төзү белән шөгыльләнүче "МДМ" җәмгыятенә директор булып күчә һәм бүгенге көнгә кадәр биредә эшли.

Исмәгыйль әфәнде кайда гына эшләмәсен, үз хезмәтен җиренә җиткереп, яратып башкара. Кешелекле, мәрхәмәтле милләттәшебез хәленнән килгәнчә башкаларга, иң беренче чиратта туган авылына, матди ярдәм дә күрсәтә. Әле Елховка районының мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгәндә ул мәктәп укучылары, авылдашлары өчен, автобус яллап, Изге Болгарга сәяхәт оештыра торган була.

- *Бу өч көнлек дөньяда кешелекле булырга, башкаларга хәлеңнән килгәнчә ярдәм итәргә кирәк. Изгелек җирдә ятмый ул, үзеңә әйләнеп кайта. Кешеләрнең уңышларына шатлана, кайгыларын уртаклаша белергә кирәк. Шул вакытта җаныңда тынычлык һәм гармония булачак,* - дип уртаклашты Исмәгыйль абый.

Буш вакытларында ул мәктәп укучылары, авылга шәһәрдән әби-бабасына кунакка кайткан балалар белән футбол уйнарга ярата. Кышын урманда чаңгыда шуудан ләззәт таба икән. Шәһәргә килгәч, бильярд уйнамыйча китми, чөнки, аның сүзләренчә, бу аны тынычландыра.

- *Үзегездә нинди кимчелекләрегез бар дип саныйсыз?* - дигән соравыма Исмәгыйль әфәнде:



- *Кешеләргә юк дип әйтә алмыйм мин. Ә алар арасында төрлеләре була бит,* - дип җавап бирде.

Ә өстенлекләреннән төгәл, сүзендә торырга, кешелекле булырга тырышуын атады. Башка кешеләрдә дә ул шундый ук сыйфатларны өстен күрә икән.

Милли җанлы татар буларак, татар хәрәкәте турында да үз уй-фикерләрен белдерде Исмәгыйль Латыйпов.

*- Соңгы 20 елда, милли проблемаларны хәл итү мөмкинлеге туггач, бу өлкәдә, бәхәссез, бик күп эшләр башкарылды. 30нчы еллар азагында татар газета-журналлары ябылып, дин әһелләре, милли хәрәкәт җитәкчеләре кулга алынып, төрмәләргә ябылды. 80нче еллар азагында милли рухка сусаган халык башы белән бу эшкә чумып, уңышларга ирешә. Татар бәйрәмнәре, концертлары үткәрелә, татар газеталары чыга башлады, татар мәктәпләре, мәчетләр ачылды, милли оешмалар булдырылды.*

*Тик бүген татар оешмалары арасында бердәмлек җитешми, дип саныйм. Аккош, кысла һәм чуртан кебек булмаска иде. Әгәр дә милли хәрәкәт башлыклары бер-берсе белән бердәм булсалар, хөкүмәт җитәкчеләре белән очрашып сөйләшүе дә, проблемаларны хәл итүе дә җиңелрәк булыр иде бит. Гомумән, милли-мәдәни хәрәкәт һәм Диния нәзарәте бердәм структура булырга тиеш, дип уйлыйм. Шундый бер риваять тә бар бит: бер бабай үләр алдыннан үзе янына балаларын чакырып ала да, менә сезгә себерке, аны сындырып карагыз, ди. Тегеләр ничек кенә тырышмасыннар, себеркене сындыра алмыйлар. "Ә хәзер, - ди бабай, - себеркенең чыбыкларын берәм-берәм сындырып карагыз". Балалары чыбыкларны бик тиз һәм җиңел сындырып ташлыйлар.*

*Шулай итеп, без бердәм булсак, безне сындыра алмаячаклар. Бер себерке, аның яхшы хуҗасы да булса, шул вакытта милли хәрәкәтебез дә көчле булачак, минемчә. Татар оешмаларының җитәкчеләренә үзләренең җәмгыяте турында түгел, ә халык, аның ихтыяҗлары турында уйларга кирәктер,* - дип сөйләде ул һәм дингә, авыл мәктәпләре проблемасына да тукталып үтте.

*- Менә бүген мәчетләргә бик аз кеше йөри, диләр. Аллаһы йорты халык белән тулып торсын өчен мәхәлләләрнең имамнарына халык белән актив эш алып барырга кирәк, дип уйлыйм. Ә инде мәчеткә күпме кеше йөрүе аларның эш нәтиҗәләренең яхшы күрсәткече булып торырга тиеш тә инде.*

*Мәктәпләргә килгәндә исә, үзебезнең авылны гына алыйк: 23 укучы өчен генә тулы мәктәп булдыра алмыйлар бит инде. Шуңа күрә балаларыбыз Елховка район үзәгенә йөреп укыйлар. Һәм мин моны начар, дип санамыйм, чөнки анда югары квалификацияле укытучылар эшләгәнгә,*



*укучыларның белем сыйфаты да яхшырак булачак. Бүгенге көндә һәр авылда хастаханә булдыру мөмкинлеге булмаган кебек, 11 еллык мәктәп тә булдыру мөмкин түгел, чөнки биредә укучылар саны да, югары квалификацияле укытучылар да аз. Шуңа күрә балаларны район үзәкләренә йөртеп укытуны бу авыр ситуациядән чыгу юлы, дип саныйм.*



*Ә татар телен балалар башлангыч сыйныфта үзләштерергә тиешләр. Тик монда гаиләнең роле тагын да зуррак, чөнки өйдә ата-аналар нарасыйлары белән үз телендә аралашмасалар, укучыларга аны мәктәптә генә өйрәтеп бетерә алмыйлар шул. Ә бит ана телен белгән баланың потенциалы зур булганлыктан, аңа башка телләрне дә өйрәнүе җиңелрәк, - дип саны Исмәгыйль абый.*

Аның үз кызлары Гөлназ һәм Гөлгенә дә татар телен яхшы беләләр, чөнки алар гаиләдә һәрвакыт ана телендә генә аралашалар икән.

Шулай бүген 50 яшькә җитеп килүче Исмәгыйль әфәнде Латыйпов яшь егетләрдәй дәртле, актив, көч-куәт белән тулы. Чын татар ир-атларының берсе буларак, ул үз эшен дә яратып башкара, милли хәрәкәт өчен дә чын күңеленнән борчыла, гаиләсен дә, бигрәк тә кечкенә оныгы Камиләне, яратып, мәш килеп яши.

# Седая древность и вечная молодость Сабантуя

Шамиль ГАЛИМОВ



Сабантуй - самый популярный и самый любимый татарским народом национальный праздник. Когда он зародился и вошел в земледельческую культуру татарского народа - точных сведений нет. На этот счет у историков и специалистов-культурологов имеются разные суждения. Самое раннее упоминание о Сабантуе встречается на древней эпитафии (надгробном камне) булгарского периода, датированной ориентировочно 1292 годом. На ней написано (в латинской транскрипции) - Saban tui kon ati, то есть «День Сабантуя».

Конечно, сам праздник возник не 721 год назад, а намного раньше. Ведь понятно, чтобы день кончины этого безвестного человека был отмечен как день проведения Сабантуя, праздник должен быть стать привычным и символичным. О конных скачках, которые составляют, как мы знаем, непременный элемент праздника Сабантуй, писал Махмуд Кашгари в XI веке, а о борьбе на поясах - Юсуф Баласагуни в тот же период.

Идегей - главный герой знаменитого одноименного эпоса золотоордынской эпохи в споре со своим сыном Нурадыном говорит о себе:

*«Я как молния полон огня…*
*Если я с тобой поборюсь,*
*Одолею тебя в борьбе,*
*А поспоришь в беге со мной, –*
*Побежишь за моею спиной»*

***(Перевод Семена Липкина)***

Весенний праздник казанских татар 1505 года подробно описали составители «Истории Казанского царства, или Казанского летописца». А с конца 1760-х годов, после воцарения на российском престоле Екатерины II и последующего изменения государственной политики по отношению к мусульманам Российской империи, народные праздники татар получили второе дыхание. Архивные документы и разного рода путевые заметки российских и иностранных ученых много раз сообщают о Сабантуе как народном празднике, отмечаемом в магометанских, то есть татарских селениях.

Глубоко земледельческий характер праздника определил и время его проведения - перед началом весенне-полевых работ. В апреле или мае - в зависимости от района проживания татар и от погодных условий, позволяющих начать работу в поле. И завершался он коллективным выходом крестьян на пашню для закладки коллективной борозды. Так что в прежние времена Сабантуй имел значение первого шага очередного земледельческого года. Например, в рукописном календаре 1775 года, обнаруженном в селе Митряй Бугульминского уезда тогда Оренбургской, а потом Самарской губернии днем проведения Сабантуя определено 4 апреля.



С началом татарского возрождения в конце XIX века и, особенно, в начале XX века Сабантуй превратился в неотъемлемую часть татарской народной культуры. Со своей определенной системой традиций, которые изменялись и дополнялись в соответствии с новыми веяниями времени и конкретными условиями проведения праздника. С этого времени, когда все больше и больше татар стали жить в городах, он перестал быть чисто деревенским праздником. Тогда среди татар появился особый слой интеллигенции и стал расширяться круг людей, умеющих организовать, собрать людей на массовое мероприятие и провести публичные и спортивные состязания. Но еще большее значение имело то обстоятельство, что в то же время начал быстро укрепляться класс татарской буржуазии, представители которой проявляли готовность и имели возможность оплатить расходы на проведение Сабантуя, а также благотворительных мероприятий, содержание медресе и мектебов, оказывать помощь бедным ученикам.

Собственно, татарское национальное возрождение дореволюционного периода опиралось на эти

три силы: нарождающуюся интеллигенцию, меценатов, а также на прогрессивную часть мусульманского духовенства.

Сабантуй в городе Самаре имеет более чем вековую историю. Имеются косвенные сведения о его проведении в 1908 году. Поиск, изучение документов, других свидетельств об этом событии - в ближайших планах исследователей истории самарских татар. А вот Сабантуй 1914 года стал заметным в общественной жизни всей губернии, собравшем жителей со многих уездов губернии, о нем писали русские газеты. Состоялся он 18 (31) мая, за два месяца до начала первой мировой войны, на ипподроме, который находился на месте нынешних клиник медицинского университета, на Московском шоссе.

Вот что писала через несколько дней газета «Голос Самары»:

«18 мая почти все мусульманское население города двинулось за город на



ипподром, на национальный праздник Сабан-туй (праздник весны), впервые устраиваемый местным мусульманским обществом после продолжительного перерыва.

Состоятельные мусульмане ехали на собственных лошадях, в городских экипажах целыми семьями, с запасом провизии на целый день. Менее состоятельные, собравшись несколько семей, вместе тащились в колымагах и рыдванах. К 12 часам дня (начало праздника) ипподром имел далеко необычный вид: переполненные ложи, трибуны, площадки перед трибунами, все это покрыто почти сплошной массой мусульманской публики. Распорядители с разноцветными лентами через плечо и цветными бантами на груди наводили порядки. На вышке расположился трибунал с подарками для победителей - главным образом - полотенцами с широкими каймами.



Торжество началось борьбой на свободных поясах охотников. Особенной симпатией зрителей пользовался Зиннатулла Гиньятуллов, в первом отделении положивший 6 человек и все это проделывал с самым наивным добродушным видом и, временами как будто сам удивляясь собственной силе и сноровке.

Поражал необыкновенной силой и красивыми приемами Якуб Биктаев, положивший также и Гиньятуллова. Али Мухаметов и другие борцы, выступившие с попеременным успехом, все они пользовались вниманием чрезвычайно шумной и экспансивной публики и были награждены полотенцами за каждую победу. После двухчасовой борьбы был сделан антракт, а затем был бег малышей на дистанцию одна верста. Из юных бегунов первым, чуть высунув язык, прибежал Калимулла, вторым Загрутдин и третьим Хасан. Босоногие победители получили полотенца. Первого прибежавшего пришлось даже поднять от земли, чтобы дать возможность увидеть всем.



Комичные картины пришлось наблюдать перед бегом взрослых: охотники, для облегчения при беге, раздевались до белья тут же, на глазах многотысячной толпы, причем весь снятый шурум-бурум предупредительно хранился кем-то из зрителей. Первому пробежавшему 2-верстную дистанцию - Шарифу была торжественно вручена феска, второму - Давлетдину - жетон серебряный, третьему - Зарифу - полотенце.

Совсем обенный вид имели велосипедные состязания. Из 10 велосипедистов только двое мусульман, остальные русские. Дистанцию в 4 версты по тяжелой, покрытой травой дорожке прошел в 13 минут Зотов, получивший потом полотенце, Рудьянов, в 15 минут, получивший жетон, Панков, одновременно сравнявшись уже у финиша, полотенце, Щукин, 17 минут, полотенце.

Чисто мусульманский характер носило состязание, так называемое, бег в мешке, на 50 саженей. На голову и ноги одевались мешки, и в таком виде спортсмены прыгали или семенили ногами, кувыркались, падали, вызывая гомерический хохот у зрителей. Победителем допрыгал Мингалей и был награжден жетоном, вторым добрался Шахинияз, получивший кепку, затем Гимазетдин и Хатимулла - полотенца.

Джигитовки, ожидаемой с таким нетерпением, не было, если не считать случайно заскакавшего в публику старика на старой клячонке, который под смех публики положительно не знал,

где ему выйти из сомкнутого круга зрителей.

Затем опять борьба, доставание полтинника со дна таза, наполненного кислым молоком. Охотников до этого спорта только пять, причем лишь один сумел достать языком полтинник, еще одному же таз опрокинули на траву, где он и разыскал монету, трое отошли ни с чем. Нужно было видеть эти лица, вымазанные густой белой массой, которые спортсмены сфыркивают прямо на зрителей.

Нельзя сказать, что эстетическим зрелищем представлялось следующее. Выстроившейся в босой команде ребятишкам было дадено по французской булке, с обоих концов вымазанной, очевидно, в киселе. Нужно было съесть скорее. Не обошлось без плутней: некоторые мальчишки, объев мазанную булку, сухую прятали за рубашонку, но были уличены в этом к великому стыду. Победители получили жетон, кепку и полотенце…

Праздник закончился, уже когда солнце начало садиться за стоящие неподалеку деревья. Валовой сбор достиг не менее 500 рублей.

Площадь у ипподрома представляло какое-то становище: всюду выпряженные лошади, на дрогах и колымагах ревели некоторые ребятишки, про которых забыли увлекшиеся родители.

Подъем настроения у мусульманского населения - огромный.

Вероятно, этот день по богатству впечатлений, в особенности для женщин, останется надолго в памяти…»

Весь сбор от Сабантуя 1914 года пошел в помощь бедным учащимся русско-татарских школ Самары.

…Вскоре началась война, потом произошла революция 1917 года и была кровопролитная гражданская война, коренным образом изменившие ход истории нашей страны, да и всего мира тоже. В 1921 году случился страшный голод. Людям на много лет стало не до праздников.

В Самарской губернии о них, в том числе Сабантуе, вспомнили только в середине 20-х годов. Именно с этого времени он приобретает новый оттенок, начинаеи проводиться в форме подведения итогов весенне-полевых работ. Кроме того, Сабантуй был выбран новыми властями как метод изживания «старых религиозных предрассудков» и пропаганды новых социалистических обрядов. В 1926 году, как артподготовка перед решительным наступлением на религию, во многих селах Самарской губернии партийные и советские органы провели Сабантуй. В инструкции Самарского уездного комитета ВКП (б) от 23 мая 1926 года, например, указывалось, что самой положительной чертой предстоящего Сабантуя будет неучастие в нем мулл. Организаторы нового, советского Сабантуя прилагали большие усилия для того, «чтобы население почувствовало: Сабантуй разумнее и веселее, чем всякие религиозные праздники, вроде Ураза-байрама и Курбан-байрама, нужно пение из комсомольского репертуара, лучше хором». Однако новая идеология народного праздника нисколько не отпугивала татарское население от древнего обычая, Сабантуй и в этих условиях был и оставался любимым и желанным. Тем более на многих праздниках были введены новые элементы, которые пришлись по душе людям: выступления художественных коллективов, соревнования по футболу, торговля дефицитными товарами и другие.

В отчетах из некоторых сел о Сабантуе 1926 года отмечается, что «все попытки мулл провести праздник под своим влиянием и в своих интересах не имели результата, Сабантуй впервые в этом году прошел под руководством партии».

В 1928 году в Самаре состоялся третий Сабантуй. Он проходил на спортивной площадке, на месте которой через несколько лет был воздвигнут Дом промышленности. Мы пока не очень много знаем об этом интересном событии, организованном татарской секцией клуба национальных меньшинств имени Сталина - картину праздника еще предстоит восстановить. Известно только, что в нем участвовали не только татары - коренные жители Самары, но прибывшие из деревень на работу на 42-й завод («ЗиМ»), станкостроительный завод, который находился неподалеку от места Сабантуя - на берегу Волги напротив Струковского сада. Главным организатором выступил активист по имени Садри. Его помнят самые старые жители города. А в остальном все было как на Сабантуе: татарская борьба, игры, концерт и все остальное доброе, веселое и разумное.

Так что история помнит разные праздники Сабантуй. В том числе, самый памятный, что должен был состояться в воскресенье, 22 июня 1941 года. Он уже успел начаться, организаторы и участники вышли на игровые площадки и на сцену, как в полдень, в 12 часов через радио вся советская страна услышала весть о начале Великой Отечественной войны. Многие участники соревнований, молодые люди призывного возраста и отслужившие в армии, прямиком с майдана побежали в райвоенкоматы, чтобы уйти на фронт.

Многие батыры предвоенных Сабантуев погибли в боях за Родину. А некоторые вернулись инвалидами, как, например, Хазей Бикташев. Но он и после войны, с одной рукой, выходил в родном Абдикеево на борцовскую площадку и часто бросал на зеленый ковер травы своих соперников. Именно в таких боях ковалось мастерство его сына - будущего дважды чемпиона Европы, победителя и призера других многочисленных соревнований, заслуженного мастера спорта СССР Хабиля Бикташева, ныне главного судьи соревнований по татарской борьбе «керэш» в Самарской области.

А на Сабантуях в селе Алькино Похвистневского района получал первый опыт еще один наш знаменитый



спортсмен, чемпион мира 1955 года по классической (теперь греко-римской) борьбе, заслуженный тренер РСФСР Наиль Гареев.

Все советские годы Сабантуй развивался и наполнялся новым содержанием. Его доброй традицией стало чествование при всем народе людей труда - не только хлеборобов и механизаторов, но и тружеников ферм, сельских учителей, врачей, многодетных матерей, ветеранов войны и труда.

Во всех крупных татарских селах Камышлинского (с 1962 по 1991 год они все входили сначала в Похвистневский, а потом в Клявлинский), Похвистневского, Шенталинского и других районов Сабантуй проводился каждое лето. Несколько раз его организовывали в

Теплом Стане Кошкинского района. В условленный июньский день малая родина собирала на площадке Сабантуя не только жителей того или иного села, но и односельчан, проживающих в различных городах области и далеко за ее пределами, и становилась местом встречи родных и друзей.

Перестройка конца 80-х годов вдохнула в древний татарский праздник Сабантуй новую жизнь. К тому времени десятки тысяч татар проживали в Куйбышеве, Тольятти, Сызрани и других городах области. Идея национального возрождения призвала в ряды энтузиастов татарской культуры десятки представителей творческой и технической интеллигенции. Благодаря этому Сабантуй прочно «прописался» в городе.



Первый городской Сабантуй нового времени состоялся в Тольятти в 1987 году и проводился в рамках празднования 250-летия Ставрополя-на-Волге. Руководителем оргкомитета был мастер спорта СССР по самбо и вольной борьбе Шамиль-ага Гайнуллов. Первым батыром стал молодой человек по фамилии Сагдинов. С тех пор тольяттинские татары и башкиры ежегодно собираются на Сабантуй в живописном месте на берегу Волги.

В начале 1989 года в Куйбышеве организовался татарский культурный центр «Туган тел», одним из первых мероприятий которого стал так называемый «Зимний Сабантуй» во Дворце спорта авиационного завода 24 февраля. Необычное сочетание двух этих слов в названии праздника объясняется очень просто. В организаторах было столько энергии и желания сделать полезное и нужное для своего народа, что на придумывание новых, как мы теперь сказали бы, брендов, не было времени - ухватились за самое близкое, родное и понятное людям.

А летом того же 1989 года, 24 июня, на куйбышевском ипподроме с большим успехом прошел «настоящий» Сабантуй: с татарской национальной борьбой, конными скачками, большой концертной программой. В его подготовке и проведении приняли участие Рашид Абдуллов, Рафик Абдеев, Асия Ахметова, Наиля Багаутдинова, Шамиль Багаутдинов, Хабиль Бикташев, Шамиль Галимов, Эльсор Кабиров, Иршат Каюмов, Альфия Махмутова, Фархад Махмутов, Азат Надиров, Ахмет Нафигин, Асия Нугманова, Гельсина Нуруллина, Минахмет Сагиров, Марат Сафин, Мазгут Шакмаев, Шаукат Хайбуллов, Равиль Ягудин и Мансур Ямалетдинов. После 1993 года самарский Сабантуй с ипподрома на два года “переехал” на стадион “Металлург”, а с 1996 года местом его постоянного проведения стал парк имени Гагарина. Главным организатором многие годы выступало (и выступает до сих пор) общество “Туган тел” (его президентом сейчас является И. Г. Шакуров).

Потом в проведение главного мероприятия татарской национально-культурной жизни стали подключаться новые организации - городская татарская национально-культурная автономия (Р. Т. Хузин), а теперь и областная ТНКА (М. М. Халиуллов). Вслед за Самарой и Тольятти татарские организации стали проводить “свои” Сабантуи в Сызрани, Похвистнево, Новокуйбышевске, а просто активисты из числа местных жителей - в селах Ново-Урайкино, Старое Фейзуллово, Мулловка и других. В 2010 году село Алькино стало местом проведения первого Всероссийского Сабантуя. Сельский Сабантуй областного масштаба нынче в первый раз пройдет в Камышле 8 июня.

В этом году самарский Сабантуй проводится в 25 раз. За эти четверть века через сцены, борцовсие и игровые площадки самарского Сабантуя прошли сотни артистов, борцов, спортсменов других видов и просто желающих помериться своим мастерстовм и силой. Он стал символом единения татарского народа, его стремления сохранить родной язык и национально-духовные традиции, добрососедских отношений с другими народами. Источники, которые многие века подпитывают Сабантуй, являются основой его вечной молодости и постоянного обновления.



# ПРАЗДНИК ПЛУГА И ВЕСЕЛЬЯ

## Камышлинский район готовится к приему гостей со всех уголков губернии

*В селе Камышла 8 июня пройдет первый областной сельский Сабантуй – праздник, знаменующий собой окончание весенних полевых работ.*

**Елена ПЛАТОНОВА**

Для Самары Сабантуй - не новость. В парке имени Гагарина татары ежегодно стараются воссоздать обстановку этого праздника, со всеми его традициями и обычаями. Это и борьба куряш, и битва подушками на бревне, и национальные песни и танцы, а также угощения из блюд татарской кухни. Но исторически Сабантуй все-таки сельский праздник, не случайно его отмечают летом.




Именно в тот период у сельчан после окончания сева, перед началом косовицы появляется небольшая передышка. Так что логичнее всего, да и правильнее было бы народные гулянья проводить не в городском парке, а на широких деревенских просторах.

И если в городе Сабантуй - однодневный праздник, то в сельской местности он, как правило, растянут по времени и состоит как минимум из двух частей - ритуального сбора подарков и майдана. Не обходятся в селах и без самого кульминационного момента - конных скачек, собирающих лучших наездников. На камышлинской земле все это обязательно будет - и дурманящий запах плова с шашлыком, и атмосфера всеобщего веселья, разделить которую традиционно могут не только татары, но и люди других национальностей, потому как Сабантуй носит поистине общенародный характер. Это праздник для всех.

Из разговора с заместителем главы района по социальным вопросам, председателем оргкомитета по подготовке и проведению Сабантуя Минсагитом Шайхутдиновым стало ясно, что программа праздника обещает быть богатой, насыщенной и продуманной до мелочей. Тем более что опыт имеется - праздник плуга и веселья здесь отмечают на районном уровне каждый год.

Областной сельский Сабантуй не станет исключением. Еще за неделю до основных гуляний всадники с музыкой и песнями начнут разъезжать по селу, собирая призы для победителей предстоящих соревнований. Как правило, это вышитые платки или полотенца.

К примеру, раньше самым большим и весомым подарком для батыра считалось вышитое полотенце из рук «последней» невесты - то есть той, кто совсем недавно, самой последней из общего числа невест, вышла замуж.

Есть и другая, не менее интересная традиция, когда лучшему в борьбе куряш полотенце вручает победительница местного конкурса красоты. Но и в этом случае она вышивает его своими руками.

Помимо местных творческих коллективов (как всегда, на сцену выйдут не только татарские, но и русские, мордовские, чувашские ансамбли), перед гостями праздника выступят артисты из Татарстана.

Увидят зрители и традиционное торжественное шествие, только на этот раз на майдан выйдут не трудовые коллективы и передовики производства одного района, а делегации из всех сел губернии с компактным проживанием татар.

Подготовка к празднику вышла на финишную прямую, приезжих ожидается много, но камышлинцы к этому готовы. Так уж повелось, что на селе Сабантуй - традиционно еще и время приема гостей, встречи родных и близких. В эти дни в родное село ежегодно приезжают те, кто с ним связан, кто здесь родился и вырос, что называется, прикипел сердцем и прирос корнями.

Наша справка:

Камышлинский район в простонародье называют маленьким Татарстаном, потому как 81 процент местного населения - татары.

### ПРОГРАММА

**проведения первого областного сельского татарского национального праздника Сабантуй-2013 в муниципальном районе Камышлинский 8 июня 2013 года**

| | |
|---|---|
| 09.00 | Встреча и регистрация гостей. |
| 10.00 | Конные скачки. (Ипподром) |
| 10.30 | Посещение презентационной площадки татарских сел. (Майдан) |
| 11.00 | Торжественное открытие праздника. |
| 11.15 | Приветствие и поздравление Главы района Р.К. Багаутдинова. |
| 11.30 | Шествие делегаций татарских сел Самарской области. |
| 11.30 | Работа детской игровой площадки. |
| 11.45 | Выступления почетных гостей. |
| 12.00 | Торжественные награждения |
| 12.30 | Соревнование по национальной борьбе «Курэш». |
| | Концерт звезд татарской эстрады РТ (Большая сцена) |
| | Игры и состязания на майдане. |
| 13.00 | Концерт коллективов художественной самодеятельности (Малая сцена) |
| 15.30 | Награждение победителей национальной борьбы и состязаний. |
| 15.40 | Торжественное закрытие праздника. |
| 22.00 | Татарская дискотека для молодежи. (Площадь перед РДК) |



# САБАН ТУЕ – УЛ БЕР КӨНЛЕК, АНЫҢ РУХЫ ДӘВАМЛЫ...

***Әйе, чыннан да, татарларның иң яраткан бәйрәмнәренең берсе булган Сабан туе бер генә көн узса да, аңардан калган тирән тәэсирләр халык күңелендә әле озак сакланырга мөмкин. Шәһәребездә ел саен үткәрелгән бу чараны күпләр зарыгып көтеп алалар, чөнки чын татар рухы хөкем сөргән әлеге бәйрәмнең байлыгы, милли колориты күп кешедә соклану, горурлык хисләре уята.***

Быел Самарда Сабан туе менә инде егерме бишенче тапкыр уздырылачак. Ә 1989 елның 24 июнендә ипподромда үткән иң беренче бу бәйрәмне күпләр хәтерлиме икән? Хәтерлидер. Чөнки милли рухка, милли чараларга сусаган татар халкы өчен ул бер зур бүләк, бер зур шатлык кебек кабул ителгәндер.

Сабан туе дигәч тә, шунда ук күз алдына бу бәйрәмнең йөзек кашы булган көрәш бәйгесе килеп баса. Самар Сабан туендагы көрәшне искә алгач исә, шунда ук олпат гәүдәле Хәбил Бикташев искә төшә. Гомумән, шәһәребездә узган бу бәйрәмдәге көрәшне аңардан башка күз алдына китерүе дә мөмкин түгелдер. Менә инде ничәмә еллар буе ул биредәге көрәш бәйгесенең баш судьясы булып тора.

6 - 7 яшеннән туган авылы Сабан туйларында көрәшеп үскән Хәбил әфәнде үз гомерен шушы спорт төренә багышлый. Армиягә китәр алдыннан егет авыл Сабан туенда батыр булып кала. Ул бәйгедә катнашкан Татарстанның көчле көрәшчеләрен җиңә ул.

Армиягә алынып, Самарда урнашкан милиция батальонында хезмәт иткәндә көрәш бәйгесендә катнашкан Хәбил монда да җиңүче исеменә лаек була. Аның сәләтен күреп алган тренер егет белән ныклап шөгыльләнә башлый. Шулай Бикташев бер ел эчендә спорт остасы була, ә тагын бер елдан соң Минск шәһәрендә үткән "Молодежные игры" бәйгесендә икенче урынны яулый.

Үз гомерендә Хәбил әфәнде самбо белән дә, дзюдо белән дә шөгыльләнә. Хәтта сумоны да калдырмый ул. Бу спорт төреннән Бикташев өч тапкыр дөнья чемпионатында өченче урынны ала.

Дзюдо буенча дөнья чемпионатында сигез тапкыр көмеш, дүрт тапкыр бронза һәм бер тапкыр алтын медаль призеры, Советлар Союзы һәм Европа чемпионы, атказанган спорт остасы, "Хөрмәт билгесе" ордены иясе, 15 ел буе Самар өлкәсенең

дзюдо федерациясе президенты булып торган Хәбил Бикташевның олимпиада чемпионы булу хыялы гына тормышка ашмыйча калган. Ике тапкыр олимпиадага барырга тиеш булган



спортчы төрле сәбәпләр аркасында анда эләгә алмый.

*- "Һәр солдат генерал булырга хыяллана", дигәндәй һәр спортчы олимпиада чемпионы булырга тели. Минем дә шундый хыялым бар иде, тик ул, кызганычка, тормышка ашырылмыйча калды,* - ди Хәбил әфәнде.

Без көрәш остасы, чемпион Хәбил әфәнде Бикташев белән очрашып, аңардан Самар Сабан туе, анда үткәрелгән милли бәйгебез тарихы турында сораштырдык.

**- Хәбил әфәнде, Сез – Самарда иң беренче Сабан туен оештыруда катнашкан кеше. Шушы еракта калган 1989 елга кайтып килик әле. Бу эш ничек башланып китте һәм милли бәйрәмебезне оештыруда тагын кемнәр катнашты?**

- Сабан туеның чишмә башында милли хәрәкәтебезнең иң актив кешеләре тора - Рәшит Абдуллин, мәрхүм Равил Яһүдин, Илгиз Колючев, Шамил Баһаутдин. Бигрәк тә инде Рәшит әфәнде Абдуллин бу эш өчен янып-көеп йөрде. Нәкъ ул минем яныма килеп: "Әйдә, Хәбил, шәһәребездә Сабан туе үткәрик", - дигән тәкъдим ясады да инде.

Шулай барыбыз бергә бу эшкә җигелеп, матургына бәйрәм уздырдык. Беренче Сабан туен оештырырга Сания Каюмова, Вазыйх Мөхәммәтшин, Дания Ваһапова һәм башкалар матди ярдәм күрсәттеләр.

Беренче Сабан туенда көрәш тә, бәйгеләр дә, концерт та булды. Оештыручыларның, бәйрәмдә катнашучыларның берсе дә акча эшләр өчен йөрмәде, барысы да милләт, халык өчен бушлай тырышты. Көрәш бәйгесендә җиңгән батырга бирер өчен сарыкны мәрхүм Равил абый Яһүдин китерде. Хәтта гади халык арасында да күпләр үзләре белән бүләкләр алып килгәннәр иде. Көрәштә мин баш судья булдым һәм, гомумән, бәйрәмне алып бардым. Беренче Сабан туенда абсолют батыр булып Самарда яшәүче танылган көчле көрәшче Әлфик Хәлиуллин калды. Ул тумышы белән



Татарстанның Аксубай районы Иске Ибрай авылыннан.

Шуннан инде Сабан туен ел саен үткәрә башладык. Башта ул ипподромда уза иде. Ул чактагы губернаторыбыз Константин Титов бер-ике бәйрәмдә хәтта башыннан ахырына кадәр булган иде.

Аннан инде ипподром үзәктән ерак урнашканга, биредә ачык җирдә бик кызу булганга, Сабан туен Гагарин исемендәге паркка күчерергә туры килде. Һәм бу дөрес тә, минемчә. Халык күл янында, агачлар күләгәсендә рәхәтләнеп көрәш, концерт карап утыра. Ә быел, юбилей Сабан туенда, милли бәйгебез футбол кырында, тамашачыларга эскәмияләр куелып, зурлап үтәчәк.

**- Беренче елларда Сабан туйларын үткәрү өчен акча җыю җиңел булмагандыр?**

- Әйе, әлбәттә, бу яктан авыр булды. Ярдәм сорап бик күп кешегә мөрәҗәгать итәргә туры килә иде. Шулай бер елны Сабан туена эшкуар Ринат Яһүдин, "Сок" фирмасы җитәкчесе Юрий Качмазов машина, ә шәһәр башлыгы Георгий Лиманский фатир да биргәннәр иде.

Ә менә үзебезнең татар халкы, татар эшкуарлары беренче елларда бу эштә актив катнашмыйлар иде. Шөкер, соңгы елларда татар эшмәкәрләре, милли оешмалар җитәкчеләре, ниһаять, милли тормышка йөзләре белән борыла башладылар. Соңгы арада Фәхретдин Канюкаев, Минәхмәт Хәлиуллов, Ильяс Шәкүров Сабан туйларын бик матур, бай итеп уздырып киләләр. Тик менә, кызганычка, алар арасында бердәмлек кенә җитеп бетми. Өчесе дә менә дигән, лаеклы ир-егетләр. Әгәр дә алар берләшсәләр, шундый көчле бер йодрык килеп чыгар

иде бит. Без дә ярдәмгә килергә әзер. Без авылдашым, компаньоным, көрәш буенча тренер Илшат Бикташев белән берничә еллар Сабан туенда катнашучы көрәшчеләр өчен бүләкләр биреп тордык.

**- Беренче Сабан туена күп халык җыелдымы һәм бәйрәмнән канәгать калдымы?**

- Әйе, күп халык җыелды, ипподромдагы утыргычларда бер генә буш урын да калмаган иде. Көрәшне карауЧылар да бихисап булды. Самарда беренче Сабан туе уздырылуы турында ишеткәч, башка төбәкләрдән дә кунаклар килде - Татарстаннан, Ульян, Тольятти шәһәрләреннән. Гомумән, халыкның мондый чараларга сусаган булуы күренеп торды. Апалар, әбиләр арасында: “Сабан туе матур узды,



хәтта яшь чакларыбыз искә төште”, диючеләр дә булды. Ул вакытта бит әле реклама бүгенге көндәге кебек актив түгел иде. Шәһәрнең берничә җирендә Сабан туе турында афиша элеп куйдык. Ә инде татарлар бу турыда берберсеннән ишетеп белделәр.

**- Соңгы елларда Самар Сабан туенда көрәш бәйгесендә катнашучылар күп. Элек тә шулай идеме?**

- Әйе, беренче Сабан туенда да, аннан соңгы елларда да көрәш бәйгесендә катнашучы ир-егетләр күп иде. Безнең беркемгә дә юлны каплаганыбыз юк, теләгән һәр кеше көрәшә ала. Безгә төрле төбәкләрдән дә бик күп көрәшчеләр килә. Берсен дә кире борып җибәргәнебез юк, лаек булган бүләкләрен биреп, озатып калабыз.

**- Көрәш бәйгесендә баш судья булуы җиңел түгелдер?**

- Көрәш бәйгеләрендә ыгы-зыгы, тавыш килеп чыгуы, хәтта сугышкан очраклар да булуы турында ишетергә мөмкин. Тик, шатлыкка, безнең Сабан туйларында беркайчан да мондый хәлләрнең булганы юк, барысы да тыныч, матур узды. Иң мөһиме - судья гадел булырга тиеш. Әгәр дә берәр көрәшчене якласаң, моны халык, әлбәттә, күрә, аңлый һәм шуннан тавыш та чыгарга мөмкин. Без, шөкер, беркайчан да бәхәскә калдырмадык.

**- Шушы 25 ел эчендә Самар Сабан туенда берничә тапкыр абсолют батыр калган көрәшчеләр дә бардыр?**

- Шундый көрәшчеләрдән иң беренче булып алда әйтеп үтелгән Самар егете Әлфик Хәлиуллинны атар идем. Ә бер елны көрәш бәйгесендә кызыклы хәл булды. Шенталы районының Әбдеки авылыннан килгән 70 килограмм авырлыктагы Габделхәй Вәлиев 120 килограмм авырлыктагы Әлфик Хәлиуллинны җиңеп, абсолют батыр исемен яулаган иде. Халык моңа шаккатты, әлбәттә.

Шулай ук Татарстанның Чаллы шәһәреннән Ильяс Гилаев, Самардан Владимир Чегуров, Тольяттидан Максим Зимин да - шәһәребездә узган Сабан туйларында берничә тапкыр абсолют батыр исемен алган егетләр. Бер елны Максим Зимин хәтта икенче олимпиада уеннары призерын - грузин егетен җиңгән иде. Безнең Сабан туйларында әнә шундый көчле, танылган көрәшчеләр катнашуы бәйрәмебезне тагын да күтәрә, әлбәттә.

Шуны да әйтәсем килә: безгә Татарстанның Нурлат, Зәй, Баулы районнары башлыклары үзләренең көрәшчеләре, артистлары белән бергә килеп, Сабан туйларыбызны уздыруда актив катнашалар, рәхмәт яугыры. Бу Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев вакытында да шулай иде. Ә хәзер Рөстәм Миннеханов каршында тагын да киң колач җәйде.

**- Хәбил абый, соңгы елларда Самар Сабан туйларында еш кына башка төбәкләрдән килгән көрәшчеләр җиңә. Бу нидән, дип уйлыйсыз?**

- Әйе, бигрәк тә Татарстаннан килүче ир-егетләр җиңә дияр идем. Эш шунда ки, анда һәр шәһәрдә, һәр район үзәгендә, хәтта һәр авылда Спорт сарайлары гөрләп эшли һәм көрәш бәйгесе белән ныклап шөгыльләнәләр.

**- Ә Самарда көрәш бүген нинди дәрәҗәдә, дип уйлыйсыз?**

- Башка регионнар белән чагыштырганда бездә көрәш уртача дәрәҗәдә, ә инде Татарстанга караганда күпкә түбәнрәк. Ә болай безнең өлкәдә көчле көрәшчеләр бар. Әйтик, Самарда, То-



льяттида, Похвистнево районында. Менә өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Минәхмәт Хәлиуллов “Яктылык” мәктәбендә балалар өчен көрәш секциясе ачып, бу спорт төрен үстерүгә үз өлешен кертә. Малайлар белән шөгыльләнүче тренерлар Рәшит Үтәшев, Руслан Йосыповны да мактап телгә аласы килә.

**- Сез үзегез дә шәһәребездә көрәшне үстерүгә өлешегезне кертәсез бит?**

- Әйе, минем Самарның “Динамо” стадионында дзюдо буенча “Бикташев мәктәбе” бар. Сабан туйларында узган көрәш бәйгеләренә, турнирларга булышкалыйм. Татарстанда шундый бәйгеләр үткәрергә дә ярдәм иткәлим. Аннан мине “Татар көрәшен үстерүдә актив катнашкан өчен” медале белән дә бүләкләделәр. Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә бер сигез еллар рәттән Самар өлкәсеннән көрәшчеләрне алып барып, андагы балалар йорты өчен хәйрия турниры уздырдык. Бөтен спортчылар алган бүләкләрен шушы балалар йортына биреп калдыралар иде.

**- Хәзер җан-фәрманга юбилей Сабан туена әзерләнәсездер инде?**

- Әйе, әзерлек бик кызу бара. Шуны әйтәсе килә: үз вакытында губернатор Константин Титов безнең Сабан туйларын калдырмый иде диярлек. Хәзер менә Николай Меркушкин да бәйрәмебезгә әзерлекне хәтта үз контроленә алды һәм оештыру эшләрендә дә актив катнаша. Рәхмәт аңа.

**- Хәбил абый, җавапларыгыз өчен рәхмәт. Сезгә исәнлек-саулык, зур уңышлар теләп калабыз һәм быелгы юбилей Сабан туе шулай ук матур булып үтәр, дип ышанабыз.**

***Әңгәмәдәш – Миләүшә Газимова.***

# САМАРЦЫ ОКУНУЛИСЬ В ТАИНСТВЕННЫЙ МИР ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ

*25 апреля 2013 года в ДК им. Литвинова прошел областной конкурс чтецов татарской поэзии. Организатором мероприятия выступило Самарское областное татарское общество «Туган тел» при финансовой поддержке ООО «ИПОЗЕМбанк».*
*Цель конкурса – формирование у соплеменников интереса к татарской поэзии, к художественной литературе, развитие эстетического вкуса и творческих способностей, выявление и поддержка талантливых сородичей.*
*Мероприятие было приурочено к 127-летию великого татарского поэта Габдуллы Тукая.*

**Римма НУРЕТДИНОВА**



Вечер открыли и вели члены СОТО «Туган тел» Фархад и Альбина Махмутовы, взвалившие на свои плечи основную работу по организации и проведению мероприятия.



В четырех возрастных категориях конкурса сошлись 37 чтецов. В одном зале собрались вместе люди различных поколений и сфер деятельности. Но всех объединила любовь к поэзии и к своему родному языку.

Каждый чтец был по-своему уникален. Своей дикцией, интонацией, тембром, темпом, ритмом, возгласами передавал настроение, доносил смысл произведения.

Было всё: страх перед сценой и дрожь, робость и неуверенность в голосе, и, наоборот, сильные чувственные интонации … Было – всё и было – по-разному. Сколько участников, столько и темпераментов, столько и способов достижения цели.

Звучали не только великолепные стихи татарских классиков, некоторые участники представили слушателям и самостоятельно сочинённые произведения.

В рамках мероприятия перед зрителями выступили казанские гости – заслуженный деятель искусств Республики Татарстан, поэтесса, корреспондент отдела литературы и искусства редакции газеты «Сабантуй» Йолдыз Шарапова и корреспондент журнала «Мәгърифәт» (г.Казань) Надия Шайхутдинова. Также самарская поэтесса Наиля-ханым Хусаинова прочитала свои новые стихи.

Мастерство конкурсантов оценивали члены жюри, куда вошли президент Самарского областного татарского общества «Туган тел» И.Г.Шакуров, заслуженный деятель искусств Республики Татарстан, поэтесса, корреспондент отдела литературы и искусства филиала ОАО «ТАТМЕДИА» «Редакция газеты «Сабантуй» Йолдыз Шарапова, главный редактор самарской областной татарской национальной газеты "Бердэмлек" ("Единство") Р.Н.Аглиуллин, главный редактор самарской областной национально-культурной и духовно-просветительской газеты «Сэлам» («Мир») Ф.Х.Шириязданов, корреспондент журнала «Мэгърифэт» (г.Казань) Надия Шайхутдинова, учитель татарского языка и литературы школы «Яктылык» г. Самара Ф.Н.Гилязова.

По итогам конкурса определились победители по возрастным группам.

Среди 10 участников от 6 до 9 лет первое место занял 9-летний Айдар Фаляхов из села Денискино Шенталинского района. Он великолепно исполнил стихотворение народного поэта Республики Татарстан Роберта Миннуллина «Энекәш кирәк миңа". Двоюродные сестры – 8-летняя Алия Биксалиева и 9-летняя Исламия Гарипова из города Самара заняли 2 и 3 места соответственно. Они прочитали стихотворения, написанные их бабушкой Илхамией Гариповой.

Лучшим чтецом среди 11 участников в возрасте от 10 до 13 лет стал 11-летний Рамиль Хамзин из села Денискино Шенталинского района. Он выступил со стихотворением местного автора Шагиды Галимовой «Денисем – татлы җимешем!".

Второе место у 13-летнего ученика школы "Яктылык" г.Самара Сабира Галимуллина (Г.Зайнашева "Солдат гармуны"), а третье – у 12-летнего Айнура Зарипова (Рәшит Бәшәров "Мин бит – татар малае!").

Среди 6 старших чтецов от 14 до 17 лет лучшей стала 16-летняя Лилия Галиуллина из с.Денискино Шенталинского района. Ученицы школы "Яктылык" г. Самара Эльвира Нигматуллина (Муса Джалиль, «Яшь ана») и Гузель Субеева (Габдулла Тукай, «Милли моңнар") заняли 2 и 3 места соответственно.

Среди взрослых 11 конкурсантов первое место досталось Гульназ Биксалиевой, которая прекрасно исполнила стихотворение «Яши белсәң», написанное ее матерью – Илхамией Гариповой. Ей достался главный приз – плазменный телевизор. Второе место у Айсылу Мустакаевой (Сибгат Хаким "Клиндер эзлим"), а третье – у Нурании Мухутдиновой (Дания Аглямова "Тукай бар чакта").

Организаторы мероприятия и члены жюри поздравили победителей и поблагодарили всех участников конкурса за их огромный труд и талант.

Несмотря на пустующие места в зале, мероприятие удалось. В конкурсе царила доброжелательная атмосфера. Благодаря великолепному исполнению стихов конкурсантами и участники, и слушатели окунулись в таинственный мир татарской поэзии.

# Самарлылар серле татар шигърияте дөньясына чумдылар

***2013 елның 25 апрелендә Самарның Литвинов исемендәге Мәдәният сараенда беренче тапкыр татар шигырьләрен сәнгатьле итеп башкаручылар бәйгесе булып узды. Ул бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 127 еллыгына багышланган иде.***

***Бәйгене “Ипозембанк” җаваплылыгы чикләнгән оешманың матди ярдәме белән өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте оештырды.***

***Чараның максаты – милләттәшләребездә татар шигъриятенә кызыксыну, туган телебезгә мәхәббәт уяту, хөрмәт хисләре тәрбияләү, сәләтлеләрне табу һәм тамашачы хозурына чыгару иде.***

***Кичәне “Туган тел” оешмасы әгъзалары – чараны үткәрүгә күп көч салган Фәрхәт һәм Альбина Мәхмүтовлар алып бардылар.***

**Римма НУРЕТДИНОВА**

Бәйгедә, яшь буенча дүрт төркемгә бүленеп, 37 конкурсант катнышты. Тамашачы залына шигърияткә битараф булмаган төрле чор кешеләре һәм төрле һөнәр ияләре җыелган иде.

Һәр конкурсант сәнгатьле укуга бөтен осталыкларын куеп, интонация, паузалар белән сөйләргә тырышты. Кемнәрдер татар әдәбияты классикларының иҗат җимешләрен башкарса, кайсылары үзләре язган әсәрләрен дә яңгыратты.

Әлеге чара кысаларында тамашачылар каршында Казан шәһәреннән килгән кунаклар - балалар шагыйрәсе, ”Сабантуй” газетасы хезмәткәре, журналист, Татарстан мәдәният министрлыгының А.Алиш исемендәге әдәби бүләге иясе Йолдыз Шәрәпова һәм “Мәгърифәт” журналы хезмәткәре Нәҗия Шәйхетдинова чыгыш ясадылар. Шулай ук җирле шагыйрә Наилә ханым Хөсәенова да үзенең яңа шигырьләрен укыды.

Бәйгедә катнашучыларның осталыкларын мәртәбәле жюри бәяләде. Аның составында өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте президенты Ильяс Шәкүров, Казан шәһәреннән килгән кунаклар - Йолдыз ханым Шәрәпова һәм Нәҗия Шәйхетдинова, өлкә татар “Бердәмлек” һәм “Сәлам” газеталарының баш мөхәррирләре Рәфгать Әһлиуллин һәм Фәрит Шириязданов, “Яктылык” мәктәбенең татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы Фәния Гыйләҗева булды.

Ниһаять, бәйгедә җиңүчеләренең исемнәре билгеле булды.

Кечкенәләр төркемендәге беренче урын Шенталы районы, Денис авылыннан килгән 9 яшьлек Айдар Фәләховка бирелде. Ул Роберт Миңнуллинның “Энекәш кирәк миңа” шигырен бик үтемле итеп сөйләп, залны әсир итте. Сеңелләр - Самар шәһәреннән 8 яшьлек Алия Биксалиева - икенче урынга, 9 яшьлек Исламия Гарипова өченче урынга лаек булдылар. Алар әбиләре – Иске Ярмәк авылында туып-үскән, Яңа Усман авылында гомер кичерүче Илһамия Гарипова иҗат иткән шигырьләрне сәнгатьле укуда зур осталык күрсәттеләр.







Ун-унөч яшьтәге балалар төркемендә шулай ук җирле шагыйрә Шаһидә Галимованың “Денисем – татлы җимешем” шигыре белән Денис мәктәбенең 5 сыйныф укучысы Рамил Хәмзин җиңеп чыкты. “Яктылык” мәктәбе укучылары Сабир Галимуллин – Гөлшат Зәйнәшеваның “Солдат гармуны” һәм Айнур Зарипов Рәшит Бәшәровның “Мин бит – татар малае” шигырьләре белән икенче-өченче урыннарны алдылар.





14-17 яшьтәге башкаручылар арасында Денис авылыннан килгән 16 яшьлек Лилия Галиуллина үзе язган “Туган авылым – Денисем” шигыре белән тамашачыны тирән дулкынландырды һәм беренчелекне алды. “Яктылык” мәктәбе укучылары Эльвира Нигъмәтуллина - Муса Җәлилнең “Яшь ана” һәм Гүзәл Субеева Габдулла Тукайның “Милли моңнар” шигырьләре белән икенче-өченче урыннарга чыктылар.



Олы яшьтәге шигырь сөйләүчеләр арасыннан Гөлназ Биксалиеваның чыгышы югары бәягә лаек булды. Ул бик сәнгатьле итеп әнисенең - Илһамия Гарипованың “Яши белсәң” шигырен сөйләде һәм беренче урынга лаек булды. Иң зур приз – киң экранлы телевизор да аңа хаклы рәвештә тапшырылды. Айсылу Мостакаева Сибгат Хәкимнең “Клиндерләр эзлим” шигыре белән икенче урынны алды. Ә өченче урынга Нурания Мөхетдинова Дания Абзалованың “Тукай бар чакта” шигыре белән чыкты.

Бәйрәмне оештыручылар һәм жюри әгъзалары җиңүчеләрне тәбрикләп, барлык катнашучыларга рәхмәтләрен белдерделәр. Шигырь бәйрәмендә катнашучы бер генә кеше дә игътибардан читтә калмады, барысына да истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Тамашачылар залында буш урыннарның күп булуына карамастан, шигъри җыен тирән эчтәлекле, тантаналы төстә узды. Ул рухи бердәмлек, иҗади туганлык чарасы буларак кабул ителде. Җылы атмосферада, югары поэзия мохитында үткән кичәдә барлык катнашучылар һәм тамашачылар серле татар шигърияте дөньясына чумдылар.

# Аның күңел түрендәге «манаралары»...

***Агалы-энеле Хуҗиннар турында Самарда белмәгән, ишетмәгән кеше аздыр, мөгаен. Аларның кечесе Рифкать Туктаргали улы менә берничә ел инде Самар шәһәренең татар милли-мәдәни автономиясенә җитәкчелек итә. Соңгы вакытларда аның катнашыннан башка бер генә милли чараның да, бәйрәмнең дә уткәрелгәне юктыр.***

**Рәфгать ӘҺЛИУЛЛИН. *«Бердәмлек».***

- Күп очракларда Тәлгать абыемның исеме ничектер читтәрәк кала төсле, - дип сөйли Рифкать Хуҗин, - ә бит матди ярдәмне күбрәк ул бирә, ул күрсәтә…

Тәлгать Туктаргали улы озак еллар Самар өлкәсенең һәм шәһәренең урта кул төзү предприятиеләренең берсе булган “Волгопродмонтаж” ябык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры булып эшләде һәм аны алдынгы предприятиеләр рәтенә бастыра алды, югары квалификацияле җитәкче һәм эшче кадрлар хәзерләде. Хәзер икегә - ябык һәм җаваплылыгы чикләнгән акционерлык җәмгыятьләргә бүленгән предприятиеләрне яшь җитәкчеләр җитәкли инде. Ә Тәлгать Туктаргали улы Хуҗин аларга күз-колак булып, директорлар советы рәисе вазифаларын үти. Бер үк вакытта ул “Ипозембанк” президентының киңәшчесе дә бит әле.

Үткән гасырның туксанынчы еллары ахырында элеккеге план институтын (хәзерге Самар экономика академиясе) тәмамлап, төрле урыннарда эшләп берникадәр тәҗрибә туплаганнан соң, ул Самарда үзенең шәхси кече төзү предприятиесен ачып җибәрә. Беренче мәлләрдә алар, биш-алты төзүче, шәхси фатирлар ремонтлау белән шөгыльләнәләр, ә торабара таралып килүче “Спецмонтаж” предприятиесенең мәйданчыкларын арендага алып, 50 - 60 кешелек төзелеш фирмасын оештыралар. Аларның бу коллективы менә таралам-таралам дип торган «Волгопродмонтаж» дәүләт төзү предприятиесен ябык акционерлык җәмгыяте итеп үзгәрткәннән соң, зур промышленность предприятиеләрен ремонтлау һәм реконструкцияләү белән шөгыльләнә башлый. Тәлгать Туктаргали улы Хуҗин яңа фирманың генераль директоры итеп сайлана.

Шул тынгысыз беренче көннәрдән хәзер унике елдан артык вакыт үтеп тә киткән инде. Төзү-монтаж эшләрен башкаручы “Волгопродмонтаж” фирмасы предприятиеләрендә бүгенге көндә биш йөзгә якын югары квалификацияле төп хезмәткәр бар.

- *Төзү-монтаж эшләренә заказлар да күп, алар арткаңнан-арта гына бара,* - дип сөйли Тәлгать Туктаргали улы. - *Соңгы елларда без Татарстанның Түбән Кама шәһәрендәге зур “Таттанеко” нефтехимия комплексы предприятиеләрен төзүдә, аларның металл конструкцияләрен монтажлауда күп эшләр башкардык, хәзер дә дәвам итәбез. Өлкәбезнең промышленность предприятиеләрендә дә заказлар күп, мәсәлән, Новокуйбышевск, Куйбышев, Сызран нефть эшкәртү заводларына реконструкцияләр үткәрүдә актив эш алып барабыз. Кечерәк объектларда эшләүдән дә читтә калмыйбыз. Кайда эш бар - безнекеләр шунда. Предприятиегә өлкә хөкүмәтендә дә, промышленность буенча министрлыкта да соңгы вакытта игътибар арта төште. Шуны да әйтергә кирәк: шушы көннәрдә генә безнең “Волгопродмонтаж” төзелеш фирмасына 47 яшь тула инде.*



Ә Тәлгать Туктаргали улы Хуҗин 11 майда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Елховка районының Тупли авылында гап-гади гаиләдә тәрбияләнгән Тәлгать әфәнденең шундый зур дәрәҗәләргә ирешүе куандыра, әлбәттә. Әтисе Туктаргали абзый күптән вафат, ә менә әнисе Нәҗия апага быел 77 яшь тулган инде.

- *Беренче төпле тәрбия безгә гаиләдә бирелде,* - дип исенә төшерә Тәлгать әфәнде. - *Дөньядан иртә киткән әти ягыннан Галиулла бабамны хәтерләмим инде, ә менә Мәрьям әбиемнең безне тәрбияләүгә керткән өлеше чиксез зур булды. Ул күп догалар өйрәтеп калдырды.*

Аның әнисе ягыннан Хәернисә әбисе һәм Нигъмәтулла бабасы да авылда хөрмәтле кешеләрдән саналганнар. Халыкта юкка гына: “Алма алмагачтан ерак төшми”, - дип әйтмәгәннәрдер шул.

Йөз еллык тарихы булган Тупли авылы мәктәбенең дә тәэсире көчле булгандыр. Әле 1980 елда урта мәктәпне тәмамлаган Тәлгать әфәнде хәзер дә зур җылылык белән класс җитәкчесе Галия Галәүтдин кызы Шәкүрованы, тәрбия эшләре буенча мәктәп директоры урынбасары, тарих укытучысы Таһир Борһан улы Әбүзәровны (ул озак еллар өлкәнең эчке эшләр бүлекләрендә җитәкче булып эшләп, пенсиягә чыкканнан соң, бүген “Волгопродмонтаж” фирмасында хезмәтен дәвам итә), математикадан төпле белем биргән Россиянең атказанган укытучысы Зөлфирә ханым Гыйматдиноваңы исенә ала.

Яхшы дини һәм милли тәрбия алган Тәлгать әфәнде үз гаиләсен дә матур һәм ныклы итеп кора алган. Хатыны Руфия ханым тумышы буенча шәһәрдән булса да, шулай ук туган телебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны белеп, күреп үскән.

- *Без өебездә балаларыбызны тәрбияләгәндә гел татарча гына аралаша идек, бу хәзер дә шулай дәвам итә,* - дип сөйли Тәлгать Туктаргали улы. - *Шуңа күрә улларыбыз Эмиль белән Данир да туган телебезне үзләштерделәр. Олысына хәзер 23 яшь инде, үткән елны Мәскәү дәүләт университетының финанс-экономика факультетын тәмамлап, башкалада “Роснефть” компаниясендә эшли. Икенче улыбыз да шул ук уку йортында белем ала.*

Агалы-энеле бертуган Тәлгать һәм Рифкать Хуҗиннарның өлкәбезнең татар оешмаларына, “Яктылык” татар мәктәбенә, мәчетләргә риясыз ярдәм күрсәтүләре турында язмабызның башында әйтелгән иде инде. Тупли авылындагы Яңавыл, Самарның Тарихи һәм Кряж бистәсе мәчетләре манараларының барысы да алар җитәкләгән “Волгопродмонтаж” фирмасы акчасына күтәрелгән. Андый манаралар, Россия мөселманнарының баш мөфтие Шәйхелислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин әйткәнчә, һәркемнең күңел түрендә булырга тиеш. Ә милләттәшебез Тәлгать Туктаргали улы Хуҗин нәкъ шул рәвешчә яши дә инде. Аның күңел түрендәге “манаралары” башкаларга да юл күрсәтеп, ерактан балкып торалар кебек.




*Шигъърият кичәсендә "Туган тел" оешмасы президенты Ильяс Шәкүров, Илһамия Гарипованың шигырьләре белән чыгыш ясаган кызы Гөлназ Биксалиева, оныклары Алия Биксалиева, Ильмаз һәм Исламия Гариповлар.*

# Илһамия ГАРИПОВА: «Шигырьләремне балаларым һәм оныкларым өчен язам»

***Самарның Литвинов исемендәге Мәдәният сараенда үткән шигърият кичәсендә иҗат җимешләрен беренче тапкыр тамашачы хозурына чыгарган каләм тибрәтүчеләр дә бар иде. Шулар арасыннан Камышлы районының Иске Ярмәк авылында туып-үскән, Яңа Усман авылында гомер кичергән Ильһамия Гарипованың шигырьләре аеруча игътибарга лаек булды. Аларны кызы Гөлназ Биксалиева, оныклары Алия Биксалиева, Ильмаз һәм Исламия Гариповлар сәнгатьле итеп укып, тамашачыны тирән дулкынландырдылар. Әлеге чыгышлар югары бәягә лаек булдылар. Җирле автор белән очрашу, танышу максаты белән Камышлы районының Яңа Усман авылына юнәлдем.***

**Римма НУРЕТДИНОВА**

### "Үземне шагыйрә дип атарга җөрьәт итмим"

Авыл мине иркен урамнары, төзек матур йортлары белән каршы алды. Язмам героеның йорты нәкъ аның уртасында урнашкан иде.

Илһамия ханым бар яклап та килгән хатын-кыз икән. Ике катлы, иркен өендә чисталык, пөхтәлек хөкем сөрә. Аш-су бүлмәсендәге өстәлдә сыйлы табын сыгылып тора.

Менә мин килеп керү белән дә хуҗабикә каршы алып, табынга чакырды. Өстәл тирәли аның балалары һәм оныклары әниләренең пешергән ризыкларын мактый-мактый, чөкердәшә-чөкердәшә иртәнге чәй белән сыйланалар. Биредә нинди генә камыр азыклары юк — кабартма, коймак, өчпочмак, вак бәлеш, гөбәдия... Кыскасы, Илһамия апаның өстәлен тәмле, туклыклы милли ашлар бизи. Хуҗабикәнең сүзләренә караганда, аларны әзерләүдә аңа гаиләсе этәргеч булып тора. Аш-су тәмле булсын өчен ул бөтен күңел җылысын салып пешерергә тырыша.

*– Мин бар эш-гамәлләремне дә балаларыма һәм оныкларыма багышлыйм. Шигырьләремне дә алар өчен язам. Иҗат җимешләремдә гаиләм әгъзаларына мөрәҗәгать итәм, аларга тәрбия бирәм, шигъри юллар аша үзләренә уй-хисләремне җиткерергә тырышам. Шуңа да үземне шагыйрә дип атарга җөрьәт итмим,* – ди күзләреннән илаһи нур, татар хатыннарына гына хас итагатьлелек, сабырлык бөркелеп торган бу сөйкемле ханым.

Сүзләр сүзгә бәйләнеп, әңгәмә акрын гына бүгеннән узганга күчә: дистә еллар дәвамында шушы матур мохитны кадерләп саклап яшәүче ханымның гомер сүтәбез.

### Тәүге мәхәббәт кыйссасы

Илһамия Камышлы районының Иске Ярмәк авылында яшәүче Исламнур һәм Җария Сафиннар гаиләсендә эш сөючән, чибәр һәм акыллы кыз булып үсә. Мәктәп партасыннан ук рус һәм татар әдәбиятын яратып укый, самими хисләре күңел буасына сыешмаганга, бөек илаһи тылсымга – иҗатка тартыла. Әтисе аңа: "Әдәбият укытучысы булырсың инде син, кызым", – дия торган була. Шуңа да карамастан, Илһамия иптәш кызларына ияреп, Куйбышев шәһәренең медицина училищесына укырга керә.

*- Дөресен әйткәндә, һөнәрем буенча эшләргә дә туры килмәде, әмма медицина буенча укуыма бер дә үкенмим. Мин һәрвакыт өемдәгеләр өчен шәфкать туташы булдым, иремә һәм балаларыма медик ярдәмне үзем күрсәтеп тордым,* – ди Илһамия апа.

Дәүләт имтиханнарын бирү һәм диплом эшен яклар алдыннан студент кызны Куйбышевның беренче санлы бала табу йортына практика үтәргә җибәрәләр. Шушы вакытта ул Мәзгүт исемле чибәр егетне очрата да инде. Яшьләрнең танышулары нәкъ һинд киноларындагыча була...

Бала тудыру йортына Камышлы районының Яңа Усман авылыннан булачак әнине алып киләләр. Яшь хатын бигрәк тә күрше авылыннан булган Илһамия исемле шәфкать туташын ошата. *"Йә, Ходаем, ничек син минем энем Мәзгүткә охшагансың, Ильһамия туташ...",* –



*Ильһамия һәм Мәзгүт Гариповлар оныклары белән*

дип кызны аптыратып бетерә. *“Мәзгүт армиядән кайткач, мин аңа синең турында сөйләрмен әле. Бәлки, сине эзләп тә килер. Шундый уңган һәм чибәр татар кызын ерак җибәрергә ярамый. Әле безнең Яңа Усман авылына килен булып та төшәрсең”,* – дип көлдерә.

Шуннан соң озак вакыт та үтми ап-ак халатлы Илһамия каршына Мәзгүт исемле авыл егете килеп басмасынмы!..

Яшьләр бер-берсенә бер күрүдән үлеп гашыйк булалар, очраша башлыйлар, эч серләре, изге уй-ниятләре белән уртаклашалар, киләчәккә планнар коралар.

*– Илһамия, минем белән авылга кайтасыңмы? Әйдә, җаным, менә күрерсең, бездән дә бәхетле пар булмаячак бу дөньяда,* – дип кабатлый Мәзгүт Илһамиясен күкрәгенә кысып, һәм кыз ризалаша.



*Тәүфыйклы оныклар Исламия, Ильмаз, Алия дәү әниләре – Илһамия апа белән*



*Шагыйрә балалары Ильһам, Гөлназ һәм Римма белән*

Әйе, яраталар, бик яраталар, өзелеп сөяләр алар бер-берсен. Гөрләтеп туй ясыйлар. Алмадай өч бала үстерәләр, таудай дөнья корып, байлыкта-муллыкта яшиләр. Мәзгүт колхозда – баш бухгалтер, Илһамия кибет мөдире булып эшли.

*– Шунысы бик кызганыч: карт белән карчык булып, кара-каршы тезне-тезгә терәп утырып, өстәл тирәли тәмле чәйләр эчеп, рәхәтләнеп тигез гомер итәргә тәкъдиргә язылмаган икән. Ә бит минем бөтен теләгем – Мәзгүтем белән бергә картаеп, үстергән балаларыбызга куанып, оныкларыбызның шатлыгын уртаклашып, парлы булып яшәү иде. Юк шул, гел без уйлаганча гына килеп чыкмый икән...*

*Бармаклар бит тигез түгел,*
*Гомерләр дә тигез бирелми.*
*Кемгә күпме тиешлесен*
*Бер Ходаем билгели.*

*Алты ел элек җәйнең матур бер көнендә үземнең 32 ел бергә гомер иткән тормыш иптәшем, балаларымның әтиләре кинәт кенә безне калдырып, якты дөньядан мәңгелеккә китеп барды. Бу безнең өчен аяз көнне яшен суккандай булды...,* – дип сөйли язмам герое.

*– Мәзгүтем шулкадәрле сабыр, кешелекле, юмарт, акыллы, уңган ир иде. Аңарда бер кимчелек тә булмагандыр кебек. Оныкларыма васыятем шул: бабаларының исемен мәңгеләштереп, фамилияләрен Мәзгүтовка алмаштырсыннар иде,* – ди хәләленең үлемен бик авыр кичергән Илһамия апа.

Иҗатка тартылган, нечкә күңелле автор үзенең йөрәк әрнүләрен шигырьләрендә дә туплый:

*Ачы хәсрәт килде башкаема -*
*Югалттым мин якын кешемне.*
*Үлгән артыннан үлеп булмый инде,*
*Түзәм, чыдыйм, кысам тешемне.*
*Урының оҗмахта булсын, дип,*
*Сорыйм ялварып Ходайдан.*
*Гүрең якты булсын, тыныч йокла,*
*Ташламабыз изге догадан...*
*(“Юксыну”)*

*....Кайтып булса әгәр яшьлегемә,*
*Сине сайлар идем мин, иркәм.*
*Күңелемнән бер дә чыкмыйсың,*
*Һаман сине уйлыйм кич-иртән.*
*Төшләремдә сине, Мәзгүт, күрәм,*
*Киңәшләшәм, сөйлим серемне.*
*Була шундый рәхәт, дөнья матур,*
*Аера алмыйм төштән үземне.*
*Күзләремне ачсам, югалтуның*
*Ачысыннан әрни күңелем.*
*Кабул итеп булмый сине кабат*
*Кайтаруы мөмкин түгелен...*
*(“Югалту ачысы”).*

**Асыл нәсел балалары**

*“Хатын-кыз бәхете, шәхсән, Сезнең бәхетегез нәрсәдә, Илһамия апа?”* – дигән сорауга ул тыйнак кына елмаеп: *“Минем бәхетем ул – минем гаиләм, балаларым*

*һәм оныкларымның шатлык-сөенечләре, өмет-хыяллары”.*

*“Үсмер чакта канатланып күз алдына китергән матур хыялларымның чынга ашуына, вәгъдәләр бирep кавышкан сөйгән ярым Мәзгут белән тәүге хисләребезне тапламыйча, беребез өчен беребез җан атып, хөрмәт итеп яшәгән елларыбызга, тигез мәхәббәттә туган сөекле балаларыбызның чын кеше булып үсүләренә ихлас сөенәм, горурланам. Бәхет үзе шушы түгелмени, сеңелем?!”* – диде һәм, бераз уйланып торганнан соң, фикерен дәвам итеп, шигъри юлларын да укып китте:

*“Миңа сорау бирсәләр:*
*“Бәхетлеме?” – дисәләр.*
*Бәхетем шул – балаларым*
*Кеше булып йөрсәләр...”.*

Илһамия апаның балалары – улы Илһам, кызлары Гөлназ һәм Римма – тәртипле, инсафлы, яшьтән үк әти-әниләренә булышып, эшчән, миһербанлы, намуслы булып үскәннәр. Мәктәпне алтын һәм көмеш медальләргә, югары уку йортларын кызыл дипломнарга тәмамлаганнар, тормышта үз юлларын тапканнар, теләгән максатларына ирешеп яшиләр, дәрәҗәле урыннарда эшлиләр, гаилә корып җибәргәннәр. Самарда яшәүче балалары сөекле әниләрен ялгыз калдырмыйча, үзләре белән шәһәргә алып киткәннәр. Бәйрәмнәрдә һәм ял көннәрендә алар бергәләп авылдагы туган йортларына кайтып йөриләр.

Илһамия апа балаларына багышлап бик матур шигъри юллар иҗат иткән:

*Балаларым!*
*Сез – туганнар, сезне җаннар түгел,*
*Каннар тартып бәйли үзенә.*
*Туганлыкны саклап, гел дә бергә*
*Атлагыз сез гомер уренә.*
*Бармак арасына ит үсми ул,*
*Ят кешеләр гел дә чит итә.*
*Бер-берегезгә кирәк, терәк булып,*
*Тату яшәүләргә ни җитә?*
*Бәхеттә дә, кайгыда да кеше*
*Туганына килеп сыена.*
*Кайгы-шатлыкларны уртаклашып,*
*Яшәгез сез гомер буена.*

Әби белән үскән балалар тәртипле була, диләр бит. Илһамия апа – оныкларын тәрбияләүдә төп рольне башкаручы. Ул Самар шәһәренең “Яктылык” татар мәктәбендә белем алучы Исламиягә, Ильмазга һәм Алиягә кечкенәдән үк дини тәрбия бирә, үзләрен туган телебездә сөйләшергә өйрәтә. Әнә, шигърият кичәсендә без әлеге балаларның телебезне яхшы белүләрен, татар хәрефләрен дөрес әйтүләрен, әбиләренең шигырьләрен сәнгатьле итеп укуларын күрдек.

*Укуыннан кайткачтын*
*Онык ишекне шакый.*
*Ул “Яктылык” мәктәбендә*
*1нче сыйныфта укый.*
*Авызы колагына җиткән,*
*Күзләре янып тора.*
*“Ничә бишле алганымны,*
*Дәү әни, тизрәк сора!”*
*Мин авызымны ачканчы,*
*“Дүрт бишле!” – димәсенме.*
*Һәр бишлегә биш сумымны*
*Белә ул бирәсемне!*
*Утырабыз аның белән*
*Кичләрен без сөйләшеп,*
*Җиде яшьлек оныгымнан*
*Мин – гади бер өйрәнчек.*
*(“Бишле хакы”).*

9 яшьлек Исламиянең озын-озын Коръән сүрәләрен укып, ничәмә буын ата-бабаларының исемнәрен атый-атый дога кылганын күрсәгез иде сез! Мин моны таң калып күзәттем...

*Ислам нуры, Коръән сүрәләре*
*Сафландыра изге хисләрем.*
*Раббым Аллам ризалыгы өчен*
*Дога кылам иртә-кичләрен.*
*Үзем белгән Коръән сүрәләрен*
*Чын күңелемнән укып юанам.*
*Җитешсезлек, хаталарым булса,*
*Ярлыкачы, Раббым, бер Аллам!*
*Бу дөньядан киткән якыннарым*
*Миннән хәер-дога көтәләр.*
*Алар рухларын зурлаганда*
*Көннәр тыныч, матур үтәләр,* – дип яза тәүфыйклы оныкларның дәү әниләре – Илһамия апа.

Бу гаиләдәге җылылык, ихласлылык, бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрдәге эчкерсезлек, тирән хөрмәт мохитында күп булса, бер сәгать торылгандыр. Тик шул кыска гына вакыт эчендә озын гомергә җитәрлек рухи канәгатьләнү алдым. Иң мөһиме - бәхет, хатын-кыз бәхете турындагы уй-фикерләрем тупланган күңел сандыгына бик тә кирәкле тагын берничә бәяләмә өстәлде. Игелекле, шәфкатьле кеше генә чын мәгънәсендә бәхетле була һәм башкаларны да бәхетле итә ала.



*Илһамия ханым балалары һәм оныклары белән Яңа Усман авылындагы йортлары каршында*

*Мы продолжаем публикацию материалов, посвященных 135-летию со дня рождения выдающегося татарского ученого-просветителя, философа, публициста и общественного деятеля Закира Кадыйри, внесшего значительный вклад в развитие образования, культуры, национального самосознания своего народа. Большую часть жизни Закир Кадыйри провел в вынужденной эмиграции. И все годы рядом с ним находилась его жена Сания Гыйффат – татарская поэтесса, драматург, автор многочисленных учебников для школ в татарских диаспорах Китая, Финляндии и др. стран. Жизнь её достойна увлекательного романа, но мы сегодня ограничимся лишь коротким знакомством с биографией этой незаурядной личности, ставшей символом самоотверженности и силы духа татарской женщины.*

***Я пою, хоть жилье мое тесно и старо,***
***Не боюсь, хоть любимый народ мой – татары –***
***Так безжалостно стрелы вонзает в меня.***
***Я недрогнувшей грудью встречаю удары.***

Г.Тукай

*«Размышления одного татарского поэта»*



**Сания Гыйффат (1899 г. – 1957 г.)**

# ВЕРНОСТЬ

## НЕСЛОМЛЕННАЯ СУДЬБОЙ

***Много написано о женах декабристов, добровольно разделивших с мужьями суровую сибирскую ссылку. Но мы практически мало знаем о женах татарских эмигрантов, которые разделили с мужьями всю горечь изгнания, были порой единственной их опорой в самых трудных жизненных ситуациях. А Сания Гыйффат была не просто спутницей жизни Кадыйри, но и его сподвижницей. … Современники находили в ней редкое сочетание красоты, ума и таланта. А ведь судьба этой прекрасной женщины-поэтессы и драматурга достойна пера романиста. Она, без преувеличения, стала одной из самых ярких звезд послереволюционной татарской эмиграции. Мне кажется, что именно в ней Закир Кадыйри увидел и нашел идеал мусульманской женщины, о котором он писал в своих статьях и книгах: свободную, прекрасно образованную, активную. На протяжении четырех десятков лет она была рядом с мужем в чужой стране. Ни на день не покидала ее тоска по родине, эту печаль она пронесла через всю свою недолгую жизнь, выразила в стихах и прозе.***

**Ирек САЙФИЕВ**

Сания родилась 11 октября 1899 года в семье чистопольского купца Х.Сабирзянова. Мать свою Галию не помнила – она умерла сразу после ее рождения. Воспитанием внучки занялась бабушка Хадича, женщина образованная, придерживавшаяся передовых взглядов. Дед Сании Мортаза в селе Каракашлы был самым уважаемым человеком. Это он построил водяную мельницу, а в 1913 году дал денег на строительство новой школы.

Сания рано научилась писать и читать, свободно владела русским языком. Дома у неё была богатая библиотека с книгами на татарском, турецком, арабском и русском языках, многочисленные журналы. Сания закончила медресе «Буби», затем некоторое время учительствовала, сотрудничала в газетах. Рано проявился поэтический дар девушки. На становление почерка поэтессы с ярко выраженным национальным колоритом оказала двоюродная сестра, журналистка Фатыйма Наурузова, публиковавшаяся под псевдонимом Фатыйма Фарида.

Знакомство ее с Закиром Кадыйри, в то время уже известным общественным деятелем, историком, признанным ученым, состоялось в доме Наурузовых в Томске. Наурузов тогда редактировал газету «Сибирь», в которой часто печатался и З.Кадыйри.

В 1914 году она переехала вместе с родственниками в Уфу. Здесь Сания Гыйффат стала одной из ведущих сотрудниц газеты «Тормыш», редактируемой З.Кадыйри. Её статьи на актуальные темы, полные романтизма стихи непременно вызывали живой интерес у читателей. Вскоре в издательстве «Тормыш» вышел и первый поэтический сборник молодой поэтессы.

В 1917 году она вышла замуж за Закира Кадыйри. Вскоре у них родились дочери Азат и Лалэ. Они прожили долгую совместную жизнь, полную лишений и скитаний. А отношения их всегда оставались красивыми и достойными подражания. Это был союз

двух одаренных, творческих личностей, скрепленный общностью целей и интересов. Именно под влиянием З.Кадыйри и благодаря ему, творчество Сании «раскрылось, как цветок», отмечает исследователь ее творчества профессор Х. Миннегулов. А для мужа она была не только музой, но и самым близким по духу сподвижником, его надежной опорой и помощником во всех начинаниях.

В годы революции и гражданской войны тысячи людей были вынуждены покинуть родину, и среди них - только начавшие свою семейную жизнь чета З.Кадыйри и С.Гыйффат. До 1924 года она в Китае преподает в созданной Закиром Кадыйри татарской школе. Затем вслед за мужем переезжает в Турцию.

Сейчас трудно восстановить подробности их жизни в этот период, но ясно, что она осталась верна национальным идеям, и интерес к литературе у неё не ослаб.

В 1936 г. семья З.Кадыйри и С.Гыйффат по приглашению татарской диаспоры, состоявшей из переселенцев из России, переезжает в Финляндию и поселяется в Хельсинки. И здесь Сания продолжает занятия литературным творчеством, но главным делом становится обучение детей в открытой супругами татарской школе. Эта работа придает ей новый прилив сил и творческой энергии, она активно занимается просветительством, проводит вечера и встречи, пишет статьи, стихи и драмы. Её пьесы «Ханский подарок» и «Новая деревня» были поставлены на сценах финских театров. А драма С.Гыйффат «Зеркало жизни» в 1937 году вышла в Хельсинки отдельной книгой. В 1938 г. выходит из печати её учебник «Книга для чтения». В совершенстве владея татарским, турецким, русским языками, она удивительно быстро освоила и финский, что прибавило к ней уважения и среди коренного населения страны. Старшее поколение в Финляндии и сейчас добрыми словами и с огромным уважением вспоминает С.Гыйффат.

В 1939 году, опасаясь военного вторжения СССР в Финляндию, Закир Кадыйри, объявленный на родине «врагом и контрреволюционером», уезжает из Хельсинки снова в Турцию. А Сания смогла вернуться в Анкару только в 1944 году.

Во время проживания в Финляндии супруги тесно общались с С.Максуди и А.Куратом, выпустили несколько книг и учебников для татарских детей.

В 1937 году вся татарская политическая эмиграция готовилась к чествованию Гаяза Исхаки, по случаю его значимого юбилея – 40-летия творческой, литературной и общественной деятельности. Организацией финской части торжеств целиком занялась Сания Гыйффат. Она публикует много статей, посвященных творчеству Г.Исхаки, пишет к юбилею стихи, собирает рассеянную по миру татарскую общественность. В это же время отмечается и 20-летие провозглашения Милли Меджлиса. Для людей, отдавших жизнь борьбе за сохранение татарской нации, это была важная дата. Сания, хорошо знавшая Г.Исхаки, подготовила и опубликовала в разных изданиях целый ряд аналитических статей об этой незаурядной личности – признанном лидере татарского национального движения и о почетном месте писателя во всей татарской истории.



*Юбилей Г. Исхаки в г. Тампере в Финляндии*

В последние годы жизни С.Гыйффат практически отходит от общества, редко общается с друзьями, тяжело переносит уход из жизни мужа и Г.Исхаки. В Анкаре она страдала болезнями сердца и бронхиальной астмой. В самые трудные минуты жизни с горечью вспоминала отчизну: «Ах, вернуться бы в Чистополь, на берега Камы, где сам воздух помог бы мне!». Она умерла 12 апреля 1957 года, всего на два с половиной года пережив своего мужа. Похоронили ее в Анкаре рядом с могилой З.Кадыйри. Её благодарные ученики и последователи специально приезжали из Хельсинки, чтобы поставить на её могиле надгробный памятник.

***Нерукотворный памятник поэту – это его творчество. А на стихи и поэмы Сании Гыйффат советской властью было наложено табу. В 1988 году в Татарском книжном издательстве вышла книга «Эмет йолдызлары» («Звезды надежды») с краткими биографиями и избранными стихами татарских поэтесс конца XIX – начала XX веков. Нет вины составителя, уважаемого Мухаммеда абый Гайнуллина, что среди полутора десятков имен не оказалось имени С.Гыйффат: кто бы ему позволил напомнить о жене эмигранта-контрреволюционера Кадыйри и тещу «самого отъявленного антисоветчика из радио «Свобода» Ахмета Тимера, к тому же открыто восхвалявшую Гаяза Исхаки?! Но времена изменились, и вместе с отринутыми именами славных сынов и дочерей татарского народа возвратилось к нам и имя Сании Гыйффат, поэтессы огромного дарования. В любой другой стране такая личность составляла бы гордость нации. Сейчас татарский читатель уже имеет возможность насладиться ее творчеством. Она вернулась к нам через годы забытья и страданий.***

*Наилә Хөсәенова – Әбдерәшитованы Самарда белүчеләр көннән-көн арта бара. Халыкның бер катламына ул шәфкать туташы буларак таныш. Поэзиягә мөкиббәннәр Наилә ханымның иҗатын "Бердәмлек" гәҗитәсе аша күзәтеп баралар.*



# ДӘРЬЯ ТАШКЫННАРЫН СЫЙДЫРГАН ЙӨРӘК

Ниһаять, Наилә ханым үзенең беренче җыентыгын дөньяга чыгарды. Китапның исеме – "*Туган якның ачып ишеген*".

Китап - синтез.

Биредә тарих та бар.

Биредә хикәят – нәсыйхәтләр.

Биредә тарихи фотогалерея.

Һәм үзәк өзгеч шигырьләр.

Хатын-кыз йөрәгенә барчасы да сыя.

Шашкан мәхәббәт.

Ярсулы мәхәббәт.

Җавапсыз мәхәббәт.

Кыя ташларны эретерлек ялкынлы мәхәббәт!

Йөрәк өзгеч сагыш.

Чиксез хыял.

Киң күңеллелек.

Милләте татарга олуг хөрмәт һәм тугрылык.

Наилә ханымның шигъри юллары күңел түренә каршылыксыз кереп утыралар да, йөрәккә дәрт вә дәрман биреп, һәр күзәнәгенә яшәү шытымы булып урнашалар.

*Сөю дигән сихри чишмәләрдән*
*Сулар эчтек яшьлек таңында.*

Ә менә бу юллары олы кешеләрне дә өмет кыршавында тота.

*Күзебездә җылы көннәр булып*

*Соңгы гөлләр чәчәк атуын.*

Ә кем генә битараф калыр икән түбәндәге юлларга!

*Мин әзер үләргә куеныңда,*
*Сөям,дип,әйтелгән сүзеңнән.*

Наилә ханым елның кайсы фасылын гына алмасын, ул аны сиздерми генә хискә чорнап, бик оста утлы гыйшки ялкынга әверелдерә.

*“Җил пышылдый никах догасын”.*
*“Ак кар ява кәләш күлмәгедәй,*
*Сөю иңгәч күктән, гөнаһ булмас”,*
*Диеп бирә Ходай дәвасын.*

Наилә ханымның иҗатында усаллык юк.

Ул барлык көчен кәкре дөньяны турайту максаты белән яши.

Ул сирәк хатыннарның берсе.

Ул хыянәт итүчене дә ярата һәм изге хезмәтен кызганмый, теләкләре гөнаһсыз.

*“Мин югалттым мәхәббәтнең үзен,*
*Күз яшьләрем тама юлыңа.*
*Ятлар белән үткән чакларыңда,*
*Шул яшьләргә таелып егылма*”.

Бу юлларны нәфис күңелле, нәзберек тәрбия алган хатын гына яза ала.

Хатын-кыз йөрәгенә җитәрлек сүзне тик ир-ат кына әйтәдер һәм шул сүзгә җавап итеп тик хатын-кыз гына тегәл сүз табадыр.

*“Бер сүзең дөньямны үзгәртте,*
*Канатлар үстереп иңемә”.*

Яисә менә афоризм биеклегенә күтәрелгән фикерләр.

“Сөйләшә берсүзсез йөрәкләр”.
“Җырлыйсым килә синең куеныңда”.
“Йөрим пычак йөзеннән”.
“Көч алып яшьлекнең җиеннән”.
“Минем көчле мәхәббәтем
Сине саклар җилләрдән”.

Наилә ханымның туган авылына булган олуг мәхәббәтен туган телебездән аеру мөмкин түгел.

*Рәхмәт укыйм, туры юлдашларны*
*Бүләк иттең минем юлымда.*
*Һәм телемне – мәшһүр татар телен*
*Дустым итеп бирдең җаныма.*
*Милләтемә хезмәт итәр өчен*
*Каләм бирдең аңа дәшәргә.*

Наилә Хөсәенова тормышның эчендә кайный.

Ул һәр мизгелне канатландырып күккә чөя белә, һәр хәсрәтне, фаҗигане шигъри юлларга сыйдыра.

*Намазлык юк, дога уты сүнгән,*
*Онытылган ир, бала, оныклар.*
*Сериаллар карап, ялган тыңлап,*
*Яши бирә әби-бабайлар.*

Наилә ханым лирик шагыйрә.

2013 елда әткәен мәңгелеккә озатты.

Үлем хәсрәте таш йөрәкләрне дә эретә.

Ә инде йомшак күңелле, хисле хатын-кызның ул бәгырен тапый.

Наилә ханымның түбәндәге язма юллары белән танышуыгызны сорыйбыз.

**Күңелкәйләр сагына әткәемне...**

Быелгы март ае нәселебезгә бик зур югалтулар алып килде. Минем кадерле әтием 82 яшендә вафат булды.

Әткәй актив кешеләр исемлегендә булды.

Ульян өлкәсенең Кулаткы районында урнашкан Иске Мостяк авылында югары оч мәчетен төзүгә зур өлеш кертте.

Һәм шул мәчеттә күп еллар имам-хатыйб вазыйфасын үтәде. Аны, Хәсән углы Сөләйман Әбдерәшитовны, соңгы юлга авылдашларыбыз хөрмәт белән озаттылар.

Ул балалары, авылы, аның халкы, динебез Ислам өчен янып-көеп яшәде.

Аллаһыма мең-мең шөкранамын. Әтиемнән читтә яшәсәм дә, актык көннәрендә мине аның янында булдырганына.

Әтием-бәгырем, урының җәннәттә булсын.

Без СИНЕ нур, изгелек сипкән кеше буларак күңел түребездә саклыйбыз.

Аллаһы теләсә, догада булырбыз.
Намазларыбыздан калдырмабыз.
*Сөләйман кызы Наилә Хөсәенова.*

**Әтием исән чакта язылган шигъри хисләрем**

**Алтын бөртекләрем**

Әти-әни алтын бөртек,
Тормышымны бизәп торган,
Безнең өчен, үреп наздан,
Күңелемдә бишек корган.
Әти-әни изге җаннар,
Миңа гомер биргән алар,
Йөрәгемә иман нуры
Һәм дә шәфкать нуры салган алар.
Әткәй-әнкәй изге җаннар,
Хәятем бит Сезнең җанда,
Нарасыйдай күңел изрәр
Балам, диеп, Сез кочканда.
Әткәй аем, әнкәй кояш,
Дөнья күге асыллары,
Гомер күгем офыклары
Һәм җәннәтнең ачкычлары.
Узганнарга түзә йөрәк,
Сез бит миңа көчле терәк,

Һәр таң саен азан белән
Сезнең янга кайта күңел.

Әткәй-әнкәй – рухи канат,
Йөрәгемә сеңгән хикмәт,
Тәңремә мәңге рәхмәт,
Сез бит миңа олуг нигъмәт.

**Әтием үлгәч язылган юллар**
**Ажагандай булдың, әткәем...**

Юк син, әткәй...
Инде миңа каршы чыкмассың,
Шатлыгым вә куанычым диеп,
Мәңге мине сөеп кочмассың.
Ходаемның миңа бүләгедер,
Гомереңнең актык көннәрен,
Чәйләр эчеп бергә үткәрдек,
Сизмәдек бит бу мизгелнең соңгы икәнен.
Юк син, әткәй...
Син кайтмассың...
Тик шулай да йөрәгемдә җылы сулышларың,
Яшәү дәрте булып янасың.
Бәхетебез безнең кыска булды,
Бер аерды язмыш, бер үлем,
Җәннәтләрдә урының булсын диеп,
Дога укып сорыйм мин бүген.

Сөләйман *кызы Наилә Хөсәенова.*
Самар – Иске Мостяк.
Март. 2013 ел.

**Наилә ханымның хәсрәтле елында Ходай Тәгаләдән: “Сабырлык бирсәң иде”, - дип сорыйбы**з.

# Наил ТАХАУТДИНОВ: “ТЕХНИКА БЕЛӘН ЭШЛӘРГӘ КУЛЫМ ӘЛЕ ДӘ КЫЧЫТА”

*Авылдан чыккан күренекле татарлар арасында Самарның «Агроавто» ябык акционерлар җәмгыяте белән идарә итүче Россия Федерациясенең атказанган транспортчысы Наил Гариф улы Тахаутдинов та бар. Ул үзенең тормыш юлын болай тасвирлады.*

**Эльмира ШӘВӘЛИЕВА**



Вакытында Камышлыда яшәүче Камалетдин бабамны да, Дәүләтколда яшәүче Кәлим бабамны да кулакка санап, бөтен мал-мөлкәтләрен тартып алганнар. Дөрес, әтинең әтисе Камалетдин бабайга, 80нән узган карт буларак, авылда калырга рөхсәт ителгән, ә балаларының барысын да Пермь өлкәсенең Березняки шәһәренә илтеп ташлаганнар. Соңрак алар Чиләбе өлкәсенә күчеп яши башлаганнар, ә минем әти, төпчек малай буларак, авылга кайткан. Унике яшеннән заводларда эшләп үскән әтием мунча хәтле салам башлы өйгә кайтып кергән.

Ә әнием Мәһруйның әтисе Хәлим бабайның таш өенә колхоз правлениесе кереп урнашкан. Аларга да кулак исеме тагылып, күп нужа күргән кешеләр.

Әтием Гариф Тахаутдинов үз гомерендә райисполком рәисе шоферы булып эшләде. Сугыш башлангач, ул колхоз машинасын алып фронтка китә һәм сугыш юлларын аркылыга-буйга йөреп чыга. Әмма колхоз машинасын башкаларга алыштырырга туры килә: кайсына снаряд тиеп яна, кайсы ватыла... Ә Брянск тирәсендә барган сугышларның берсендә әтинең грузовигы сазга бата башлый. Ул кабинасыннан сикереп төшеп, салкын суда фашистлардан кача-кача үзебезнекеләр янына чыкканда, салкын тидерә һәм ревматизм белән авырый. Аяклары шешеп, йөрәге авыртып гомере буе шул чирдән интекте, бахыр.

Алланың рәхмәте белән, бөтен кыенлыкларны үтеп, кырык үлемне алдап, әтиебез сугыштан нәкъ Җиңү көнне, 9 майда, кайтып кергән. Сәламәтлеге нык какшаган булса да, илле яшендә йөрәк ревматизмыннан вафат булганчы, ул машина йөртте. Мин менә нәкъ сугыштан соңгы, кырык алтынчы ел баласы булып туганмын. Үземне белә башлаганнан бирле әти янында, аның машинасы тирәсендә бөтерелеп үстем.

Мин чын татар мәктәбендә, бөтен фәннәрне дә туган телемдә укыган бәхетлеләрнең берсе. Шуңа күрә, армиядә хезмәт итеп кайткач, авылда рус телендә сөйләшә торган авылдашларыма сәерсенеп карый идем. Ничек инде татар була торып, татар авылында русча сөйләшергә була икән? Милләтең белән горурлану хисе булырга тиештер бит?

Беренче сыйныфка укырга кергәндә авылның бер очында дүртъеллык татар мәктәбе эшли иде әле. Башлангыч белемне шунда алдым. Аннары безнең өйдән өч километр ераклыктагы җидееллык татар мәктәбенә күчерделәр. Ерак булса да, шунда йөрдем, чөнки анда да бөтен предметлар татар телендә алып барылды. Ә урта белем алырга теләүчеләр үзәк мәктәптә укуларын русча дәвам итәләр иде. Дөрес, анда да татар балаларына ана телен укыттылар. Шулай итеп, рус телен дә яхшы ук өйрәнеп өлгердем һәм сельхозинститутның авыл хуҗалыгын механикалаштыру бүлегенә кереп, укуымны дәвам иттем. Дөрес, аңа хәтле классташлар белән Богырысланның летчиклар әзерли торган училищесына да имтихан тотып карадык. Әмма егетләрнең күбесе керә алмагач, мин дә калмадым инде, авылдан беркая да чыгып йөрмәгән татар баласына руслар арасында кыенрак шул. Ә сельхозинститутта авылдашлар байтак иде.

Профессия сайлавым ваемсызрак булып күренсә дә, хәзер мин моны тәкъдир, дип саныйм. Чөнки машиналар, техника - ул минем дөньям, балачактан яраткан һөнәрем, әткәмнән калган мирасым. Ул төшке ашка кайтканда, беренче секретарьның яшь шоферы ялтыратып юып куйган машина янында минем авыру әтием йөрткән Камышлы районы башкарма комитеты рәисе машинасы ямьсез булып күренмәсен өчен, тәгәрмәч дискларын булса да юып җибәрә идем бит. Ә инде ватыла калса, мин дә әти янында кайнашам.

Ул йөк машинасына күчеп эшли башлаган вакытта мин радиотехника белән мавыга идем. Беркөн әти эштән шатланып кайтып керде, аңа яңа кабина биргәннәр икән. Ә электрикасын тоташтырырга кеше юк. Ул схемаларны өйгә алып кереп алай да, болай да әйләндереп карады. Чара юк. Мин әйдә, икәү тоташтырып карыйк, дигәч, башта булдыралмам дип курыкты. Ә эш тәмамланып машина кабынгач, әти исе китеп телен шартлаткан иде.

...Сельхозинститутны кызыл дилом белән тәмамлап, авылга кайттым. Мине сельхозтехника оешмасына баш инженер итеп эшкә алдылар. Яхшы гына эшләп киткән идем, ике ел да үтмәде, райком секретаре миңа районның комсомол оешмасын җитәкләргә тәкъдим итте. Ә ник алынмаска? Теләк бар, гайрәт җитәрлек. Партия кушты - комсомол үтәде, дигәндәй, тәвәккәлләп, Кләүлегә күчеп киттем. Комсомолның район комитеты секретаре буларак, күп кызыклы эшләр башкарылды, халык белән эшләү тәҗрибәсе тупланды. Җитмешенче еллар башында комсомол оешмасы зур көч иде бит ул.

Шулай өч ел гомер гөрләп үтте. Аннары Камышлыдагы автохуҗалыкны җитәкләргә тәкъдим иттеләр. Кләүледән Камышлыга йөреп эшләргә бик авыр булды. Ел ярым интектем. Ә Кләүледәге район сельхозтехникасы җитәкчесе урынбасары булырга тәкъдим иткәч, шатланып риза булдым. Ул вакытта бит инде гаиләм дә, балалар да бар иде.

Тик анда да озак эшләргә насыйп булмады. Машиналар саны күбәю сәбәпле, оешманы икегә бүлделәр. Балансләр аерым, ә урын бер, арада хәтта койма да юк. Без, идарә башлыгы һәм мин, «Транссельхозтехника» транспорт предприятиесе нәчәлниге, бер казанда ике тәкә башы кебек кайныйбыз. Бу үзебезгә дә, партия бюросына да ошамый башлады.

Партиянең райком секретаре Виктор Кузьмич Тюрин бу хәлне үзенчә хәл итеп, мине төзелеп бетмәгән комбикорм заводы белән идарә итәргә куймакчы иде. Барып карасам, галәмәт! Җитештерү технологиясе дөрес кулланылмый, оборудование проект буенча эшләнмәгән, суд тикшерүе алып барыла... Риза булмадым мин моңа. Белгечлегем буенча да транспортчы бит. Бюрога минем бу башбаштаклык ошамады бугай, выговор бирделәр. Ә мин тоттым да, Башкортстанның Октябрьск шәһәренә барып эшкә урнаштым. Анда күтәреп алдылар. Туймазы янында яңа төзелә башлаган компрессор станциясе җитәкчесе урынбасары итеп куйдылар, бер ай дигәндә өч бүлмәле фатир бирделәр, ә выговорны алдылар... Тиз арада гаиләмне алып килеп урнаштырдым да, башым белән эшкә чумдым.

Төзелешне буш урыннан башларга туры килде. Кыр уртасында безгә бирелгән җирне койма белән уратып алдык, вагончиклар куйдык, котельный ясап җылыттык, эшчеләр өчен ашханә булдырдык. Техника кайта башлагач, төзелешкә керештек. Өч ел буе көн димәдек, төн димәдек, Трангаз өчен компрессор станциясен вакытында төзеп, хөкүмәткә тапшырдык. Шунысы кызык, аны тапшыру эше да миңа йөкләнде. Ә төзелешне уңышлы башкарып чыгып, тирә-якка әйләнеп карасак, эшсез калганбызны күрдек. Менә сиңа мә!

Янәшәдә автобаза бар иде, шунда баш инженер булып урнаштым. Тик олыгая башлаганмын ахыры, туган яклар, татарлар янына тарта башлады. Бөгелмәдәге автоколоннага баш инженер кирәк, дигән хәбәр булгач, бәхетемне шуннан эзләп карарга телләдем. Дөрес, анда да мине бик яхшы каршы алдылар, фатир бирделәр. Кечкенә шәһәрдәге бердәнбер автоколоннада нәчәлник булу бик престижлы эш иде. Сине барысы да беләләр, гел нәрсәдер сорап киләләр. Анда яшәргә бик җиңел булды. Тик мин һаман нәрсәдер көткән кебек идем.

Шулай ел ярым чамасы эшләгәнмендер, Куйбышевтагы Облколхозстрой берләшмәсенең транспорт бүлеге җитәкчесе Вячеслав Маркелов, күптәнге танышым хәбәр бирде - андагы зур автохуҗалыкка директор кирәк икән. Мин шуны гына көтеп торган кебек, бөтен эшемне ташладым да, туган якларыма кайтып киттем. Мин Куйбышевта та татарларны таптым, кирәкле элемтәләр булдырдым һәм тиз арада үз кеше булып киттем.

Дөрес, 525 кеше эшли торган «Куйбышевагропромстрой» автохуҗалыгы тәртип белән мактана алмый иде. Беренчедән, эчүчелек. Мин үзем дә эчәргә яратмыйм, кул астында эшләүчеләрнең дә эчүен түзмим. Бу бәлане тиз җиңдем. Ә менә хезмәт хакы фондының зыянлы булуы белән бераз көрәшергә туры килде. Шуннан соң барысы да җайга салына башлады. Чөнки мин төрле урыннарда эшләп, күпне күреп өйрәнгән кеше идем, хәтта Ленинградка барып, тәҗрибә өйрәнеп тә кайткан идем заманында. Барысын да Минтранс таләп итүенчә ясап куйдык: эшчеләргә ашханә, душ, машиналарны юу урыны булдырылды, автохуҗалык тирәсендәге юллар төзекләндерелде, аларны кардан чистарту өчен бульдозер да сатып алдык.. Бөтен хезмәткәрләрем белән дә яхшы мөнәсәбәтләр урнашты. Шулай уңышлы гына эшләп ятканда үзгәртеп кору вакытлары килеп җитте...

Хәтерләсәгез, 90нчы елларда беренче чиратта бензин бәяләре күтәрелгән иде бит. Ә КамАЗ, иномарка белән чагыштырганда, дизель ягулыгы 30 процентка күбрәк китә. Шуның аркасында безнең системадагы җиде автохуҗалыкның алтысы таралды да инде, ә без менә әле дә яшибез. Тик йөк ташу белән шөгыльләнмибез инде хәзер. Заманасы башка.

Облколхозстрой таралгач, хөкүмәт үзе дә кайда һәм ничек барырга икәнлеген белми торган чакларда, дилбегәне ныклап тотарга туры килде миңа. Исемең идарә итүче булгач, көймәң кайсы якка ава башлавын алдан сизәргә кирәк бит. Кул астында йөз сиксән КамАЗ, йөздән артык грузовой һәм җиңел машина, Самарка елгасы буенда автобаза. Миңа биналарны периметр буенча төзетергә туры килгән иде, чөнки көймәчеләр бензинны урлап чыгарга җаен көтеп кенә торалар бит. Яңа системада бу, киресенчә, зыянга булды. Уртада калган зур җир кишәрлеге өчен саллы гына аренда бәясе түләп торырга кирәк булды. Аны бит башка оешмага биреп торып та, сатып та булмый. Ахыр чиктә водительләргә хезмәт хакы урынына машиналарын биреп, эштән чыгара башладым. Бу процесс 10 - 15 елларга сузылды. Чөнки мин аңлыйм: һәркемнең гаиләсе, балалары бар. Үзенә яңа эш урыны тапмыйча, беркем дә безнең автохуҗалыктан урамга чыгып китмәде. Беркем дә минем белән судлашып та йөрмәде, киресенчә, ике айлык пособиесен алганда рәхмәт әйтүчеләр дә булды.. Ул вакытларда бик азлар гына законлы рәвештә эшчеләре белән аерылалар иде бит.

Кыш уртасында машиналарны гараждан урамга чыгарып, иң зур бинаны «Самаратрансгаз» оешмасына арендага биргәч, тормыш бераз җиңеләеп китте. Аннары тагын берничә бина төзеп, аларны да арендага биреп тора башладык. Хәзер безнең оешма «Агроавто» ябык акционерлар җәмгыяте дип атала. Анда машиналар юк, тик күчемсез милек белән генә идарә итәбез. Ә техника белән эшләргә кулым бүген дә кычыта.

Арендаторларыбыз байтак, чөнки элеккеге ашханә хәзер кафе булып китте. Дөрес, аның хуҗасы башка, ә шулай да безгә файда. Чөнки маршруткалар безнең оешмага кадәр килеп йөри башладылар, водительләре биредә тамак ялгап чыгалар. Халыкка эшкә килүе уңайланды. Егерме җиде ел элек сатып алынган бульдозер әле дә юлларыбызны чистартып тора. Үсәбез әкренләп. Калган җирләрне, ниһаять, үзебезгә сатып алдык. Тиздән менә Киров күпере төзелеп бетә, димәк, яңа юллар салыначак, шәһәр безнең якка таба да атлап, тормыш җанланыбрак китәр, дип өметләнәбез.

Самарга килүемә 28 ел булды инде. Беренче елларымда биредә әле «Ялкынлы яшьлек» ансамбле генә эшли иде. Аннары «Туган тел» татар җәмгыяте барлыкка килде, газета чыга башлады, радио эшләп китте, Сабан туй, Нәүрүз бәйрәмнәре оештырыла, мәчетләр төзелә башлады. Өлкә үзәгендә, авылларда төзелә торган күпчелек мәчетләргә кирпеч китерергә, чүп түгәргә машина сорап, миңа киләләр иде. Мин беркайчан да аларны борып чыгармадым. Водительләремә дә рәхмәт, каршы килмәделәр, кайда җибәрсәң дә, барып эшлиләр иде. Чиркәүләр төзүчеләр дә бездән күп ярдәм күрделәр. Ә туган авылым Камышлы мәчете манарасына материаллар, калайлар да кайтарып бирдем, бүген дә мин аны онытмыйм, һәрдаим садакаларымны кайтарып торам. Изге эшкә ничек ярдәм итмисең инде?

Гаилә тормышыма килгәндә, Ходай миңа өч хатын язган булган. Барысы да яхшы иде, тик шулай насыйп булгандыр инде, картлыгымны Мулла авылында туып-үскән бик холыклы һәм акыллы Кадрием Гайнуллина белән каршылыйм. Алдагы ике хатынымнан туган дүрт балам - өч кыз һәм бер малай бар, барысы да укып чыгып, үз тормышлары белән яшиләр, миңа оныклар да бүләк иттеләр инде. Барысы да янымда, Самарда яшиләр, еш күрешәбез, бөтен гаилә бәйрәмнәрен бергә уздырабыз. Олыгайган көнеңдә акыллы балаларың, яраткан хатының, күңеленә якын эшең булуын бик зур бәхет, дип саныйм һәм барыгызга да шуны телим.



# МУЗЫКАГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

***Рамил Батыршин - талантлы баянчы, музыкант, Самар филармониясенең рус халык инструментлары ансамбле җитәкчесе, Казахстанның Актүбә шәһәрендә уздырылган Халыкара оркестрлар һәм халык инструментлары ансамбльләре фестиваленең Гран при һәм Самар өлкәсе губернаторы премиясе иясе, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре...***

**Эльмира ШӘВӘЛИЕВА**

Самар татарлары арасында Россия Федерациясенең атказанган артисты исемен йөртүче башка берәү бармы икән? Юк, диләр. Димәк, без Рамил Батыршинның кем булуын, кайда үсеп, ничек шундый зур дәрәҗәгә ирешүен белергә хаклыбыз.

Аның әтисе, Шамил Батыршин, Оренбург татары. Әнисе Нәҗия Насыйбулловна безнең яклардан. Өйләнешкәч, алар башта Оренбургта яшәп алалар. Әтисе Оренбургның музыка комедиясе театрында сәхнә хезмәткәре булып эшли. *«Гомере буе ул Оренбург театрында отып алган музыкаль комедияләрнең һәм оперетталарның җырларын җырлап йөрде. Тавышы да, моңы да булган, тик менә белеме генә җитеп бетмәгән, укыган булса, җырчы буласы кеше иде ул»*, - дип сөйли әтисе турында Рамил Шамил улы. Ә әнисе - гади сатучы. Юк гади түгел, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены иясе. Ул бит 1957 елда гаиләсе белән Куйбышевка, туганнары янынарак күчеп килгәч, Масленников һәм Мичурин урамнары чатындагы беренче гастрономда сатучы булып эшли башлый. Ә ул вакытларда шундый престижлы урында эшләү мактаулы һәм шул ук вакытта бик җаваплы да була. Күп намуссыз сатучыларны һәм директорларны төрмәгә утырткан чакларда, 30 ел буе бер урында эшләп, Нәҗия Насыйбулловна орден алу бәхетенә ирешкән. Димәк, чынлап та, бик уңган һәм чиста куллы кеше булган ул.

Биш яшьлек уллары Рамил һәм кызлары Раилә белән Куйбышевка күчеп килгән гаилә хәзерге Приволжский микрорайоны урынындагы Яблонька бистәсеннән сатып алынган өйдә яши. Җырчы әтисенә карап, улы да бакчага тазлар, чиләкләр, ләгәннәр алып чыгып, шулардан музыкаль инструмент кебек нәрсә әмәлли һәм төпләренә бәрә-бәрә музыка чыгарырга азаплана. Урожайный урамы тәмам тынгы күрми башлагач, әтисе белән әнисе, бу балада өмет бар дип, аны музыка мәктәбенә укырга бирәләр. Инструментны Нәҗия ханым үзе сайлый: тик баян гына! Ә алты яшьлек малайны зур баян төймәләре дә куркытмый, ул шатлана-шатлана ноталар, көйләр өйрәнә башлый. Шул вакыттан башлап, күршеләре таз һәм чиләк шалтыравына түгел, ә ай нурында агылган баян көенә хозурланалар. Кунакка килеп чыккалаган туганнары да Рамилдән татар көйләре уйнатып, җырлашып утырырга яраталар.

Үзеннән дә зур баянын сөйрәп, яшүсмер малай сигезенче сыйныфны тәмамлаганчы, Подпольщиклар чокырында урнашкан музыка мәктәбенә, аннары Куйбышев урамындагы музыка училищесының халык инструментлары бүлегенә йөреп укый. 1969 елда «Ялкынлы яшьлек» ансамблен оештырган Илгиз Колючев аны шуннан табып ала да инде.

*«Бу вакытлар минем күңелдә яшьлегемнең алтын мизгелләре булып истә калган. Мин нәкъ шушы елларда үзебезнең татар халкы мәдәнияте белән якыннанрак танышу бәхетенә ирештем. Без беренчеләрдән булып Куйбышев татарларына тиңсез җырларын, моңнарын, биюләрен кайтаручылар буларак, Металлурглар Мәдәният сараенда уздырыла торган репетицияләргә иҗат канатларында очып бара идек. Ансамбльнең беренче артистлары Илгиз Колючев, Рифкать Фәретдинов, Шамил Сатдаров, Әлфия Гыйниятуллина, Камил Шамкаев һәм башкалар - барысы да очкынлы талант ияләре иде. Бигрәк тә мәрхүм Рифкать Фәретдиновны еш искә төшерәм: ул булган җирдә гел уен-көлке, кызык-мәзәк, шаян сүз хөкем сөрә, ә сәхнәгә чыкканда ул җитди һәм талантлы була белә иде. Һичшиксез, сүз остасы иде ул егет»*, - дип исенә төшерә Рамил әфәнде. Уналты яшьлек егеткә биредә барысы да ошый. Ни дисәң дә, яшьлек - яшьлек инде ул. Беренче җылы карашлар, алкышлар, иҗади уңышлар... Ул бит халкына андыймондый такмаклар гына уйнамый, Салих Сәйдәшевнның Советлар Армиясе маршы, Рөстәм Яхинның классикага әверелгән тиңсез көйләре белән үзенең иҗат юлын яра.

«Ялкынлы яшьлек» составында Самар, Оренбург өлкәләренең татар авылларына, Татарстанга гастрольләргә йөргәндә, егеткә сәхнә тормышы ошаган булса кирәк. Рамил профессиональ музыкант карьерасын сайларга ниятли. Училищены тәмамлаганнан соң, ул ансамбль белән саубуллаша да Ленинград консерваториясенә юл тота. Мәдәният каласы тормышы, югары культура, дәрәҗәле педагоглар - барысыннан да уңа Рамил Батыршин. Укытучылар да үзләрен яңа студенттан уңган, дип саныйлар. Ә барысыннан да бигрәк Ленинград консерваториясе каршындагы училищеның вокал курсында укучы украин кызы Вера уңа. Ирдән...

Рамил консерваторияне тәмамлаган 1976 елда өч шәһәрдә туй гөрли - Ленинградта, Куйбышевта һәм Вераның туган

ягы Полтавада. Яшьләргә тормышларын Пермьда башларга туры килә. Юллама буенча килгән музыка белгечләре Пермьның мәдәният институтын булдыруда башлап йөриләр, ә ачылгач, аның беренче укытучылары да булалар. Әмма Рамил Шамилевич халык инструментлары ансамблен оештыру идеясе белән янып яши һәм күп тә үтмәстән аны оештыра да.

Шулай, музыкага уралып, ун ел гомерләре сизелмичә үтеп китә. Уллары Илдар да инде мәктәп баласы. Тик менә туган яклары аларны һаман җибәрми, һаман үзенә тартып тора. Монда бит аларны туганнары - төзүче Вазыйх Мөхәммәтшин, хирург Шамил Сатдаров, медицина фәннәре докторы Әлфия Хәмәдиева, бертуган сеңелесе, немец теле белгече, доцент Раилә Шакирова һәм, әлбәттә инде, әтисе һәм әнисе көтә... Батыршиннар Самарга кайткач, әнисе Нажиянең авыру икәнлеге билгеле була. Рамил белән Вера да, Раилә дә аны бала карагандай тәрбияләп, 62 яшендә гүргә иңдерәләр. *«Ә әти картаеп, үлем чире белән авыргач, миңа күп эшләргә туры килә иде. Аны күбрәк Вера карады, хәтта күтәреп йөртә иде. Хастаханәдә аның килен булуын белгән табибларның исләре китте. Кайберәүләр үзләренең әти-әнисен дә алай карамыйлар, ә монда килен каенатасын шулай хөрмәт итә. Мин моның өчен хатыныма бүген дә бик рәхмәтле»*, - ди Рамил әфәнде.

Самарга күчкәч, ул филармониягә эшкә урнаша. Директорга Пермьда оештырган ансамбленең чыгышлары язылган видеотасмаларны күрсәткәннән соң, биредә дә шундый ук ансамбль оештыруга рөхсәт ала. Элек Куйбышев филармониясендә тик классик музыка гына башкарылган булса, Рамил Батыршин аны рус, татар, башка милләт халыклары көйләре, кинофильмнар өчен язылган матур музыка белән төрләндерә. *«Безнең Идел буе регионында төрле милләт халыклары күптәннән бер казанда кайныйлар һәм аларның мәдәниятләре табигый рәвештә бер-берсенә үтеп керә, башкаручылар музыканы кайсы милләтнеке дип аерып тормыйлар, сыйфатына карап репертуарга алалар. Менә, мәсәлән, Татарстанның халык инструментлары ансамбленең художество җитәкчесе - рус кешесе, инструментлар да русларныкы, ә репертуар - татарныкы. Татарстан хөкүмәте үзенең территориясендә яшәүче бөтен милләтләрнең дә мәдәниятен үстерергә тырыша. Без бер җирдә яшибез һәм, илдә тынычлык булсын өчен, дуслык мөнәсәбәтләрен сакларга тиешбез. Минем өчен үзебезнең һәм чит милләтләрнең музыкасы дигән төшенчә юк. Бары тик яхшы, профессиональ дәрәҗәдә язылган музыка гына бар. Нинди генә телне, милли музыканы алма - Ходай биргән байлык, тиңсез көй»*, - ди музыкант. Ул әле дә Брамс, Дворжак, Прокофьев, Салих Сәйдәшев һәм Рөстәм Яхин кебек бөек композиторларның музыкасын гына ансамбль репертуарына ала. Күптән түгел алар, 40нчы профессиональ-техник училище директоры Мидехәт Хисмәтов чакыруы буенча, Камышлыга гастрольләргә барып кайтканнар. Халыкның исе китеп: «Без Самара филармониясендә татар һәм башка милләт халыклары көйләре башкарылуы турында белми идек әле. Гомумән, бик яхшы репертуар, бик зур рәхмәт», - дип сокλануларын белдергәннәр.

Дөрес, күпчелек халык югары зәвыклы музыканы аңлап бетерми, дип саный профессиональ баянчы. Бу татарларга гына түгел, башка милләт халыкларына да хас. Чөнки радио һәм телевидение халыкны эстрада һәм популяр музыка мохитында тәрбияли. Ә безнең ансамбльнең максаты - тамашачының күзен зәвыклы музыкага ачу.

Ансамбльгә быел 27 яшь тулган инде. Соңгы 12 елда башкаручылар составы бер дә алышынмаган. Ансамбльнең җитәкчесе Рамил Батыршинга үткән елда 60 ел тулып узган булса, калган музыкантлар - барысы да яшьләр. Балалайка-контрабаста уйнаучы Алексей Турче-





нок үзенең җитәкчесе турында болай сөйли: *«Ул рухи яктан яшь. Шуңа күрә үзе тирәсенә яшь музыкантларны җыя да. Рамил Шамилевич хәрәкәтләнүчән, җитез һәм яңа ачышларга омтылучан».*

Хәләл җефете Вера да 27 ел буе шушы ансамбльнең төп солисты булып эшли. *«37 ел буе эштә дә, өйдә дә гел бергә булсак та, без бер-беребездән туймадык,* - ди Рамил әфәнде. - *Гомерлек мәхәббәт шундый буладыр инде ул. Вера - ачык күңелле кеше, кайгыртучан хатын һәм бик яхшы ана. Минем татар туганнарым да аны бик яраттылар һәм үз иттеләр. Хатынымнан башка кунакка килсәм: «Башкача берүзең йөрмә, Вераны алып кил», - диләр».*

Вера да чын күңеленнән татарларның гореф-гадәтләре белән соклана: *«Әти белән әни вафат булганга күп еллар үтте инде, ә без ел саен укыткан Коръән мәҗлесенә бөтен туганнар җыелып килә, җылы сүзләр белән сагынып искә алалар»,* - дип сөйли ул.

Батыршиннарның уллары Илдар да - музыкант-пианист. Ул Мәскәү консерваториясен тәмамлаганнан соң, шунда яши һәм иҗат итә, сәнгать мәктәбе директоры урынбасары булып эшли. Илдар гастрольләргә еш чыгып йөри. Соңгы мәртәбә Самарга кайтканда, филармониянең симфоник оркестрына кушылып уйнаган һәм безнең тамашачы аны хуплап каршы алган, иҗатына зур бәя биргән. Аның репертуары да бик җитди - Чайковский, Шопен, Бетховен...

«Ялкынлы яшьлек» ансамблендә татар көйләре уйнап, музыкант карьерасын башлаган Рамил Батыршин яңадан татар мохитына кайту мөмкинлеген кире какмый. *«Тик инде хәзер тагын да яхшырак, тагын да катлаулырак программа белән халык алдына чыгармын. Минем максатым - халкыбызда зәвык тәрбияләү, бөек иҗат җимешләренә җәлеп итү, татар композиторлары иҗат иткән иң яхшы музыканы ачып күрсәтү. Әмма*



*җитди музыка гына иҗат үрнәге була ала, дип ялгышырга кирәкми. Безнең ансамбль башкаруында кинофильмнарга, спектакльләргә махсус язылган җырлар да бик матур яңгырый. Аларны өч аккордтан торган такмак дип атап булмый, тулы мәгънәсендә музыка әсәрләре алар. Тамашачылар безнең концертларны бик яратып каршы алалар»,* - ди музыкант.

Ул яңа программалар, репертуар булдыру өстендә бертуктаусыз эшли. Рамил Шамилевич ансамбльнең художество җитәкчесе генә түгел, ул аранжировкалар язучы да, репетицияләр үткәрүче дә, солист та. Хәтта продюсер буларак, бөтен гастрольләрне һәм концертларны да ул үзе оештыра. Авыр, билгеле, әмма бүгенге дөньяда башкача яшәп булмый.

Хәер, Рамил әфәндегә карап, бер дә үзенең яшен биреп булмый. Шул ук янып торучы, елмаючан күзләре, чигәләренә чак кына бәс кунган кара чәчләре, сынын төз тотып, җиңел атлап йөрүләре бу кешенең тәртипле тормыш алып баруы, яраткан эше, гаиләсе белән канәгать булуы турында сөйли.

Менә бу елның 28 мартында Опера һәм балет театры бинасында Николай Меркушкин Рамил Батыршинны һәм башка мәдәният хезмәткәрләрен губернатор премиясе белән бүләкләгәндә дә ул сәхнәгә очып чыккан иде. Губернатор аның костюмына күкрәк билгесе беркеткән арада, Рамил әфәнденең башыннан шундый уйлар йөгереп үткән: «*Кара син аны, озак еллар Мордовиядә эшләгән губернатор рус инструментлары ансамбле оештырып, 27 ел буе Россиягә хезмәт иткән өчен украин хатыны белән яшәүче татар кешесенә премия тапшыра. Әйе, төрле милләт культураларына иркен үсәргә мөмкинлек биргән ил генә шулай бай була. Халкы белән бай*».

Губернатор премиясен алган якташыбызны беренче булып Кабель компаниясенең директорлар советы рәисе Әнвәр Бульхин котлаган булган. Без дә, Рамил ага Батыршинның иҗаты һәм тормыш юлы белән сокланубызны белдереп, губернатор премиясен алуы белән чын күңелдән котлыйбыз һәм аңа иҗади уңышлар теләп калабыз.



***В прошлом номере нашего журнала мы рассказывали о селе Назаровка Клявлинского района – единственном месте Самарской области, где компактно проживают кряшены. На этот раз мы хотим познакомить читателей жунала «Самар татарлары» с ансамблем крещеных татар «Натукай», без которого в селе не проходит ни один праздник. Именно такие фольклорные коллективы призваны сохранять и популяризировать национальную этнокультуру, напоминать людям о забытых обычаях и традициях, праздниках, обрядах, песнях и танцах.***



# «НАТУКАЙ» ОЗНАЧАЕТ НАТАЛЬЯ

Фольклорная группа «Натукай» была образована при доме культуры. Начинать было очень трудно. По крупицам в селе собирали материал, большую помощь оказывали в этом старожилы села. Название группа получила от названия старинной песни, которую пели только кряшены Назаровки. В последствии эта песня станет гимном коллектива.



Не так давно о селе Назаровка узнал Виталий Васильевич Агапов, кряшенский барон, как лаского между собой называют его кряшены, истинный сын своего народа, решивший объединить всех кряшен России. В декабре 2011 года он приехал в гости в село Назаровка для встречи с фольклорной группой. Эта встреча помогла дальнейшему творческому развитию коллектива «Натукай». В январе 2012 года фольклорная группа получила приглашение от Виталия Агапова на ежегодный песенный фестиваль кряшен «Нардуган», где она за свое активное участие была удостоена грамоты. Следующим шагом стало приглашение группы «Натукай» на V Всероссийский фольклорный фестиваль «Тугэрэк уэн», где она стала лауреатом II степени. Вернувшись с фестиваля, через неделю «Натукай» – уже участник многонационального фестиваля в Самаре.

За два года коллектив сумел достичь больших результатов, собрал большую коллекцию грамот, дипломов, кубков, благодарственных писем.



Отрадно, что учасники ансамбля ведут большую работу по приобщению подрастающего поколения к своей этнокультуре. Юнные таланты, участники группы, также неоднократно были отмечены грамотами и ценными подарками. Сейчас, группа готовиться к участию в областном сельском татарском национальном празднике Сабантуй, который будет проходить в селе Камышла Самарской области, и к участию на обрядовом фестивале в г. Казани.

Бесспорно, этот коллектив вносит огромную лепту в дело возрождения культуры села. А будет возрождена культура — возродится село.

**Татьяна Базанова**
учитель начальных классов
Назаровского филиала ГБОУ СОШ №2
им. В. Маскина ж.-д. ст. Клявлино



# ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

***Әңгәмәдәшем бик тә гади кеше. Ул үз гомерендә җитәкче булып та эшләде, тормышны да җигелеп тартты, күңеленә күпләрнең сере дә сыя. Аның һәр адымы, хезмәте якташларымның күз алдында булды. Хәзер инде ул лаеклы ялда. Ләкин элеккегечә сылу сынлы, гел елмаеп торучан, кешеләр белән ихлас күңелдән аралаша, ярдәм итә. Ара-тирә коңгырт күзләре генә моңсуланып киткәли. Анысы инде хәтер төенен кузгатудандыр. Анда бит төрлесе саклана: күңелне әрәтә торганы да, куандыра, бәхетле итә торганы да... барысы да.***

**Фәния КӘРИМОВА**

Венера Хәмит кызы Галимованы Камышлы районында белмәгән кеше бик сирәктер, чөнки халык мәхәббәтен, бигрәк тә олы яшьтәгеләрнең ихтирамын, яулаган кешеләрнең берсе ул. Тумышы белән дә шушы яктан, шушы туфрактан. Салкынлыгы тешне камаштырырлык чишмәләре, бөдрә каенлы, төз наратлы урманнары, уңган-булган кешеләре белән дан тоткан Камышлы авылында дөньяга килгән. Венера ханым сугыш кырыннан яраланып кайткан Хәмит ага белән Минафа апаның мәхәббәт җимеше.

Сугыштан соңгы авыр еллар булуга карамастан, кыз укуга да хирыс, эшкә дә өлгер булып үсеп, мәктәпне тәмамлый. Хыялы табиб булу. Ләкин уку йортында зур конкурс булу сәбәпле, кызга хыялларын җигәнләргә туры килә, һәм ул педагогия институтына читтән торып укырга керә. Шул ук вакытта хезмәт юлын Яңа Усман авылы урта белем бирү мәктәбендә пионервожатый вазифасында башлап җибәрә. Берничә айдан үткен кебек кызны Кләүле комсомол комитетына эшкә җибәрәләр.

Дөрес, комсомол дип аталган кадрлар әзерләү мәктәбе хәзер юк, ул тарихта гына калды. Заманында ул үзенә бер көчле мәктәп иде. Комсомолда башлаган эшне партия әләктереп ала килде. Венера Хәмит кызы башта мәктәпләр бүлеге җитәкчесе, комсомол комитетының икенче секретаре, Кләүле районы “Белем” оешмасының җаваплы секретаре, аннан инде партия райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы, бүлек мөдире һәм, ниһаять, секретаре. 27 ел дәвамында халык белән эшләү тәҗрибәсе шулай тупланә.

Күбегез беләсездер, атның, кыйнасаң да, әлләни ерак китми торганы һәм, киресенчә, йөгәненнән тартсаң да, туктамый алга чаба торганы бар. Венера Хәмит кызы да үзенең хезмәтендә бертуктамый алга ыргылган ат сыманрак булды. Аның шунысы да бар бит, чапкычы атны кинәт туктатсалар, аның йөрәге шартлый. Венера ханым белән дә шундыйрак хәл килеп чыгарга мөмкин иде. Комсомол, коммунистлар комитетлары үзгәрешләр кичерде, илдә болганчык вакыйгалар булып алды.

Ләкин хезмәткә җигелеп, күңелен биреп эшләгән кеше, нинди вакыйгалар булса да, югалып калмый, үз урынын төрле эштә таба ала. Венера Галимова бер ел чамасы Кләүле районы мәгариф бүлегендә методист булып эшләп ала да, өр-яңадан, җиң сызганып, районда социаль хезмәт күрсәтү үзәге ачып җибәрә.

Ачып җибәрә дип әйтүе генә җиңел. Утырып эшләр өчен үз бинаң, кадрлар



булмау сәбәпле, эш алга бара алмый шул. Барысын да булдыру өчен төрле оешмаларның юлын таптау, акча, төзү материаллары, эшчеләр яллау - барысы да хатын-кыз җилкәсенә төшә.

Менә, ниһаять, Кләүле районында халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең ишекләре ачыла. Венера Хәмит кызы янә эзләнә, олылар өчен яңадан-яңа уңайлыклар тудырырга омтыла. Ул өлкә күләмендә иң беренчеләрдән булып олылар, инвалидлар өчен көндезге ял итү бүлеге ачуга ирешә, семинарлар үткәрә. Зәвык белән эшләнгән бүлмәләр, дәвалану, ял итү өчен тудырылган уңайлыкларга куанып, олы яшьтәгеләр, инвалидлар шәфкатьлелек йортына бик теләп йөриләр, киңәшләшәләр, моң-зарларын

түгәләр, исәнлекләрен яхшырталар. Биш ел гомер мәшәкатьләр белән, яңалыклар эзләп, бик күп хыялларны тормышка ашырып сизелми дә үтеп китә.

Һәм көтмәгәндә Венера ханым тормышында кискен борылыш ясый. Яңадан торгызылган Камышлы районы үсеш юлында, кадрлар җитми, төрле оешмалар ачыла. Район башлыгы Сазит Галимуллин Венера Хәмит кызына туган авылына кайтып, социаль үзәкне җитәкләргә тәкъдим ясый.

- Әй, тәвәккәл дә булгансыз икән, Венера Хәмитовна, - дим.

*- Әйе, мине хис, тәвәккәллек, ташып торган энергиям алга әйдәде. Дөресен генә әйткәндә, бер мизгелдә генә уйладым һәм риза булдым. Аллаһының әмере булды микән?* - дип җаваплады ул.

Ә очкынланып торган күзләренә тагы моңсулык инде. Гөрләп эшләп торган җирдән китеп бару, җиңел булмаячагын белә торып, яңадан нәфис иңбашларыңа авыр йөк салу - тәвәккәллек, сабырлык, көч таләп итә. Үз җаен алган гаилә тормышы нишләр, уллары Руслан, Рубен, туганнары ни әйтер? Төрле сораулар аның күңелен борчыса да, 51 яше тулган хатын-кыз җаваплы вазифага каршы атлый.

Тумыштан һәркем үз бәхете белән туа. Хәер, аягыңа уралса, аның бәхет икәнен тоймыйсыңдыр, бәлки. Җиңел килгән бәхет бәхетмени, эзләп тапкан бәхет кадерле, дип тикмәгә генә җырламыйлардыр! Моның асыл мәгънәсен адәм күп сулар аккач, потлап тоз ашагач кына аңлый торгандыр шул. Венера ханыма барысына да канәгать булып яшәргә мөмкин иде. Юк шул, күңел дигәне һаман эзләнә, очар коштай талпынып, яңа үрләргә ашкына. Мактаулы хезмәткә илтүче юл сикәлтәсез, шоп-шома буламыни? Уңышлыкларга юл ача торган сукмакларга гына үлән үстермиләр. Ниндидер югалтулар бәрабәренә булса да.



Камышлыда төпләнгәч, Венера ханым тормышын ак биттән башлады дисәм, һич ялгыш булмас. Яңа өй җиткерү, социаль үзәкне төзекләндерү, кадрлар белән эшләү күп көч һәм эшкә сизгерлек таләп итә. Берничә елдан аны район башлыгының социаль сораулар буенча урынбасары итеп билгелиләр, яңа вазифалар йөклиләр. Янә тагы ике ел дәвамында ул Самар шәһәренә йөреп, социаль яклау министерствосында



алып баручы белгеч вазифасын башкара. Олы яшьтәге ханымның юлда йөрүләре, җитәкчелек эшенең авырлыгы да исәнлегенә йогынты ясамый калмый, әлбәттә, ул йөрәгенә катлаулы операция ясата.

Менә бер генә мизгелгә тын алып, үз-үзеңне тәрбияләп, балаларыңның уңышларына куанып, оныкларыңны сөеп яшәр вакыт җитте. Тик Венера ханым кеше белән аралашмыйча, эшсез тора аламы соң?! Социаль яклау министерствосыннан бик соралгач, ул тагы социаль ярдәм күрсәтү үзәгенә эшкә килде. Беразга гына дигәне өч елга сузылды.

Шуны әйтеп үтәргә кирәк, Венера Хәмит кызы эшләү дәверендә Камышлыда һәм районыбызның һәр авыл үзидарәсе каршында көндезге ял итү бүлекләре ачылды. Өлкә күләмендә беренчеләрдән булып социаль хезмәткәр Кадимә Гатауллина караучысыз калган олы яшьтәге өч авылдашын үз гаиләсенә алып тәрбияли башлады (бер сүз белән әйтсәк, асрамага алу). Россия Федерациясе буенча иң яхшы социаль хезмәткәр дә Камышлы районында. Гөлчирә ханым Мөнирова Мәскәүгә барып, президентыбыз кулыннан бүләкләр алып кайтты. Болар барысы да Венера Галимованың хаклы рәвештә мактаулы хезмәте.

Күп тапкыр Венера Хәмит кызы янына хезмәтем буенча кергәнем булды. Коллективта һәрвакыт тигезлек, тыныч, яхшы мөгамәлә мине әсир итә иде. Ул беркайчан да чәчрәп чыкмас, төптән уйламыйча, фикерен белдерергә ашыкмас, үзе бик тә зыялы. Сүзен һәрчак дәлилләп, хаклыгына ышандырып сөйләр. Шуңа да Венера Галимова иңгә-иң терәлеп эшләгән хезмәттәшләренә акыллы киңәше, җылы сүзе белән таяныч булды, аларның чиксез хөрмәтен яулады. Ә олыларның рәхмәт сүзләрен бергә җыйсаң, бер зур тауны тәшкил итәр иде.

Тормыш юлы үткәндә адәм баласы төрле мизгелләр кичерә: югалтулар, кайгы-хәсрәт, шатлыклар. Венера Хәмит кызын да шундый мизгелләр читләп үтмәгәндер. Авырлыкларга сынмавы, сыгылмавы, бүген дә якыннарына кирәкле кеше булып калуы белән ул бик тә бәхетле кеше диярдем. Хезмәтенә бар көчен биреп эшләп, якташлары күңелендә эз калдырган ханымны милләтебезнең күрке димичә, ни дисең.





# “ТУГАН ТЕЛЕМ – ТАТАР ТЕЛЕ, ТУГАН ҖИРЕМ – САМАР ҖИРЕ...”

24-нче апрельдә бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышлап, “Яктылык” мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын белүче укучылар арасында 1-нче шәһәр бәйгесе узды. Бу чарада Самарның рус мәктәпләрендә белем алучы татар балалары катнашты. (Әйтергә кирәк, алдан конкурста катнашырга теләгән 30-га якын баланың берегә барысы тик 12-се генә килгән иде. Укучыларның яшь аермасы да шактый: Ләйсән Шәрифуллинага 6 яшь булса, 176-нчы мәктәпнең 10-нчы сыйныф укучысы Лилия Зәйнетдиновага 16 яшь иде.) Конкурсның шарты буенча ул ике этапка бүленеп үткәрелде. Алдан укучылар татар теленнән һәм әдәбиятыннан тест яздылар. (Бу тестларны “Яктылык” мәктәбенең татар теле укытучылары әзерләде һәм тикшерде.) Биремнәр, укучыларның яшьләренә карап, 3 төркем өчен әзерләнделәр:

1-нче төркем – 1-4 нче сыйныф укучылары кергән кече яшьтәгеләр төркеме.

2-нче төркем – 5-8 нче сыйныф укучылары кергән урта яшьтәгеләр төркеме.

3-нче төркем – 9-11 нче сыйныф укучылары кергән олы яшьтәгеләр төркеме.

Билгеләнгән вакытта катнашучылар тестны язып бетерделәр. Укучыларның биремнәрне үтәгәндә, гомумән, билгеле дәрәҗәдә сорауларны аңлап, дөрес итеп җавап бирергә тырышулары ачыкланды. Моңа мисал итеп, 154-нче мәктәпнең 5-нче сыйныф укучысы Наилә Газизованың эшен атарга була.

Аннары бәйгенең икенче этабы мәктәпнең актлар залында дәвам итте. Анда укучылар яраткан шагыйрьләренең шигырьләрен сәнгатьле итеп яттан сөйләделәр. Бу бәйгедә катнашучылар да үзләренең татар шигърияте белән кызыксынуларын күрсәттеләр. Шигырь сөйләүчеләргә бәяне «ИПОЗЕМбанк» президенты Лилия Сәлахова житәкчеле-гендәге жюри әгъзалары бирделәр.

1-нче этапта үз төркемендә барлык сорауларга да дөрес итеп җавап биреп, иң күп балл җыйган 154-нче мәктәпнең 5 нче сыйныф укучысы Наилә Газизова танылса, 2-нче этапта сәнгатьле итеп шигырь сөйләүчеләр арасында 121-нче мәктәпнең 6-нчы сыйныф укучысы Фәрзәнә Мәхмүтовага тиңнәр булмады. Бөтен сынауларны үткәч, жюри әгъзалары бу бәйгенең җиңүчеләрен атадылар.

1-нче төркемдә (1-4 нче сыйныф укучылары кергән кече яшьтәгеләр төркеме) урыннар менә шулай бирелде:

1-нче урынга 154- нче мәктәпнең 3-нче сыйныф укучысы Билал Газизов лаек дип табылды, ә 2 -нче һәм 3- нче урыннарга 131-нче мәктәпнең 2-нче сыйныф укучылары Шамил Әюпов һәм Рамил Дәүләтов чыктылар.

2-нче төркемдә (5-8 нче сыйныф укучылары кергән урта яшьтәгеләр төркеме) җиңүчеләр:

1-нче урында – 121-нче мәктәпнең 6-нчы сыйныф укучысы Фәрзәнә Мәхмүтова;

2-нче урында – 154-нче мәктәпнең 5-нче сыйныф укучысы Наилә Газизова;

3-нче урында - 152-нче мәктәпнең 8-нче сыйныф укучысы Азат Гатауллин.

3-нче төркемдә (9-11 нче сыйныф укучылары кергән олы яшьтәгеләр төркеме) бердәнбер катнашучы - 176- нчы мәктәпнең 10-нчы сыйныф укучысы Лилия Зәйнетдинова җиңүче дип табылды.

Бәйгедә җиңүчеләр мәктәптә һәм тормышта бик тә кирәкле бүләкләргә лаек булдылар:

1-нче урын яулаган укучыларга ноутбук һәм кәрәзле телефоннар тапшырылды, ә 2-нче һәм 3-нче урыннарны алган балаларга шулай ук кыйммәтле бүләкләр, шул исәптән электрон китаплар, фотоаппаратлар, MP-3-плеерлар, бирелде.

Иң яшь катнашучы - 6 яшьлек Ләйсән Шәрифуллина аерым призга лаек булды. Ярышта урын алмаган башка укучылар да бүләксез калмадылар.

Барча бүләкләрне дә «ИПОЗЕМбанк» әзерләгән иде.

Самар шәһәренең “Яктылык” татар милли-мәдәни компонентлы мәктәбе директоры Радик Газизов һәм Самар өлкәсенең “Туган тел” татар җәмгыяте президенты Ильяс Шәкүров бәйгенең татар телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү максаты белән үткәрелүе турында әйттеләр, барлык укучыларны бу чарада катнашулары, анда җиңүләре белән котладылар.

Ярышта катнашкан ул-кызларын һәм оныкларын котларга әти-әниләр, әби-бабайлар, хәтта балаларның карт әбиләре дә килгәннәр иде. Бу күренеш укучыларның үзләренең дә татар теле белән кызыксынуларын һәм әти-әниләрнең дә балаларын татар рухында, татар мохитендә тәрбияләргә тырышуларын күрсәтүче дәлилләрнең берседер, мөгаен.

Конкурсны оештыручыларның һәм катнашучыларның фикеренчә, татар телен һәм әдәбиятын белүчеләр арасында үткәрелгән 1-нче шәһәр бәйгесе уңышлы гына булды. Киләчәктә дә аны ел саен ”Яктылык” мәктәбендә үткәрү күздә тотыла.

Бу бәйге Самар шәһәрендә яшәүче һәр татар гаиләсенә үрнәк булып калсын һәм, милли рухлы татар балаларын берләштереп, шундый төр бәйгеләрдә катнашырга теләүчеләрнең санын арттырыр, дигән өмет-теләктә калабыз.

**Самар шәһәре “Яктылык” мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Нурзидә ФӘЙЗУЛЛИНА**









# В САМАРЕ ПРОШЕЛ ПЕРВЫЙ ГОРОДСКОЙ КОНКУРС ЗНАТОКОВ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ СРЕДИ УЧАЩИХСЯ

***24 апреля 2013 года в школе «Яктылык» г. Самара состоялся первый городской конкурс знатоков татарского языка и литературы среди учащихся 1–11 классов самарских школ. К сожалению, пока в нем приняли участие только 12 школьников из разных общеобразовательных учреждений городского округа.***

**Римма НУРЕТДИНОВА**

Мероприятие было организовано муниципальным бюджетным общеобразовательным учреждением — средней общеобразовательной школой «Яктылык» и Самарской областной татарской организацией «Туган тел» с целью сохранения и развития татарского языка в г. Самара.

С напутственными словами перед конкурсантами выступили президент СОТО «Туган тел» И.Г. Шакуров, директор самарской школы «Яктылык» с татарским культурно-национальным компонентом Р.Р. Газизов, член СОТО «Туган тел» А.К. Надиров, пожелав им удачи и победы в предстоящих заданиях.

Конкурс состоял из письменного и устного туров. Ребята выполнили задания по родному языку и литературе в форме теста, затем наизусть прочитали стихотворения из творчества татарских поэтов.

Победителей и участников ждали интересные подарки и призы. Обладателям первых мест были вручены ноутбук и сотовые телефоны. Занявшие 2 и 3 места также получили ценные подарки, среди которых были электронные книги, фотоаппараты, МР-3-плееры. Средства на приобретение победителям конкурса призов и подарков выделил ООО «ИПОЗЕМбанк».

Так, среди конкурсантов младшей возрастной группы первое место занял ученик 3 класса школы № 154 Билял Газизов, ученики 2 класса школы № 131 Шамиль Аюпов и Рамил Давлятов заняли 2 и 3 места соответственно.

Среди учащихся средней возрастной группы первое место заняла ученица 6 класса школы № 121 Фярзана Махмутова. Второе место у ученицы 5 класса школы №154 Наили Газизовой, а третье – у ученика 8 класса школы №152 Азата Гатауллина.

В старшей возрастной группе состязалась всего одна участница – ученица 10 класса школы № 176 Л. Зайнетдинова, которой присудили 1 призовое место.

Первый городской конкурс знатоков татарского языка и литературы среди учащихся 1–11 классов городского округа Самара, по мнению организаторов и участников, удался, и теперь планируется сделать его ежегодным. Надеемся, что в последующие годы в конкурсе примут участие еще больше конкурсантов и между ними усилится конкуренция.



*13 апреля 2013 года в КДЦ им. В. Я. Литвинова прошел, как повелось каждый год по весне, областной детский фестиваль «Поют татарские дети». Организаторы праздника – Самарская областная татарская национально-культурная автономия, Татарская национально-культурная автономия г.о. Самара при поддержке Министерства культуры Самарской области и Дома дружбы народов Самарской области.*

**Наталия ХАРИТОНОВА,** *www.samddn.ru*





# КАК ПОЮТ, КАК ТАНЦУЮТ ДЕТИ!

Как принято, в этом году у фестиваля актуальный юбилейный посыл – он был приурочен к 10-летию Татарской национально-культурной автономии г.о. Самара. Но главным было то, что не меняется со временем – на редкость обаятельное настроение этого праздника, свежесть и искренность того, что делали на сцене его юные участники.





Впрочем, всё началось раньше, нежели развернулось сценическое действо. В фойе работала выставка мастеров разных ремесел. Одно из самых ярких впечатлений – экспозиция авторских украшений Милеушы Завьяловой. Она изобретательно и при этом как-то очень искренне работает в обобщенно-этническомнью-эйджевом духе – фантазийные сочетания оленьего рога, меди, бисера, минералов и окаменелостей, свидетелей геологической истории Поволжья. Традициями татарского искусства заинтересовалась не так давно, но они уже живут в её вольном причудливом творчестве. Она учится и учит других, детей, конечно, тоже... А «специальный гость» праздника – детский журнал «Тылсымлы куллар» («Волшебные ручки») – проводил занимательный мастер-класс для детей и их родителей.

Но вот началась торжественная часть, во время которой поздравляющие – представители Самарской Губернской Думы, администрации г.о. Самара, национально-культурных объединений, бизнес-структур, председатель Регионального духовного управления мусульман Самарской области муфтий Талип-хазрат Яруллин – отдавали заслуженную дань признательности организаторам фестиваля, юбиляру – Татарской национально-культурной автономии г.о. Самара. И шла своим чередом фестивальная программа. Феерически выступали ребята из Тольятти, Казани – прекрасны были соло на курае Лейсан Фазуллиной, живое переменчивое пение Ильмиры Ибрагимовой...

А как порадовали таланты из самарской школы «Яктылык» с углубленным изучением ряда предметов! Складывалось впечатление, что в ней





учатся сплошь юные дарования – столько выходило на сцену удивительных ребят в самых разных, не похожих друг на друга номерах! Сначала они задали тон всему действу – вышли в «танце разных народов», гармонично соединившем русские, татарские, украинские костюмы и танцевальные движения. С полной отдачей и погружением в образ танцевали башкирский, испанский танец, изящнейший менуэт. Младшеклассники радостно, как жаворонки, пели татарские песни, с упоением аккомпанируя себе на ложках.

Огромное спасибо хотелось сказать тем, кто их так замечательно воспитал, увидел и раскрыл их дарования. И учителей из школы «Яктылык» пригласили на сцену, поблагодарили за труд – как это было естественно и при этом этически, педагогически правильно!

Казалось бы, уже было несколько кульминаций праздника, а его торжественный настрой всё оставался на высоте. Вот на сцену вышли крепкие спортивные ребята из футбольной команды «Идель». В этом году они второй раз подряд побеждают на открытом областном турнире по мини-футболу «Дружба народов», демонстрируя завидный спортивный характер и волю к победе (у команды Волжского казачьего войска выиграли в серии пенальти). Директор Дома дружбы народов Дмитрий Мюльбах вручил спортсменам впечатляющий кубок и поблагодарил за красивую игру.

После перерыва, заполненного играми и конкурсами, дети вернулись в зал. Теперь они все стали зрителями и с удовольствием посмотрели спектакль «Шурэле online» Татарского государственного театра драмы и комедии им. К. Тинчурина. В нем на одной сцене сошлись порождения фольклорного сознания: Шурале, Убырлы, Камыр-батыр — и Шрек, Спайдермен, Микки Маус. Их ждут большие испытания, так как злой профессор Доктор Вирус украл единственный экземпляр книги «Татарские народные сказки». Такой вот микс, точно воспроизводящий сознание современного ребенка. Главное, чтобы эта амальгама оставалась многоцветной, чтобы не исчезало богатство и многообразие чувств, смыслов, ассоциаций, связанных с национальной культурной традицией. Завершившийся фестиваль показал, как необходима эта составляющая для становления личности.







# “МОҢЛЫ ЧИШМӘ” ЙОЛДЫЗЛАРЫ

Самар өлкә Халыклар дуслыгы йортында балалар арасында беренче “Моңлы чишмә” караоке-конкурсы булып үтте. Аны “Ипозембанк” ачык акционерлык җәмгыяте ярдәмендә өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте әзерләп уздырды. Ә караоке-конкурсы идеясын уйлап чыгаручы һәм тормышка ашырып баручылар - Фәрхәт һәм Альбина Мәхмүтовлар.

Алар күптән түгел яшьләр арасында да шундый ук конкурс уздырганнар иде.

Хәзер инде менә 17 яшькәчә балаларга да чират житте. “Күмәк җырлау культурасы югалып бара бит. Балаларны шуңа өйрәтү максатыннан оештырабыз шушы конкурсларны”, - ди Фәрхәт Мәхмүтов.

Фәрхәт һәм Альбина катнашучыларны Самарның музыка мәктәпләреннән, районнардан һәм интернет аша эзләделәр. Чарага килергә 17 кеше теләк белдергән булса, катнашучылар уникәү генә иде. 10 - 13 һәм 14 - 17 яшьләрдәге Самар шәһәре, Камышлы һәм Красный Яр районнары балалары башта музыкасыз, аннары караоке көенә кушылып җырлап күрсәттеләр. Дулкынлануларына карамастан, балалар тамашачыларга чын бәйрәм ясадылар.

Әлбәттә, барысы да бик шәп җырлады, дип әйтеп булмый: кемнәр артык дулкынланды, кемнәр көе ноталарына тәңгәл килә алмады, кемнәр тавышы әкрен чыкты. Тик шунысын билгеләп үтәргә кирәктер: барысы да татар җырын яхшы белүләрен күрсәттеләр.

Конкурста катнашучылар арасында Самарның “Яктылык” мәктәбендә генә түгел, башка шәһәр мәктәпләрендә укучылар да катнашты. Мәсәлән, Анастасия Шалимова, татар телен белмәвенә карамастан, “Матур булсын” һәм “Туган як” җырларын махсус өйрәнеп килгән.

Камышлы районының Яңа Усман авылында яшәүче 17 яшьлек Илгиз Хәсәншинның чыгышы алкышларга күмелеп барды. Аның көр тавышы жюри әгъзаларына гына түгел, залда утыручы барлык тамашачыларга да бик ошады. Аңа жюри әгъзалары Л.Р. Нечаева, И.И. Колючев, Д.И. Сәйфиев, һичшиксез, беренче урынны бирделәр. Икенче урында - Анастасия Шалимова һәм өченче урында - Альбина Әпсәләмова (“Яктылык”).

Ә яшьрәк балалар арасыннан беренче урын - Фәрзәнә Мәхмүтовага (121нче мәктәп), икенче урын - Әлсинә Дәүләтбаевага (“Яктылык”) һәм Алсу Мөхетдиновага (121нче мәктәп) тәтеде. Аларның барысына да “Туган тел” җәмгыяте дипломнары һәм призлар - ноутбуклар, планшетлар, смартфон һәм кәрәзле телефоннар тапшырылды. Ә Илгиз Хәсәншинга иң зур бүләк - телевизор бүләк ителде.

***Данияр СӘЙФИЕВ.***



# «РОДНЫЕ НАПЕВЫ»: ЧТОБЫ ПЕСНЯ ТАТАРСКАЯ ЖИЛА…

20 апреля 2013 г. в Доме дружбы народов Самарской области состоялся I региональный караоке-конкурс татарских песен среди школьников «Родные напевы», организованный областным татарским обществом «Туган тел». Призванный сохранять традиции национального песенного искусства, этот конкурс привлёк молодёжь в первую очередь своей формой - популярным в наши дни пением-караоке, когда есть возможность исполнять песню под аккомпанемент заранее записанной музыки.

Караоке - замечательное изобретение человечества, ведь оно придумано именно для непрофессионалов и даёт возможность публично петь даже тем, кому, как говорят, «медведь на ухо наступил»: фонограмма для такого певца становится «скелетом», на который можно опираться и не бояться спеть плохо. А что уж говорить о тех, кто любит и умеет петь…

Интересно, что само слово «караоке» образовано слиянием двух слов: японского «кара» (пустота) и английского «орке» (orchestra - оркестр). Пере-







фразируя это сочетание слов, можно сказать: «пустоты» в конкурсе, который организовал «Туган тел», не было вовсе! А было пение - замечательное, пусть даже и не профессиональное, наполненное большой душевной теплотой и желанием показать миру всю красоту и богатство татарской музыки…

Конкурс проводился только в одной номинации - сольное пение. В нём приняли участие несколько десятков человек в возрасте от 10 до 17 лет, которые соревновались в двух возрастных категориях - средней и старшей. Прослушивание старшей группы было 17 февраля, и вот теперь дошла очередь до ребят среднего возраста.

Каждый участник исполнял два вокальных произведения, одно - без инструментального сопровождения (этот тур назвали «а капелла», но это не совсем точно: акапелльное пение - в первую очередь многоголосное хоровое пение, без инструментального сопровождения), а вот во втором туре ребятам было предложено выбрать из 50 песен одну и исполнить её караоке.

Как пояснил председатель жюри конкурса, вице-президент общества «Туган тел», заслуженный работник культуры РФ и Республики Татарстан, руководитель ансамбля песни, танца и поэзии «Ялкынлы яшьлек» Ильгиз Исмаилович Колючев, идея проведения подобных конкурсов возникла в связи с тем, что песенное творчество как жанр постепенно угасает - именно непрофессиональное пение, пение в кругу друзей, за праздничным столом. И его, конечно, нужно возрождать.

Трудно не согласиться с И. И. Колючевым и его тревогу можно понять. Действительно, люди старшего поколения (и, конечно, не только татары) помнят, как популярно было в советские годы пение - на всех застольях, на всех праздниках, личных и общественных, даже на улицах - люди шли из гостей и пели песни - и народные, и эстрадные (которые по сути были тоже народными - та же «Надежда - мой компас земной». Анна Герман, Эдита Пьеха, Лев Лещенко и многие другие дали миру песни, которые знали и пели за каждым столом люди всех национальностей)…

Но если советские песни сегодня хотя бы иногда, но всё же звучат публично, то с песнями на национальных языках картина совсем иная. Если в семье перестают петь, если родители не приучают детей к пению на родном языке - то постепенно песенный жанр уходит в небытие…

Так что замечательно, что у ребят, которые приняли участие в этом конкурсе, была возможность поближе познакомиться с татарскими песнями, поискать среди них те, которые ближе к душе, проникнуться их духом.

10-летняя Альфинур Махматова из Красного Яра, например, выбрала песню о войне и посвятила её (хотя со сцены это и не было произнесено) своему прадеду, который погиб в Великую Отечественную. На конкурс девочка приехала вместе с мамой, выступала в ослепительно красивом платье, которое купили специально для выступлений на сцене (в родном селе она уже выступала в песенных конкурсах и даже заняла на последнем конкурсе «Красноярские звёздочки» второе место в районе).

- А поёшь ли ты песни на родном языке дома? - спрашиваю девочку.

Она улыбается:

- Конечно, пою, и дома, и на конкурсах. На свадьбе у сестры недавно пела.

Мама Альфинур Аниса Махматова добавляет:

- Она даже когда пылесосит пол, поёт! И я, конечно, очень этому рада. Потому что это важно, это продолжение традиций…

- Вы сама музыкант?

- Нет, я работаю процедурной медсестрой в районной поликлинике. Но музыку люблю. И считаю, что такие конкурсы очень нужны, потому что дети должны знать свою национальную культуру, знать песни, не забывать родной язык…

А вот другая участница конкурса - 17-летняя студентка Самарского социально-педагогического колледжа Анастасия Шалимова - татарского языка не знает - вот так получилось… Но песни выучила добросовестно и пела очень выразительно и, что немаловажно, уверенно. У неё необычайно красивый низкий голос, «бархатное» меццо, и зал отметил эту выразительность горячими аплодисментами, а жюри присудило девочке второе место.

Уже после выступления, в перерыве, пока жюри подводило итоги, нам с Асей и её подругой и однокурсницей Алиной Апанаевой довелось пого-

ворить о музыке и об этом конкурсе. Девушки уверены, конкурс «Родные напевы», хотя он и первый по счёту, - это большое событие в жизни татар, и он обязательно приживётся. И дело даже не в том, что спонсоры конкурса приготовили ребятам просто царские подарки: за призовые места - плазменный телевизор, нетбук, MP3-плееры и т. д., всем остальным участникам, даже тем, кто не занял никаких мест, - вручили дипломы участников и симпатичные плюшевые игрушки, мальчикам - футбольные и волейбольные мячи.

- Конечно, дети есть дети, особенно маленькие, для них игрушки в качестве приза - это очень большая радость и стимул продолжать петь, - говорит Ася скорее даже не как участница конкурса, а как будущий музыкальный педагог. - И тем не менее главное в этом конкурсе - то, что все мы, и дети, и взрослые, слышим и исполняем песни на татарском языке.

Однокурсница Аси Алина добавляет с восторгом:

- Честно говоря, я даже не ожидала, что будет так здорово. Я сама из Татарстана, в Самару приехала учиться. И сегодня, когда пришла в Дом дружбы народов, словно в родной дом попала: все говорят по-татарски, звучат татарские песни - это так приятно!

- Мы специально составили такой большой список из 50 песен, - чтобы, готовясь к конкурсу, дети имели возможность хотя бы по одному разу просмотреть каждую песню, может быть, пропеть её, прежде чем выбрать одну для исполнения перед публикой, - поясняет Ильгиз Исмаилович Колючев. - Так что это не просто соревнование и не просто «раздача» призовых мест, у конкурса более глобальные задачи.

Кстати, о членах жюри. Помимо Ильгиза Исмагиловича Колючева, в его состав вошли директор общества «Туган тел» Данияр Ирекович Сайфиев и доцент кафедры хорового дирижирования и сольного пения Поволжской социально-гуманитарной академии Людмила Романовна Нечаева.

Жюри оценивало выступления участников по 10-балльной системе, по сумме набранных в обоих турах баллов и выявлялись победители.



Надо сказать, что оба тура были очень интересными. Первый - потому что, по сути, это было «домашним заданием»: дети выбирали песни сами, загодя, и было интересно узнать об их предпочтениях. Второй - потому что это был настоящий парад музыки и… кинематографического творчества: ребята пели глядя на большой экран, вывешенный над сценой, на нём, помимо слов песен, сменяли друг друга кадры видеозаписи по теме песни.

Алсу Мухутдинова, пятиклассница самарской школы № 121 выбрала песню про гармонь. Айгуль Нуризянова, 15-летняя ученица самарской школы «Яктылык», спела песню «Рябина моя» - очень красиво звучал её мощный голос - меццо-сопрано, сопровождая не менее красивый видеоряд: красоты родной природы, раздолье полей и лесов… Кроме того, у Айгуль был очень богатый национальный костюм, но самое главное - длинная коса - украшение любой девочки! - в которую были вплетены изящные украшения наподобие жемчужин…

Её ровесница и одноклассница Альбина Абсалямова очень душевно, с невероятным трепетом в голосе исполнила песню про маму - этой девочке присудили третье место.

А вот победителем конкурса стал 17-летний Ильгиз Хасаншин из села Новое Усманово Камышлинского района, можно сказать, наш самарский Робертино Лоретти. Юноша буквально сразил публику татарской народной песней «Сибелэ чэчем» - «Вьются волосы» - и получил главный приз спонсоров - телевизор.

В завершение конкурса все его участники получили подарки - их вручали директор общества «Туган тел» Данияр Сайфиев и член совета этого общества Фархат Махмутов.

Ведущая праздника - преподаватель Самарского социально-педагогического колледжа Альбина Махмутова - очень тепло поздравила всех его участников, пояснив, что по условиям конкурса было присуждено только три места, в номинациях победителей не определяли, но все без исключения дети молодцы и потому заслужили подарки за участие в конкурсе.

После этих слов ребята просияли улыбками и с радостью сфотографировались на память вместе с организаторами и членами жюри конкурса.

***Светлана Ишина***

**P.S.**

Знаете, что было самым интересным на этом конкурсе лично для меня - не как журналиста, а как обычного слушателя? То, что не зная татарского языка, я смогла понять, о чём поют ребята. Сама музыка, сама манера исполнения и, конечно, видеоряд, который был представлен на экране, давал полное представление о содержании каждой песни. Юные вокалисты смогли сделать главное - донести до слушателя дух каждой песни. Наверное, потому, что каждому из них хотелось не просто взойти на сцену и хотя бы несколько минут почувствовать себя эстрадной звездой, но и потому, что для каждого из них татарская песня - родная песня, «родной напев». И очень отрадно, что никакие современные поп-ритмы, «унифицирующие» музыку и выхолащивающие из неё её сердечность, не могут заслонить главное - душу народа. А она, эта душа, эта сердечность, конечно, живёт в песне. И передаётся из поколения в поколения благодаря таким вот конкурсам…



*Имя татарского писателя Халика Садри появилось в печати в 1912 году. Но литературной деятельностью по-настоящему он начал заниматься только после Великой Октябрьской революции. Он проявил себя во всех литературных жанрах: в прозе и поэзии, драматургии и публицистике. Любимой темой в его творчестве была пропаганда техники. В этом он оригинален как писатель. С самого начала своего творчества Х.Садри работает над тематикой, связанной с механизмами.*

**Шамил БАҺАУТДИН**

# Халик САДРИ

Халик Садри родился в 1890 году в селе Старое Ермаково Бугурусланского уезда Самарской губернии в семье батрака. Когда ему был всего один год, умер отец, а в шестилетнем возрасте совсем осиротел - умерла мать. С 7-8-летнего возраста он начал батрачить у деревенских баев. А потом начал учиться и одновременно работал в сельской школе. Ему было 10 лет, когда очень умный и добрый сельский кузнец Гасым абзый помог ему переехать в Бугуруслан и поступить учиться в татарскую школу. Проучившись два года, он поступил в ремесленное училище и в 15 лет окончил его. Затем устроился на работу.

До революции Халик Садри побывал во многих городах России и работал на разных предприятиях. В 1905-07 годах на нефтяных промыслах в г. Баку он работал масленщиком; в 1907-1909 годах - в Оренбургской типографии помощником машиниста; в 1909-10 годах - в Уфе в типографии «Шарык» электромонтером; в 1910-12 годах - машинистом паровой мельницы в Бурецком уезде Уфимской губернии; в 1912-15 годах в Бугурусланском уезде на нефтеразведочном промысле машинистом и в 1915-17 годах работал механиком в Самаре. Там же познакомился с В. Куйбышевым. Таким образом, до революции он прошёл очень сложную жизненную школу.

Сразу после февральской революции он вступил в ряды партии большевиков. Под руководством В. Куйбышева, вёл работу среди заводских рабочих и активно боролся против Временного правительства. После победы Октябрьской революции по предложению председателя Самарского ревкома В. Куйбышева при Самарском Губкоме была организована секция татаро-башкирских большевиков, председателем которой был назначен Халик Садри.

В середине 1918 года Х. Садри организовал отряд Красных партизан для борьбы против белочехов, потом со своим отрядом вступил в Чапаевскую дивизию. Летом этого же года после занятия Самары белочехами, ЦК РКП(б) направил его на Архангельский фронт, где Х. Садри был ранен.

Потом работал в Москве, принимал участие в освобождении Казани. Приехав в Самару, он работал председателем бюро татарских коммунистов при Губкоме и одновременно редактировал газеты на татарском языке.

В 1920-21 гг. он боролся против кулацкого мятежа и банд Колчака, организовывал батальоны, на Бугульминском, Карабашском фронтах был военкомом.

После гражданской войны Халик Садри снова вернулся к своей профессии и в 1922-25 годах работал механиком на Бугурусланской электростанции. Позднее он стал её директором. В 1925-28 гг. учился в татарском коммунистическом университете г. Казани. Окончив его, Халик Садри начал работать ответственным секретарём парткома при управлении Казанского трампарка. Потом был назначен директором завода «Спартак». В 1931 году избран председателем Татарского Областного совета изобретателей. В 1938 году был назначен председателем репертуарной комиссии Татарского управления искусств.

С самого начала Великой Отечественной войны Х. Садри ушел на войну и служил батальонным комиссаром до 1946 г. Был награждён двумя орденами Красной Звезды, орденом Отечественной войны второй степени, медалями. После войны начал работать уполномоченным Литфонда СССР при Татарском Союзе писателей. В связи с 30-летием ТАССР Х. Садри был награждён орденом «Знак Почёта».

Реликты тотемизма прослеживаются и в своеобразной культуре сновидений. У самарских башкир существовали различные толкования снов, в зависимости от того, какое животное приснится человеку. Так, если снилась злая собака, то это предвещало появление врага, добрая – верного друга, если человек во сне доил корову – это к добру, если снилась сорока – будут новости, ворона – следует ожидать неприятностей.

И сегодня в каждом башкирском селе рассказывают о сверхъестественных существах, якобы обитавших в этих местах. Так, например, рассказывают о находившихся недалеко от поселений водоемах, в которых водились драконы-аждаха, затем их унесли облака, а водоемы эти со временем высохли. Рассказывают также о злом существе албасты, образ которого стал у самарских башкир нарицательным (так могут назвать любую женщину с нечесаными волосами).

В памяти местных башкир сохранился еще один фантастический персонаж – бисура. Его описывают как маленькое неопрятное существо, живущее в доме. В рассказах и поговорках сидит он за печкой, подпоясавшись поясом. Бисура, в общем-то, является безобидным персонажем – просто он отпугивает своей неряшливостью. Исследователи, однако, указывают, что когда-то бисура считался злым существом, которое причиняло людям болезни и другие неприятности. Сегодня этот образ также стал нарицательным: неряшливому человеку могут сказать: «Ходишь, как бисура».



Есть поверья о шурале, убыр, мяскяй. Башкирский фольклор имеет много общего с татарским, что является дополнительным свидетельством близкого родства этих народов и их культур.

Ислам также оказал большое влияние на фольклор самарских башкир. Различные мусульманские святые стали популярными героями легенд и преданий. Все это является свидетельством сложности и многообразия башкирского фольклора.

До революции в каждом башкирском селе была мечеть, затем все они прекратили существование. Сегодня мечети действуют в башкирских селах Муратшино и Таш-Кустьяново.

Вновь проводятся традиционные праздники – Йыйын, Каргатуй и др. благодаря активной работе общественных организаций «Курултай (конгресс) башкир» Самарской области и г. Самары. В Самаре и в области работают башкирские музыкальные коллективы, членами которых в основном являются дети и молодежь. Звучит голос знаменитого музыкального инструмента курая, исполняются красивые традиционные танцы.

Башкирская культура является яркой неотъемлемой частью многонациональной культурной палитры Самарской области.

**Михаил Кржижевский,**
кандидат исторических наук, доцент кафедры туризма и гостеприимства и кафедры «Гуманитарные дисциплины» филиала ФГБОУ ВПО «Российский государственный университет туризма и сервиса» в г. Самаре





# САМАРСКИЕ КАЗАХИ: ТРАДИЦИИ В УСЛОВИЯХ СОВРЕМЕННОСТИ

***Одним из тюркских народов Самарской области являются казахи. В прошлом они, как и башкиры, являлись кочевниками-скотоводами. Южные районы Самарского края когда-то служили местами летних кочевий казахов. Постоянно представители указанного народа стали селиться на территории области начиная с первой половины XX в. В основном они проживают в восточных и южных районах нашей области: Большечерниговском, Кинель – Черкасском, Красноярском, Большеглушицком, Красноармейском, Кинельском, а также в самой Самаре.***

Самарские казахи сохранили многие особенности традиционного хозяйства и культуры. Животноводство продолжает играть важную роль в экономике, поддерживаются традиционные ремесла. Сегодня у некоторых пожилых людей сохранились отдельные элементы традиционного костюма, а во время национальных праздников казахи, как и многие другие народы области, активно используют стилизованную одежду. В настоящее время можно увидеть стилизованную на традиционный манер одежду, в которой присутствуют самые разные цвета: зеленый, синий, золотистый, белый, красный. В современной кухне присутствует множество традиционных блюд мясного и молочного происхождения. Одним из наиболее распространенных блюд является ет – отварное мясо без соли и приправ. Другое популярное традиционное блюдо – бешбармак. Для его приготовления используют котел, в котором варят баранину, затем, вынув мясо, опускают в этот котел тесто. Когда оно сварится, то его кладут на отдельное блюдо, на него нарезают отварное мясо, а сверху посыпают жареным луком и заливают мясным бульоном.

У казахов сохранилась давняя традиция заготавливать мясо впрок в копченом, замороженном и соленом виде. Из конины готовят разные колбасы: тонкие кишки животных заполняют маслом и жиром, а иногда для приготовления колбасы используется цельный кусок мяса с костью, помещаемый в толстую кишку.

Одним из основных напитков является чай, который заваривается в специальном чайнике. Казахи пьют чай с небольшим количеством кипяченых сливок или молока. Пиала с чаем традиционно подается в правую руку. Традиционным молочным напитком служит кумыс.

Религией казахов является ислам. Казахи отмечают религиозные, а также национальные праздники.

Наиболее ярким традиционным казахским праздником является Наурыз, который отмечается в день весеннего равноденствия. Он симво-



лизирует наступление традиционного Нового года и весны. Этот праздник торжественно проводится в нашей области каждый год в одном из районов, где проживает много казахов. Устраиваются конкурсы юрт, коллективов художественной самодеятельности, звучат национальные напевы и исполняются яркие танцы. Звенит домбра – национальный струнный музыкальный инструмент казахов.

Активно отмечаются и небольшие семейные праздники – найры, которые связаны с началом либо с завершением какого-либо этапа хозяйственной деятельности. Каждое такое мероприятие сопровождается праздничным пиром.

В области работает Самарская региональная казахская национально – культурная автономия «Ак жол» («Светлый путь»), выходит в свет газета с таким же названием на русском и казахском языках. В Самаре и в области работают казахские творческие коллективы.

Уже стало доброй традицией проведение областного фестиваля «Казахская красавица», в котором принимают участие девушки из Самары и из районов Самарской области. На этом конкурсе учитывается не только внешняя красота участниц, но и знание ими языка, обычаев и традиций своего народа. Проводится также аналогичный конкурс для юношей «Казахский джигит».

В Кинельском районе есть казахское поселение, которое так и называется – Аул Казахский. Оно дает прекрасную возможность погрузиться в мир традиционной культуры казахского народа. В этом поселении был открыт для посетителей этнографический музей – юрта «Мурагер» («Наследие»). Это - единственный в области музей, где стационарно экспонируется юрта – традиционное жилище казахов, которые в прошлом, как отмечено выше, вели кочевой образ жизни. Данная юрта находится в специальном помещении, и посетить ее можно в любое время года. Участники местных творческих коллективов всегда рады выступить перед гостями. В юрте можно ознакомиться с предметами традиционного быта казахов (например, рассмотреть такие предметы, как бараньи косточки асык, в которые и сегодня любят играть казахские дети; торсык – кожаную флягу, предназначенную для хранения воды или кумыса), увидеть национальные костюмы (мужские и женские), попробовать горячий чай.







Надеемся, что с течением времени это поселение будут посещать все больше экскурсантов из разных регионов.

**Михаил Кржижевский,**
кандидат исторических наук, доцент кафедры туризма и гостеприимства и кафедры «Гуманитарные дисциплины» филиала ФГБОУ ВПО «Российский государственный университет туризма и сервиса» в г. Самаре

Сөембикә

# БЕЗДӘ КУНАКТА

Самар татарлары

Бер гасырлык олы тарихы булган «Сөембикә» журналы Сезгә, һичшиксез, таныштыр: аны әле «Азат хатын» (1991 елга кадәр журналыбыз шушы исемдә дөнья күрде) чагында ук әбиегез, дәү әниегез, әниегез алдыргандыр, яратып укыгандыр. «Сөембикә» өегездә кадерле кунак булгандыр!

Бүген дә шулай булсын иде ул!

Бөтентатар хатын-кызлар журналы «Сөембикә»не хаклы рәвештә милләтебезнең йөзек кашы дип атарга мөмкин. «Сөембикә» журналы,1913 елда дөнья күргән тәүге саныннан алып, һәрвакыт халкыбыз мәнфәгатьләрен яклаучы басма булды һәм шулай булып калыр да. Чорлар алышына, илләр таркала, журналның исеме һәм тышкы кыяфәте үзгәрә, әмма аның җисеме һәм кыйбласы үзгәрешсез кала: милли рухны саклау, гаилә җылысын сүрелдермәү, бала тәрбияләү, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне, милли йолаларыбызны яшәтү, әхлакый сафлыкны ныгыту, хак тарихыбызны барлау, хатын-кызларның җәмгыятьтәге ролен күтәрү, дөньяви офыкларын киңәйтү...

«Сөембикә» — Татарстаныбызның визит таныкламасы. Журналны бүгенге көндә дөньяның татарлар яши торган барлык төбәкләрендә дә яратып укыйлар. Кулыгызга алсагыз, аны Сез дә үз итәрсез: кемнеңдер өенә ул туган яктан сәлам булып килеп керер, берәүләрне тарихи Ватаннары белән бәйләр, якынайтыр, балаларын, оныкларын туган телгә өйрәтү өчен "Әлифба" ролен үтәр, сердәшкә, дуска әйләнер... Кыскасы, ул Сезнең көтеп алган, яратып укый торган журналыгыз булыр. «Сөембикә»не укучылар сафына кушылу быел 100 яшьлеген бәйрәм итүче милли басмага зур бүләк тә ул!

Журналыбыз «Роспечать» каталогына кертелгән («Почта России» каталогының «Республиканские журналы» бүлеге), аңа Россиянең теләсә кайсы почмагында да язылырга мөмкин.
Индексыбыз – 73002. Бергә булыйк!

Сайтыбыз: www.syuyumbike.ru
Электрон адресыбыз: ssuum@yandex.ru
suyumbike@telebit.ru


# ПАНИ ФӘРИДӘ

## *АЛТЫ ЙӨЗ ЧАКРЫМ... СЕЗНЕҢЧӘ НИЧЕК, КҮПМЕ БУ, АЗМЫ? ИНДЕ ХӘЗЕР ШУНЫ БИШКӘ – АТНАНЫҢ БИШ КӨНЕНӘ ТАПКЫРЛЫЙК. ШАКТЫЙ КИЛЕП ЧЫГАМЫ?*

***Мин әле генә сездән Фәридә ханымның бер ел буе атна саен күпме юл узганын исәпләттем. Моның өчен аңа иртәнге сәгать дүрттә торып, биштә инде өеннән чыгып китәргә, көндезге унбердән кичке дүрткә кадәр эш урынында булырга, сәгать биштә кабат автобуска утырып, юлга кузгалырга туры килә. Өй ишекләрен ачып кергәндә кичке ун тула яза...***
***«Бу кадәр еракка барып эшләп йөрмәсә...» – дип тә уйларга өлгердегезме? Ашыкмагыз. Карына-яңгырына, эссегә-суыкка карамыйча юлга чыгып китү өчен шактый җитди сәбәбе булган шул аның. Гасырлар кичкәндә исемнәренә, фамилияләренә кадәр үзгәрешләр кичерсә дә, үзләрен «без татар!» дип яшәгән милләттәшләре тел өйрәнергә көткән Фәридә ханымны.***

**Гөлнур САФИУЛЛИНА**

Ире үлеп, тол калганда, җиләк кебек япь-яшь чагы була әле аның. Тик үзен кызганып, озак күз яше түгеп кенә утыра алмый: итәк тулы бала – олысына биш яшь, уртанчысына – өч, төпчегенә бер яшь... Аларны ашатасы, киендерәсе, укытасы, үстерәсе... «Ул көннәрдә минем бик зур байлыгым бар иде – белемем...» – ди ул. Тормыш беркадәр эзгә төште, җайланды дигәч тә, узмас, очы-кырые күренмәс кебек тоелган атналар-айлар була әле. Үз-үзенә кул салудан («Әллә машина астына ташланыргамы?!» дигән бәйләнчек уй хатынга озак гомерләр, чынлап та, тынгы бирми) аны балалары һәм... уку коткара. Белемне һәрвакыт зур хәзинәгә санаган ханым 45 яшьтә читтән торып кабат югары уку йорты ишекләрен ачып керә – бу юлы Ташкент дәүләт университетының психология факультетына. Улы белән бер тирәдә студент булып китүенең төп максаты, иң беренче чиратта, үз-үзенә ярдәм итү була.

Ә аннан кинәт – кискен борылыш: табиб булдым дигәндә генә дөньялар үзгәрә дә куя. Туган-үскән җирләрендә – Үзбәкстанда алар һич көтмәгәндә артыкка әйләнәләр. Башка сыймас хәлләр. Балаларының киләчәген уйлап, шәһәрнең өч җирендә берәр бүлмәле булса да, өч фатир алып куелган, үзенеке белән – дүртәү. Барысы да кала... «Үзебезне коткарырга кирәк иде...» – ди ул. Ташкенттан һаман да кузгалмаулары өчен кызының гомере белән түли язгач, шундый карарга килә ул. Тән яралары төзәлә, җан ярасы гына... Әниләре дә, балалар да ул көннәр

турында хәзер бик сирәк искә төшерәләр: шөкер, барысы да узган инде, югалган малны кызганып утырудан ни мәгънә – тапмаганы әнә тау кадәр...

Ә ул чакта... ул чакта хәлләр, чынлап та, коточкыч була. Әйе, бер көн дә монда калырга ярамый, китәргә кирәк. Тик кая?!

Улы Альбертны, университет тәмамлагач, юллама белән эшкә Калининград шәһәренә җибәргән булалар. Гаилә шул якка күз төбәп, юлга кузгала. Билгесезлеккә алып барган юлларны соңрак тагын да узарга туры килә әле Фәридә ханымга. Тик монысы иң авыры булгандыр... Җанда өмет һәм өметсезлек. Бер яктан – котылганга сөенү, икенче яктан – алда ни көтәсен белмәү...

Альбертның тулай торактагы бүлмәсенә килеп төшәләр. Аз гына соңрак – кая барсыннар?! – Фәридәнең әнисе белән абыйлары да шушында килеп сыена. *«Мин ул чакта уйдан гына тордым,* – ди ул. – *Эш юк, торыр җир юк... Ләкин теләсә нинди авыр хәлдән дә чыгу юлы табылмый калмый. Мин дә аны таптым. Польшага эшкә чакырган тәкъдимне кабул иттем».*

Тәвәккәл карар була бу!

Ул көннәрдә кулындагы һөнәре, дөресрәге, һөнәрләре өчен үз-үзенә рәхмәтне ничәмә-ничә тапкыр әйтте икән?! Кирәк дисәләр – массаж ясый, укол сала, урында яткан авыруны карый, кирәк икән – энә белән дәвалый... Фәридә ханымның шифалы куллары кагылгач – энә белән дәвалау курслары үткәргәч – унбер ел буе балага узмаган Эля Сулькевич игезәкләр таба. Мондый хәбәр халык арасында кайда да тиз таралучан – Россиядән килгән ханымга эләгү өчен чиратка басалар... Бер ел эчендә Калининградта бер бүлмәле фатир сатып алырга җитәрлек акча эшли Фәридә. Ул бер елда ике ил арасын шактый таптарга туры килә: анда – эше, монда – балалары, якыннары...

Юл мәшәкатьләре, юл газаплары белән язмышының тагын бер борылышына җиткәнен сизәргә дә өлгерми ул шулай.

– Польшада гына яшәп калырга теләмисезме?..

Биредә танышкан милләттәшләренең берсе – Матей Ризванович шулай ди дә үз тәвәккәллегеннән үзе аптырап туктап кала. Бу сорау артында нинди тәкъдим ятканын Фәридә дә, әлеге минутларда аның кырыенда булган кызы Әлфия дә бик яхшы аңлыйлар, әлбәттә. Андый чакта фикереңне тиз генә туплап, җавап биреп буламыни ул?!

– Әни, ризалаш! Ризалаш инде!

Матей Ризванович – Польша татары. Моңарчы утыз елдан артык Канадада яшәгән. Гомеренең көзенә кереп барганда күңел, җан, кан тартуы буенча туып-үскән җирләренә әйләнеп кайткан. «Кешенең соңгы урыны әби-бабасы, әти-әнисе каберләре белән янәшә булырга тиеш», – дип саный. Хатыны, буй җиткән улы аның бу фикерләре белән килешмәгән: шулай итеп, алар – анда, этиләре бер ялгызы монда...

Ике ялгызак, гадәттә, бер-берсенә терәк булыр өчен кушыла. Фәридә дә булачак иренә: «Ярый соң, калам», – дигәндә, шуңа өметләнә. Борылыш артында ук язмышның яңа сынавы көтеп торганын кайлардан белсен соң ул?!

Үзеннән егерме яшькә өлкән Ризвановичта шикәр чиренең өченче стадиясе булуы белән килешергә өлгерми, табиблар яңа диагноз куя: яман шеш... Иренә ул, чыннан да, терәккә әйләнә. Ышанычлы терәккә. *«Биш ел буе без аны кадерхөрмәттә генә яшәттек, тәрбияләдек,* – дип сөйли Фәридә ханым. – *Миннән дә, кызларымнан да канәгать булып китте. Соңгы васыятен дә җиренә җиткереп үтәдек. «Мөселманча күмәрсең мине, Фәридә»,* – *дигән иде. Аның ике абыйсы, әтисе бездән биш йөз чакрымда күмелгән. Матейны дә шул мизарда җирләдек. «Каберләребезне карап торырсың»,* – *диде. Мин аңа сүз бирдем. Ике-өч айга бер барып, догаларымны укып, кабер өсләрен җыештырып кайтам – миннән башка яннарына йөрер кешеләре юк аларның Польшада».*

**Мөгаллимә булган көнгә китереп җиткергән юл... Юк, анысы да бер дә кыска түгел. Хәер, озынлыктан бигрәк, авырлыгы, сикәлтәсе, борылышлары истә...**

Ә бит Ризвановичның варислары шактый булып чыга – Фәридә ханымга йортларыннан кечкенә бер өлеш кенә тия. Аның каруы, иренең пенсиясе аңа күчә. Россиядә кырык өч елга якын хезмәт стажы өзелеп калган хатынга монысы да язмышның зур бүләге була. Хәер, пенсиягә карап кул кушырып утыра торган кешемени Фәридә?! Үз эшен ачып җибәрә: ул табиб-массажист та, табиб-косметолог та, психолог та, энә белән дә дәвалый... Аның кулыннан әллә никадәр сугыш ветераны уза. Олы кешеләр белән уртак тел таба белә ул! *«Аларның рәхмәтләре ихлас була, шуңа гомерем буе өлкәннәргә тартылдым бугай»,* – дип елмая Фәридә.



Ә аннан, чынлап та, «пенсиягә» чыгар чак килеп җитә – гел авыру карап булмый бит. Әмма аның тынгысыз җаны һаман бер теләк тели: «Күңелемә ошаган эш, бер шөгыль бирсәң иде, Ходаем!»

Ышанасызмы-юкмы, Фәридә ханымның бу теләге, бер көн килеп, чынга аша бит. Болай була. Телефон шылтырый. «Пани Фәридә! – дип дәшә таныш булмаган тавыш. – Сезгә Варшавадан, министрлыктан мөрәҗәгать итәбез. Без татар теле укытучысы эзлибез. Сезнең хакта безгә мөфти Мискевич әйтте. Риза булмассызмы икән?» Дәресләр бирергә бер Кырым татары тапканнар, инде Казан татарлары телендә сөйләшүче татар да кирәк булып чыккан. (Гомере читтә узса да, Актаныш кызы бит ул Фәридә! Бибинур әбисе белән гел татарча сөйләшеп үскән.) Шул кичне үк Варшавага резюме әзерләп җибәрә Фәридә ханым һәм озак та үтми: «Сез безгә туры киләсез», – дигән җавап та ала.

Тормышта янә бер борылыш була бу. Көтелмәгәнрәк булса да, бу юлы – җайлы, ипле, хәтта киң күңелле борылыш. Ә көн саен алты йөз чакрым ара узу... Беренчедән – ул инде артта калган: Ольштыннан Белостокка укытырга ул хәзер атнага ике тапкыр – шимбә һәм якшәмбе

көннәрендә генә барып йөри. Икенчедән – бер ел эчендә укучылары ирешкән уңышлар ул юл газапларын күптән оныттырган! Кайчан гына парта артында утырган Ян, Жанетта һәм Лукашлар бүген инде үзләре дәрес бирә ала. *«Алар шулкадәр тырыш!* – дип гаҗәпләнеп, сөенеп сөйли Фәридә ханым. – *Берсендә Адам белән Жанетта мине үзләренә кунакка чакырды. Шаккаттым: өйләренең бөтен җире поляк сүзләренең татарчага тәрҗемәсе язылган язулар белән тулган. «Шулай өйрәнергә җиңелрәк», – диләр. Жан тартмаса, кан тарта дию дә дөрес. Лукаш: «Мин – поляк, ләкин татарча да сөйләшергә телим», – дип, дәрескә килде. Тел аңа чагыштырмача җиңел бирелгәнен күргәч: «Ачыкла әле, синдә татар каны булырга тиеш», – дидем. Шулай булып*

Белостокта милләттәшләрен туган телгә өйрәтү өчен Фәридә ханымга поляклар бөтен мөмкинлекне дә тудырган: бүлмә бирелгән, хезмәт хакы каралган, хәтта җиде яшьтән җитмешкәчә булган (Пани Зина – Зәйтүнәгә җиде дистәдән дә артык әле!) укучыларга кадәр табылган. Үзе яшәгән Ольштында татарлар өчен «Сөембикә» дигән үзәк ачарга



**«Белеме, һөнәре — кешенең иң зур байлыгы...» – Фәридә ханым тагын шул ук сүзләрне кабатлый.**

*чыкты да! Баксаң, ерак әбисе татар икән Лукашыбызның.*

*Бер ел, бер карасаң, күп вакыт та түгел шикелле, әмма без татар халкының тарихы белән дә таныштык, тел күнекмәләре дә алдык, бергәләп өчпочмак, гөбәдия, кыстыбый пешердек. Укучыларым Казанга килсә, югалып калмаслар дип уйлыйм. «Исәнмесез? Хәлләр ничек? Кайда торасыз?» кебек кенә сорауларга бик иркенләп җавап бирәләр».*

теләгәч тә, бернинди каршылык булмаган аңа. Шәһәрнең 6 нчы мәктәбендә класс бүлеп биргәннәр – Фәридә ханым анда көн саен икешәр сәгать татар теле укыта. (Укучыларның өчесе үз оныклары – Алимөхәммәд, Камилә һәм Тимур.) Бердәнбер проблема – дәреслекләр, китаплар җитмәве. Шуңа күрә Казанга килсә, китап җыя да китап җыя ул... «Татарча-полякча» сүзлек тә бик кирәк – анысын да булдыра алган кадәр әлегә үзе төзи.

Бөтендөнья татарларының V съездында Фәридә Зәйнетдин кызы Фәррахова (Ризванович) конгрессның «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнде. Әйе, аның кебек фидакарьләр милләтебезгә кирәк, бик кирәк. *«Динеңне югалтсаң – үзеңне, телеңне югалтсаң - милләтеңне югалтасың. Барысы да үз кулыбызда»,* – Фәридә ханымның бу сүзләрендә, һичшиксез, хаклык бар.

Ә борылышлар... Алар инде алда булмасын иде!

# ТУЙ БАЛДАГЫ

***ҮЛЧӘМНӘРЕ АЗ ГЫНА АЕРЫЛА ТОРГАН АЛТЫН БАЛДАКЛАР, КОЧАКЛАШЫП, АК АТЛАС ЯТАКЛАРЫНА СЕҢГӘННӘР. КЫЗ, ИНДЕ КӘЛӘШ ДИЯРГӘ ДӘ ЯРЫЙДЫР, ТАТЛЫ ЕЛМАЕП КУЙДЫ...***

***Туй балдагы – кияү белән кәләшнең бәхетле мизгелләренең тәүге шаһиты ул.***
***Туй балдагын буыннан-буынга тапшыру дөрес түгел. Һәрхәлдә, кәләшнең анасы үз балдагын кызына көмеш туен билгеләп үткәннән соң гына тапшыра ала. Ә менә әти-әни балдагын эретү юлы белән яңа туй балдаклары кою рөхсәт ителә.***
***Бармагыңа бер кигән балдакны салмавың, бигрәк тә киеп карарга биреп тормавың хәерле.***

**Асия ЮНЫСОВА**

Гөлназ бүген инде ничәнче мәртәбәсенә хәтфә тышлы футлярны кулына алды. Ачты да люстрадан төшкән яктылыктан дәррәү җемелдәп башлаган пар балдакка озак-озак карап торды. Әйе, кәләш инде ул. Әүвәле ярәшелгән кызны кәләш дип йөрткәннәр түгелме соң? Шәһәр кызы борынгы йолаларны ул кадәр үк нечкәләп белми. Әмма үзенең Ниязның кәләше икәнлеген тәгаен белә. Чөнки егет ягы Гөлназның әти-әнисеннән кызның кулын сорарга килеп китте. Алар икенче шәһәрдә яши. Башкала бөтен яшьләрнең туплану, уку урыны булгач, Гөлназ белән Нияз инде алты еллап таныш, алты еллап яратышкан егет белән кыз хәкемендә. Бергә «Сәләт» лагерена йөрделәр, күрше уку йортларында югары белем алдылар. Инде кыз егетен армиядән дә көтеп алды. Ниһаять, гаилә кору өчен нәкъ вакыты кебек. Бу никахка ике як та бик разый иде. Булачак кайнана Гөлназның намазлы кыз булуын Аллаһы бүләге кебек кабул итте. «Янәшә басып, намаз укырбыз, Алла боерса», – дипләр сөйләнде. Була торган хәл.

Кодалар кайтып киткәч, Гөлназ белән Нияз «Якут» кибетенә барып, пар балдак – туй балдагы сатып алдылар. Озак-озак сайладылар. Теләсә нинди алтын балдак туй балдагы була алмый икән ләбаса. Бу кадәресен кибеттә дә сөйләделәр, үзләре Ин-



тернеттан да карадылар. Туй балдагы бернинди сырсыз булырга тиеш икән. Янәсе гомер юлы кытыршы узмасын өчен. Хәтта бриллиант булса да, каш ярамый. Монысы нигә икән тагын. Гәрчә... кашлысы балдак түгел, йөзек була бит инде аның.

Васыйлә атна буе бәхетле йөреп тә бүген боегып калган сеңлесенә карап-карап ала. Туйга әзерләнергә дип Әлмәтенә кайтып киткән Ниязын юксына булыр бу бала. Әнә, бәхет иясе балдакларын ничәнче мәртәбә ачып карый. Кыз бала шулай инде ул, бәләкәй чагыннан үзен гүзәл кәләш күреп хыяллана. Кияүгә барачак көнен әкияти бер мизгел итеп, кияү куенын бәхет багына капка күреп көтә. Югыйсә кыз вакытның чиста, садә дәвере бәхетнең нәкъ үзе ләбаса. Моны соңыннан, хыялларың чәлпәрәмә килгәч кенә аңлап аласың шул.

Абау, нигә мондый уйларга бирелә соң әле Васыйлә, әллә сеңлесенең бәхетенә көнләшәме? Булмаганны! Әмма ул да, Җир йөзендәге бөтен тере затлар кебек, олы мәхәббәт турында хыялланды. Мәктәптә укыганда да, хәтта студент елларында да вак-төяк мавыгулар белән хисләрен вакламады. Ул көткән егет, аңа тиң яр сыйныфташлары арасында да, вуздагы сабакташлары арасында да очрамады. Ләкин күңел яктылыгы йөзенә нур булып кунган кызны тормышта иптәш, гомерлек яр итәргә ымсынучылар бетеп тормады. Шуңа күрә соң чиктә барыбер ялгыз калмасын белә иде. Егетләргә каты бәрелмичә, миһербанлы мөнәсәбәтеннән мәхрүм итмичә генә ул җаны тансыклаган кешене ипле генә көтте. «Их, шул Васыйләгә өйләнсәң иде», – дип авыз сулары корып йөргән төркемдәшләре дә, авылдаш егетләр дә берәм-берәм башлы-күзле була торды. Арада Мирза дигәне: «Их, Васыйлә!» – диде дә ерак чик буена хәрби кеше булып китте, бөтенләйгә югалды. Югыйсә Васыйләдә җавап хисләре борный башлаган иде. Әмма кыз өлгереп җитмәгән хисләрне бәйдән ычкындыра торганнардан түгел иде. «Китә бир, юлыңа ак җаймә», – булды Мирзага җавап.

Арадан берсе – Фаяз дигәне зерә дә нык өтәләнеп йөргән иде. Хәтта бер тапкырында йөрәктәгесен бигрәкләр дә үзәккә үтәрлек итеп әйтеп ташлады: «Их, Васыйлә! Егетләр рәнҗеше төшәр дип тә уйламыйсың. Иртәгә ерак юлга чыгам. Гомергә онытмамын, һичьюгы бер үптер инде. Үкенечкә каласың бит». «Бар әле, йөрмә монда эч пошырып», – булды аңа җавап. Иртәгәсен Фаяз юл һәлакәтенә тарыды. «Оныта алмаучы» булып Васыйлә үзе бу дөньяда яшәп калды. Яратканга түгел, егетнең шул соңгы ялынычын санга сукмаганга битәрләде ул үзен. Йә бер үптерсә, укасы коелган булыр идеме.

Кыз күңелен кузгатырдай егет ул укытырга билгеләнгән авылда көткән икән.

Ильяс – гармунчы, уен-көлке остасы. Нәкъ Васыйлә эзләгән егет. Шуңа күрә яшь укытучы агроном егетнең кулын кире какмады. Алчак холыклы егет Васыйләдән дә шундый туарылу көтте. Ләкин Васыйләне аңлаганнар белә: сулышыннан ут кабынырдай чагында да ул ялкынын тышка өрми. Ярата икән, тын гына, тып-тын гына. Бәйләнми, акланмый, таләп итми, дауламый. Җавапка да шундый ук затлы мөгамәлә өмет итә. Кыз үзе инан-



ган дөреслектән, таш яуса да, тайпылмый торган сабыр холыклы. Бу ныклык нечкә күңелен ят тукынулардан аралый торган бердәнбер калканы аның. Сафлыкның саклык кораллары исәбендә сүзләр юк. Боланныкы кебек матур күзләреннән мөлдерәп тамарга торган күз яшьләре бар. Тик елавы да сүзсез аның.

Чисталыкта саташкан Васыйлә зөфаф төне җәймәсен, кеше-кара күргәләгәнче, таң белән мунчага барып юып, үтүкләп тә куйды. Оялта торган тапны бер кеше дә, хәтта Ильяс та күрми-белми калды. Элек заманда урыслар кыланган кебек, бауга чыгарып эләсе булган да бит аны!

Ильяс белән тату гына яшәп киттеләр. Уңган киленне кайнана да бик яратты. Васыйләнең әнисе генә: «Әй, кызым, усал авылга килен булдың. Ничекләр чыдап бетәрсең икән?» – дип һаман саен кабатлый торган иде. Васыйләгә ни – әллә усал алар, әллә юк. Укучылары, аларның ата-аналары, бергә мәктәптә эшләүче хезмәттәшләре аның өчен үлеп торган кебек. Иң мөһиме: ирнең анасы, ә ул киленгә сокланып туя алмый.

Бер елга якын торалар инде. Балага узмый Васыйлә. Менә шул чагында исенә төшерде инде Ильяс зөфаф төненең шаһиты булырга тиешле җәймәне!

Васыйлә елады гына.

Юк гаеп өчен ничек акланырга кирәклеген белми иде ул.

Мәктәптә бала-чага белән әвәрә килеп атна тиз үтеп китә. Ял көннәре җитүгә яшь хатын кияве үз авылларына кайтырга өнди. Анда озак еллар урын өстендә яткан энесе белән олы хастаны карау өчен яше һаман олыгая барган әнисе Васыйләнең ял көннәрен тилмереп көтәләр. Казанда ук башлы-күзле булудан тыелып торуының, күрше авылга укытырга билгеләнү өчен тырышуның чын сәбәбе дә асылда шушы иде бит инде. Ике кадерле кешесенә төшкән авырлыкны ире Ильяс та бүлешер дигән яшерен өмете дә бар иде.

Алай булмаска охшап тора.

Баштарак кияүләп йөрүгә каршы түгел иде Ильяс. Аннары Васыйләнең үзен генә дә җибәрә башлады. Инде менә ялгызына авылга кайтып йөрүләргә рөхсәт беткән икән.

– Йөрмисең. Бер син генә түгел. Башка туганнарың да бар. Алар кайтып карасын.

Кайталар, алар да караша. Олы хаста бөтен кешегә дә җитә ул. Тик менә дистә еллар урында яткан энесенең тәне бик нәзберек шул. Аның кием-салымын, җәймәсен һич җой-сыр калдырмыйча, Васыйлә кебек үтүкләргә, мунчада җаен белеп, Васыйлә кебек юындырырга, сүзне Васыйлә кебек, күңелне дә күтәрерлек, җебемәслек тә итеп сөйләшә белергә кирәк. Васыйлә калдырган рәхәтлек, тәртип, чисталык аларга нәкъ бер атнага җитә. Атна ахырында ана тагын тәрәзәдән Таштугай ягына таба карый башлый, егетнең дә муены тәрәз тарафына кыйшая. Васыйлә моны һәр күзәнәге белән тоеп тора. Аларны кызганудан җаны елый. Араларда нибары сигез генә чакрым ләбаса. Машиналы кешегә генә түгел, җәяүлегә дә көн дә урарлык ара. Югыйсә Ильяс басу-кырлар

**Нигә тагын туйдан башланган уй күз яшьләренә күчте? Чөнки күз яшьләре туйдан соң озак көттермәде.**

түрендә аннан да күбрәк йөри торгандыр. Күңел күзең йомык булса, койма артындагысын да күрмисең дә, тоймыйсың да шул.

Ниһаять, җәйге каникуллар башланды. Әниләренә озаккарак кайтып торырга да булыр. Укытучы хезмәтенең шул бер рәхәт ягы – җәйге ялы. Җәйге якта агрономның да эше тыгыз. Боекмас. Боегырлык та түгел. Монда өй тулы кеше, ике энесе, этисе, әнисе. Аннан бит Василә дә кайтып-килеп йөрер – ирен зарыктырмас.

Василә, канатланып дигәндәй, җыештырынып йөрде. Юмаган кере, кырмаган сыры калмады. Эшен бетереп, кершәндәй ак идәнгә басып түргә узды. Өстен алыштырды. Төшке ашка кайткан Ильяс аның авылына җыенганын, күзе белән сөзеп, күзәтеп утырды.

– Йөрмисең!

– Ничек инде йөрмим. Хәзер дә, каникул вакытында да йөрмәгәч... Болай да имтихан вакыты дип, ике атна кайта алмадым. Ни хәл яталардыр анда. Әйдә, үзең илтеп куй мине!

– Йөрмисең! Ник йөргәнеңне беләбез! Миңа да бала төшертеп килдең. Шуңа безнең бала юк.

Йа Алла! Ильясның күңел төбендә әнә нинди кортлар уйный икән! Юк, еламасын әле Василә. Бу тиклем оятсыз гаепләүгә ка таба тәгәрәтеп кенә җибәрде. Уйнап кына сөйләшүе булса, балдакны тотып алыр да кабат Василә бармагына кигереп куяр. «Уйнап кына сөйләшәм», – дип хатынының битеннән үбәр. Бәлки, үзе үк әле әниләренә илтеп тә куяр. Энесен мунча кертешер.

Ир кеше ярдәме бик кирәк анда.

Балдак киң идән сайгагыннан матур гына тәгәрәп барды да, Ильяс янына якынлашып кына килгәндә, әллә нинди бер сикереш ясап, моңынчы барлыгы да абайланмаган ярыктан базга тәгәрәде.

– Төш базга! Алып мен балдакны!

– Менә монысы булмас инде. Сау бул!

Шул китүдән Василә Таштугай мәктәбенә кайтмады. Казанга китеп эшкә урнашты. Әйберләрен Ильяс әниләренә китереп киткән. Василә әйбәт кенә яшәп китте. Тора-бара фатирлы да булды. Кулын сораучыларны борып җибәрә торды. Озак еллар әле авылдагы кадерлеләрен тәрбияләп торды. Гомере Казан белән авыл арасында йөреп узды. Туганнарына аның мондый фидакарьлеге бик ошай иде. «Ай-һай, ялгыз каласың», – дип артык борчылганнары сизелмәде. Үзенә дә бәхетен табарга өлгерер сыман иде әле.

Ильяс, Василә киткәч, армия хезмәтенә алынды. Кайткач килде.

– Василә, бала булмау минем аркада

**Интернетта балдак, бигрәк тә туй балдагы хакында әллә нинди юрамалар язалар. Куркам мин... Никахсыз калырмын, дип.**

җавап сүзләре дә эзләмәсен. Үзенең кемлеген, асыл бәясен Василә болай да белә. Акланугa калгач, булмый инде ул. Хатын ике көнлек кенә кием салым тыккан иде. Сөйләшү мондый юнәлеш алгач... Васил олы сумкасын тартып чыгарды... Озаграк торылыр, мөгаен.

– Ярый, исән генә торыгыз. Мин барып кайтыйм әле.

– Йөрмисең!

– Үзең дә килеп китәрсең бит әле.

– Сал балдагыңны!

Василә ишек бавына тотынган җирдән иренә борылып карады. Чынлап сөйләшәме соң бу?

– Сал балдагыңны!

Ике кабатлады. «Бу балдагым өчен мин сафлыгым белән түләдем», – дип әйтеп торсынмы-юкмы. Юк, әйтмәсен! Ишетүдән, аңлаудан узган, ахрысы, аның ире.

Хатын ничә сәгать җыештырынып йөреп, шешенә төшкән бармагында тыгызланган балдакны чак бушатты. Аягына кигән иде инде. Идән таптап тормас өчен, алтын балдакны түрдә утырган Ильяс икән. Бала вакытта янгында пешкәнмен мин. Шуннан икән. Балдагыңны алып килдем. Әгәр син элекке Василә булсаң, әйдә, кайтабыз.

– Мин элекке Василә түгел. Аннары бит бер салган балдакны кабат кию хәерлегә булмый диләр. Мин үкенмим, син дә үкенмә. Тормышыңны мәшәкатьсез кеше белән корырга тырыш.

Ильяс кабат өйләнмәде. Инде дөньядан да китеп барды.

Апасының кызы Гөлназның балдак белән әвәрә килүе онытыла төшкән хатирәләрне яңартты.

– Матур апам, сиңа бер нәрсә әйтимме? Әле әнигә дә әйтмәдем. Дөресрәге, ничек әйтергә белмим. Нияз... миңа шылтыратмый.

– Ә син үзең шылтырат!

– Шылтыраттым мин, Матур апам.

– Соң?

– Ул миннән балдакларны үзенә кире бирүне сорады.

– Туегыз булмыймыни? Бу ни дигән сүз!

– Ул... бер маржа тапкан үзенә. Минем белән әдәпле итеп йөрү туйдырган булган икән аны. – Атна буе тыштан бәхетле күренергә тырышып та, эчтән уена йомылып йөргән Гөлназ үкереп елап җибәрде. – Минем бармакка хаслап алган балдакны бүтән кеше киярgә тиеш түгел бит инде, әйеме, Матур апам! Алай ярамый бит, әйеме, Матур апам! Мин бүтән еламыйм. Бүтән бер кешене яратмыйм да... Кияүгә дә чыкмыйм. Синең кебек яшим. Син бәхетле бит, Матур апам! Әйе бит, Матур апам!

– Мин бәхетле, сеңлем, бәхетле. Әмма сине кияүгә бирәбез әле. Туйда биисем килә лә минем. Әниеңә әйтергә кирәк. Алар бит туй дип мәшәкатьләнеп йөри. Ә син моңаерга ашыкма. Балдак берни түгел ул. Мин балдак белән бәйле уйдырмаларны да, маҗараларны да күп ишеткән инде. Әнә минем күршем Сәгыйдәттәй улы килененә алган балдакны үзе киде дә куйды. «Сез өлгерерсез әле. Минем бер дә балдак киеп йөргәнем булмады», – дип. Килене бик тузынып караган иде дә, аннары: «Рәхәтләнеп ки, әни», – диде дә үзенә икенчене сатып алды. Син Ниязга дигән балдакны үзенә бир, үзеңә дигәнен ломбардка тапшыр да, акчасын пешмәгән кияввеңә кайтар. Бәхете шуннан булсын.

– Ә минем бәхет? Бер уңмаган һич уңмый, ди бит әби.

– Әле генә кияүгә чыкмыйм дигән идең. Хорафатлар укып утырганчы, әнә «Милли-ят сүзлеге»н укы. Анда ниләр язалар икән балдак турында. Укып карыйк әле. Менә! «Бөҗра. Аяк беләзеге, богауның кулга, аякка кигерелә торган бөҗрасы» дигән. Димәк, сеңлем, син бу балдактан арынсаң, богаудан да котыласың гына. Һәрхәлдә минем сеңлемә лаек түгел кешене яратып йөреп әрәмгә үткән елларың кыршавыннан атлап чыгарсың. Әйдә, без моны яхшыга юрыйк. Тик, кара аны, мин синең туеңда киярга дип тектергән күлмәгемне сатарга тормыйм. Ә син туеңа чулпы, беләзек, алка әзерлә. Яңача булсын. Борынгыны яңарт. Синең кара толымнарыңа чулпы бик килешер ул.

– И Матур апам, рәхәт синең белән. Ә бит туй балдагы дип күпме җырлар язалар, кинолар төшерәләр. Балдагымны мин ломбардка тапшырмыйм. Үзем киярмен. Акчасын Ниязга болай гына бирермен.

– Гафу ит син аны. Арагызга күләгә ятқырма. Шул чагында үзеңә дә бәхет нуры кунар.

Туган көненә тәңгәл килгән көндә Василә туйга барды. Матур күлмәген киде. Мөселманча узган никах-туй гаҗәп күңелле була икән. Гөлназ фикердәше, үзе кебек әхлаклы егет белән кушылды. Бәрәкәтле гомер насыйп булсын аларга.

# Bulgary Park: жить в удовольствие!

**Стартовал новый социально значимый проект компании «Феникс», нацеленный на организацию семейного отдыха, развитие туризма и спорта в Самарской области.**

**Bulgary Park** располагается в живописном районе Царевщины и занимает территорию в 25 га. Его отличительная особенность в том, что помимо коттеджной застройки, проект предусматривает обширную рекреационную зону, включающую лесопарковый комплекс, фермерское и рыбное хозяйства, детские и спортивные площадки и многое другое. Сохранение природного богатства Самарской Луки – дубовых рощ и лесных озер – в сочетании с обустроенными набережными, облагороженными зонами отдыха, комфортабельными коттеджами дает уникальную возможность жить и отдыхать в экологически благоприятном месте, не пренебрегая при этом привычными благами цивилизации.

На территории Bulgary Park разделена на два жилых квартала: «Западный квартал» располагается на равнинной местности с выходом к озеру, «Восточный квартал» - непосредственно в дубовой роще.Запланирована вся внутренняя инфраструктура: огороженный по периметру участок, асфальтированные дороги, круглосуточная охрана, централизованные коммуникации (газ, электричество), работа управляющей компании.




Bulgary Park предложит своим посетителям многочисленные варианты как активного, так и спокойного досуга:теннисный корт, бассейн, велосипедные дорожки, волейбольное и футбольное поля, баскетбольная площадка, с наступлением холодов легко трансформирующиеся в каток. Плюс возможность заниматься в многочисленных секциях под руководством известных тренеров и мастеров спорта.Для дружеских и семейных пикников , предусмотрена зона барбекю. Птицы и животные устроенные в благоустроенных вольерах,порадуют детей и взрослых. Раздолье здесь и для любителей рыбной ловли- озёра с ценными видами рыб находятся здесь по всему периметру парковой зоны.

**ЖИТЬ В УДОВОЛЬСТВИЕ – ВОТ ДЕВИЗ БУДУЩИХ ВЛАДЕЛЬЦЕВ BULGARY PARK!**

**(846) 922-83-00**
**www.domuvolgi63.ru**





## Хөрмәтле редакция!

Мин «Яктылык» мәктәбендә 5-11 сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятын укытам. Без рус телле укучыларга Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы раслаган программа нигезендә белем бирәбез. Әдәбият дәресләрендә балалар татар әдипләренең иҗатын һәм әсәрләрен программа кысаларында өйрәнәләр, төрле иҗади эшләр башкаралар. Шушы иҗади эшләрнең бер төре - әдәби геройга хат язу.

11нче сыйныфта әдәбият дәресендә илебезнең азатлыгы өчен Бөек Ватан сугышында катнашып, инде сугышлар беткәч, Польшаның Згеж шәһәре госпиталендә вафат булган язучы Гадел Кутуйның әле 1935 елда ук язылган “Тапшырылмаган хатлар” повесте белән таныштык.

Түбәндәге повестьне укучылар белән өйрәнеп бетергәч, мин аларга өй эше итеп баш герой Искәндәргә хат язарга куштым. Иң уңышлы дип табылган хатның авторы – 11нче сыйныф укучысы Асия Шәрифуллина иде. (Аның башка язмаларын да өлкәбезнең “Бердәмлек” газетасы битләрендә еш күрергә мөмкин). Ул үткән уку елында Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты, Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге Россиянең төрле төбәкләрендә һәм Татарстанның үзендә яшәүче, 9-11 нче сыйныфларда укучы татар балалары өчен оештырган “Илһамлы каләм” әдәби конкурсында катнашып, ике турны уңышлы гына үтеп, 2010 елның 24 апрелендә Казанга финалга бару бәхетенә иреште, һәм анда минем яраткан укучым әдәби эшләре өчен “Рәхмәт хаты” белән бүләкләнде.

Ә инде 2010- 2011 нче уку елында без Асия Шәрифуллина белән бу конкурста икенче тапкыр катнашырга булдык. Быелгы “Илһамлы каләм” әдәби конкурсына минем укучым үзенең әдәби герой Искәндәргә язган хатын, әнисенә багышлаган шигырен, үзе иҗат иткән әкиятен һәм Хатыйп бабасының истәлегенә багышланган парчаны җибәрде. Тагын ике турны да уңышлы гына үтте һәм 3 нче урынга лаек булды. Агымдагы елның 27 апрелендә Казанда Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының актлар залында тантаналы рәвештә танылган татар язучысы Мәдинә Маликова минем яраткан укучым Асия Шәрифуллинага 3 нче урын өчен диплом һәм автографы белән үзенең китабын, ә миңа Асияне бу конкурска әзерләвем өчен рәхмәт хаты тапшырды.

2011 елда Асия мәктәбебезне алтын медальгә тәмамлады. Бүгенге көндә ул – Казан федераль университетының экономика факультеты студенткасы.

Самар шәһәре “ Яктылык” мәктәбенең татар теле һәм
әдәбияты укытучысы Нурзидә Фәйзуллина

# ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ “ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР” ӘСӘРЕНДӘГЕ ӘДӘБИ ГЕРОЙ ИСКӘНДӘРГӘ ХАТ

## Исәнме, Искәндәр!

Мине шулай бик тиз генә искә төшерә алмавыңа мин бер дә гаҗәпләнмим. Мин күптән инде синең белән бер сөйләшмәкче идем, тик син бу сөйләшүне һаман кичектереп килдең. Түбәндәге сүзләрне укыгач, син бу хатны Намусың язганын төшенгәнсеңдер, дип уйлыйм. Кайдан килеп чыктың әле соң син дисеңдер инде. Мин сиңа бу хатны синең мүкләнгән җаныңның инде кайда икәнлеге күптән онытылган, син егет чагында мине яшереп куйган тирән бер почмагыннан язам. Син ул чакта мине сиңа үзең теләгәнчә яшәргә комачаулаучы, җаныңның тузан бөртеге кадәр кирәкмәс бер нәрсәсе дип санадың. Ә минем синең битарафлыгың белән көрәшәсем, сиңа бик тә ярдәм итәсем килде. Тик синең күңел күзең берни күрмәде, йөрәгең дә моны сизмәде. Шуңа мин дә көрәшмәскә булдым. Шуннан соң мин ерактан гына синең үз бәхетеңне, үз язмышыңны үз кулларың белән әкренләп җимерүеңне күзәттем. Кайчакта мин“ бу бәндәнең йөрәге, җаны бармы икән”, дип тә уйлап куя идем. Тик мин бик тә ихтыярсыз, көчсез идем шул. Мин үземне тирән йокыга талган кебек хис иттем. Ә инде син үзеңне өзелеп сөйгән, олы йөрәкле Галиянең тормышын, бәхетен җимерә башлагач, мин аңыма килдем һәм үземдә синең белән көрәшерлек зур бер көч барлыгын тойдым. Мине бу йокыдан берничә дә карамыйча, сине элеккеге кебек яратучы хатыныңның кайнар күз яшьләре уятты.

Мин Галиянең сиңа дип язылган дүрт хатын да укып чыктым. Алар әрнү, үпкә, сагыш, үкенү хисләре белән сугарылган хатлар иде. Ә бу бөтен хисләрнең сәбәбе – син идең, Искәндәр! Белгәнемчә,син Галияне бик тә яраткансың. Тик мин бернәрсәне аңламыйм, синең өчен нәрсә соң ул мәхәббәт?!. Синеңчә, мәхәббәт ул - ләззәт, бетмәс-төкәнмәс шатлык, канәгатьләнү хисе. Бәлки, бу чынлап та шулайдыр. Ләкин бу мәхәббәт дигән асылташның (бриллиантның) бер ягы гына бит, чөнки “мәхәббәт” сүзе үз эченә бик күп мәгънәне сыйдыра. Мәхәббәт ул - бер-береңне аңлау, сөйгән кешең хакына бик күп нәрсәдән ваз кичерергә сәләтле булу, аңа ышану, чын күңелдән

алдан аны бәхетле итәргә тырышу, ә инде иң соңыннан гына үзең турында уйлау.

Кызганыч, син кулыңдагы бәхет кошын очыргансың, аны тотып кала алмагансың. Галиясез яшәгән вакытларыңда да яраткан кешеңнең кадерен белеп яшәргә өйрәнмәгәнсең. Шуны аңламыйча, син беркайчан да бәхетле була алмаячаксың һәм сиңа үзеңә генә үпкәләргә кирәк, минемчә. Гаилә бәхетен белү серенә син ике йөрәк парәң – ике балаң белән калган хатыныңнан өйрән. Ә Галия, синнән яшь булса да, гаилә бәхетенең кадерен белә, бу бәхетне саклап калырга тырыша.

Шуңа мәхәббәтнең бәллүр савыт кебек бик уалучан нәрсә икәнен, аны саклауның үз үзенчәлеге барын яхшы аңлый ул. Тик син аңа бу гаилә бәхетен бергәләп сакларга булышмагансың. Булышу түгел, син моны хәтта аңламагансың, ә, бәлки, аңларга да теләмәгәнсең. Сиңа бит гаиләңә караганда башкаларның синең турында нәрсә уйлаулары мөһимрәк була шул. Ә бервакыт син гаиләңне ташлап чыгып ук киттең. (Бу, минемчә, синең бердәнбер дөрес адымың иде, чөнки ул Галияне киләчәктә бик күп бәлаләрдән саклап калды). Әгәр якыннарыңны авыр хәлдә калдырып китсәң, алардан котылсаң, син ирекле артист булырсың,алда торган проблемаларың да үзеннән-үзе хәл ителер, дип уйладың син.



Искәндәр! Тик син бернәрсәне аңламадың: әгәр проблемалар, хәл ителәсе әйберләр синең йөрәгеңдә, эчеңдә икән, алардан шулай эшләп кенә качып котылып булмый ул; әгәр кешенең күңеле кара булса, эчке матурлыгы булмаса, аның тышкы матурлыгы да күзгә күренми.

Сиңа авыр чакларда, бу минутта кемгәдер яхшыдыр бит дип тә уйлагансыңдыр, ә минә сиңа яхшы булганда, кемгәдер бик тә авыр булу ихтималы синең башыңа да килмидер.

Ярар. Минем сиңа башка берни дә әйтәсем дә, акыллы киңәш тә бирәсем килми. Теләсәң, син үзең дә, бу хатны укыгач, кирәкле нәтиҗә ясый алырсың, дип уйлыйм. Мин синең таш йөрәгеңнең аз гына булса да мәрхәмәтлерәк, шәфкатьлерәк булуын телим.

Зур ышаныч белән
*синең яраланган, ләкин өметен*
*югалтмаган Намусың*

# САГЫНУ
## (Кадерле бабам - Хатыйп Гатин истәлегенә багышлыйм)

Зөбәрҗәттәй хәтфә юрган ябынган үрләр арасыннан чыгып килүче иртәнге кояш, әле уянып та өлгермәгән үзәнне күз кырые белән генә күзәтеп, йокы аралаш елмая иде. Якты кояш нурлары акрын гына, тавышсыз җыр сыман, шушы үзәнлек өстенә тарала һәм җәйге татлы чыкның үтә күренмәле тамчыларында чагыла. Бу иртә һәрбер үләнгә, чәчәккә һәм әле йоклап яткан һәрбер бал кортына сиздермичә генә якынлаша һәм, әкияттәге тылсымчыдай, аларны җиләс җилнең сулышы белән уята. Карурмандагы өрәкләрне хәтерләткән пәрәвез челтәрләре куе яфрак белән капланган агач ябалдашлары арасында тынсыз гына калтыраналар. Урмандагы агачлар да тирә-якка сибелгән яшел йомшак шарлар кебек, төрле-төрле төстәге тәпиләре белән үзләрен йөдәтүче кошларга күңелле генә селтәнәләр.

Менә шушы иртәнге сихри тынлыкта, алсу-соргылт офык ягында, кояш чыгышына таба акрын гына атлап килүче ике кешене күрергә була иде. Боларның берсе - уртача буйлы, бик мөлаем гына карт. Ул аксабрак, кул таягына таянып, җиргә сак кына басып атлый. Аның йомшак чал чәчле башы чыгып килүче кояш яктысында ап-ак мамыктай җиңел зур тузганакны хәтерләтә. Картның кулында - китап. Юлчыларның икенчесе исә - кечкенә генә (4-5 яшьләр чамасы булыр), бик шук һәм тере генә кызчык. Ул әле алга таба чабып китә, әле артка кала һәм, үзенең аллы-гөлле чәчәкләр бәйләменә яңа чәчәкләр өстәр өчен, әледән-әле иелеп, кыр чәчәкләрен өзә. Ике кеше дигәнем, без инде ул - минем яраткан бабаем һәм мин.

Әле дә хәтеремдә: бервакыт кышкы салкын кичләрнең берсендә без бөтен гаиләбез белән җылы өйдә табын янында җыелышып, тәмле-томлылар белән чәй эчеп утырдык. (Әйтергә кирәк, минем бабакаем - тәмле тамак, чәенә 3 кашыктан да ким шикәр комын салмый иде!) Шул кичтә ул безгә ниндидер искиткеч чәчәкләр турында сөйләде, ә җәй җиткәч, миңа аларны күрсәтергә вәгъдә дә бирде.

Бу иртәдә безнең менә шушы матур чәчәкләрне эзләп баруыбыз иде. Без аның белән кызып-кызып нәрсә турындадыр сөйләшеп, күтәренке күңел белән хуш исле җәйге үләннәр арасыннан атлыйбыз. Мин балалык назы белән дустымның (шул чакта үземчә бабамны мин шулай дип атадым) битенә төшкән иртәнге кояш нурларыннан ничек итеп күз кысуларын һәм бу нурларның аның кардай ап-ак керфекләреннән татлы ябышкак тамчы булып агып төшүләрен күзәттем. Ул миңа үзенең самими елмаюы белән елмаеп куйды. Бу елмаю кешеләрдәге гадәти елмаю булмыйча, гаҗәеп бер күренеш булып исемдә калган минем. Кызганыч, күп еллар үткәч тә, миңа бервакытта да һәм һичкемдә дә андый елмаюны башка күрергә туры килмәде. Моның сере шунда: елмайганда минем бабама елмаер өчен башкалар кебек ирен кырыйларын сузарга кирәк түгел иде. Аның бу гаҗәеп сөйкемле дә, самими дә елмаюын күрер өчен миңа дустымның өлгергән чикләвекне хәтерләткән көрән күзләренә бер карап алу да җитә. Бу вакытта бабакаемның йөзе яктырып китә, ә күзләре кырыендагы шаян җыерчыклары төрле якка очып китәләр сыман.

Артыннан барган чакларда да мин аның елмайганын бик тиз сизеп ала идем, чөнки бу минутларда аның бөтен гәүдәсе - куллары, кырау төшкән кебек чал чәчләре, шакмаклы күлмәге, хәтта ул таянган агач кул таягы да елмая кебек.

Бу иртәдә бабамның күңеле бигрәк тә күтәренке булып, ул минем белән шаярып, миңа юл буе төрле кызыклы хәлләр турында сөйләп барды. Ә мин аның сөйләгәннәрен шул чакта бик игътибар белән тыңладым. Ул вакыт-вакыт авызына нииндидер ак көпшәне каба һәм аннан чыккан аксыл төстәге тәтенне авызына суыра иде. Без хәтфә болын буйлап юлыбызны дәвам иттек, ә җәйге уйнак җил безнең чәчләребезне иркәләде, болында үсеп утырган күксел тукранбашларны төрле якка айкады. Аяк астындагы биек үләннәр аягымны кытыкладылар, шуңа мин ирексездән күзләремне йомдым.

Кинәт бабай туктап калды һәм минем кулымны кысып тотты. Шунда мин күземне ачмыйча гына аның нигә туктавы белән кызыксындым. Биргән соравыма җавап булмагач, күзләремне ашыкмыйча гына ачтым һәм гаҗәпләнүдән телсез калдым.

